1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН

2018 ИЮЛЬ № 7

СӨЮМБИКӘ

ISSN 0869-1398

СИНЕКЕМЕ, МИНЕКЕМЕ
өй эшләрен бүлешәбез

ТУАЧАК КЫЗЫМА ХАТ
әни көндәлеге

ГҮЗӘЛЕМ һӘМ САЛАВАТ МИҢНЕХАНОВЛАР СЫЙЛЫЙ
тутырылган ташкабак

Фелура НУРИСЛАМОВА: КЕШЕЛӘРГӘ ЫШАНЫРГА КИРӘК!

Минем өчен син һаман да – 17 дә!..

Минем өчен син һаман да – 17дә!..

Бу фотосурәтләр еракта калган кабатланмас мизгелләргә – Яшьлеккә алып китә...
...Шундый зур галәмдә меңнәр арасыннан бер-береңне эзләп табу – үзе үк могҗиза!
Аны күргәч кабынган хисләр – иң саф, иң ихлас, иң садә... Йөрәктәге сагышы да – якты, татлы, моңлы... Беренче очрашу... Аның кебек башка берәү дә юктыр! Дөнья – матур, яшәү шундый рәхәт! Очар өчен канатлар кирәкми дә!.. Ярату, йөрәккә генә сыялмыйча, җанда шигырь булып бөреләнә... Һәм мәңгегә Син – Шагыйрь, Ул Илһамчың булып кала...



Фәиз ЗӨЛКАРНӘЙ

БЕР СҮЗ

Мең кат тибрәнде күңелдә бер сүз,
бүтән сүзләргә ирек бирмичә:
«Яратам!..» дидем
кайнар пышылдап.

«Мин дә...» диде ич
карашың шунда.
Мең кат яңгырады күңелдә шул сүз,
бүтән сүзләрне ишеттермичә!

Рәсемдә: шагыйрьнең хатыны Ирка ханым.
70 нче еллар.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2018

1926 елдан башлап «Азат хатын» исеме белән чыкты. 1991 елда «Сөембикә» итеп үзгәртелде. Хатын-кызларның бөтентатар айлык әдәби-нәфис журналы 1913–1918 елларда чыккан «Сөембикә» журналының дәвамчысы.

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кулъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.

7'2018



Фото: Газинур Хафизов

Җитәкче-баш мөхәррир
Гөлнара Ильяс кызы САБИРОВА

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нәбирә Гыйматдинова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Айрат Сибагатуллин, Иркия Төхвәтуллина, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Эльвира Әхмәтова.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77

Җитәкче урынбасары 222-09-78
Рәмзия Кашапова
Баш мөхәррир урынбасары 222-09-78
Гөлнур Хәсәншина
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова
Әдәби мөхәррир
Эльмира Закирова
Сайт мөхәррирләре:
Сөмбел Гаффарова
Камилә Димөхәммәтова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Дизайн-макет:
«ASAFIN GROUP»
Верстка:
Лариса Маликова

Тышлыкта:
Фелура Нурисламова
Фото: Ксения Богданова

Бүлек мөхәррирләре:
Мәдинә Авзалова
Лилия Гәрәева
Эльмира Закирова
Ландыш Әбүдәрова
Фотокорреспондент
Ксения Богданова
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Гамәли хезмәткәрләр:
Нәфисә Әскәрова

Формат: 225х290 мм
Күләме 64 бит

Басарга кул куелды: 27.06.2018 ел
Заказ Е-1575
Тираж 4732

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77

Язылу индексы:
П2204 (ПАП рәсми каталогы буенча)
73002 («Роспечать» каталогы буенча)

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикә»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002



Факил САФИН

Хушлашмыйм

Юкәләр сары чәчәктә,
Исләре лә исләре!
Тузан тузып калган урам –
Көтү кайткан кичләрем.
Тау битендә сибелеп яткан
Кызыл куз – җиләкләрем,
Эссегә оеган урман,
Миләшләр, гөләпләрем,
Сау булыгыз! Китеп барыш
Сезне алып җаныма.
...Еллар томанын аралап
Карыйм туган ягыма.
Очалар көннәр, очалар,
Чуар күбәләк – вакыт.
Галәмнең бер өнсез җилен
Булмый гына туктатып.
Башакка тулган арышлар
Каршыга йөгерәләр.
Мине җилләр таныр микән,
Бер җырлап үтсәм әгәр?..


Тузаны да тансык икән
Көтү кайткан кичләрнең.
Хушлашырга ашыкма, җан –
Җилдә юкә исләре!
Тау битендә җиләк пешкән,
Чиккән сөлге күк алан,
Баланда – яшел муенса,
Серле елмаеп кала.

Шушы сихри дөньям белән
Хушлашмам ахыргача!
Мине китте диючеләр
Ялгышалар, ялгыша...


Фото: Ксения Богданова







БЕЗНЕҢ ТЫШЛЫКТА

12

ЭЗЛӘП ТАПКАН БӘХЕТ КАДЕРЛЕ
Эльмира Закирова

ЗАМАН ҺӘМ БЕЗ



6

ЭШМӘКӘР ӘНИЛӘР
Мәдинә Авзалова



20

«ӨЙРӘТ МИНЕ...»
Гөлнур Сафиуллина



10

ЧЕМПИОНАТ АЛАРДАН БАШЛАНА
Ландыш Әбүдәрова

ТАТАР ДӨНЬЯСЫ




24

«САРЫ ГӨЛЕБЕЗ...»
Рушания Алтай

ЭЧТӘЛЕК

МӘДӘНИ ТОРМЫШ 



34 ЯРКАНАТ
Асия Юнысова

ЯШӘЕШ 



40 АСЫЛЪЯРГА ХАТ
Гүзәл Сәгыйтова



48 КРУИЗ
Рәмзия Кашапова

ШУЛАЙ УК: 

28 КҮҢЕЛЕ АЧЫКНЫҢ – ЮЛЫ АЧЫК
Гөлнур Сафиуллина

44 АВЫЛ «БРАЧЫ» – РӘХМӘТ ФӘРЕШТӘСЕ
Роза Камалетдинова

ХАТЫН-КЫЗ ГАЛӘМЕ 



62 СМУЗИ


КИЛӘСЕ САННАРЫБЫЗДА: 


ЛӘЙЛӘ ТАИШЕВА. ТОРМЫШ КАГЫЙДӘЛӘРЕ

ЧИ КИЛЕШ АШЫЙБЫЗ: ЯҢАЧА ЯШӘҮ РӘВЕШЕ

«ИСЕМСЕЗ». АЛЬБИНА ГАЙНУЛЛИНА. ХИКӘЯ

ИПИНЕ НИЧӘ ТӨРЛЕ ИТЕП САЛЫП БУЛА? ХОББИ





ЭШМӘКӘР ӘНИЛӘР



Мәдинә АВЗАЛОВА

ҺӘР ЯҢА ЭШНЕҢ БЕРКЕМНЕ ДӘ КАБАТЛАМАГАН КЫЗЫКТЫРЫРЛЫК ЯҢАЛЫГЫ БУЛЫРГА ТИЕШ!

Бүгенге көндә зур рестораннары, кафелары булган бизнесвуменның: «Эшемне өчпочмак, пәрәмәч пешереп, кибетләргә куйдырып сатудан башладым дисәм, ышанмыйлар. Биредә бит кыюлык һәм фантазия кирәк. Ә калганына эшли-эшли остарасың», – дигәне искә төшә. Чыннан да, үзеңә эшли башлау өчен кыюлык та, тәвәккәллек тә, танышым әйткәнчә, фантазия дә кирәктер. Гәрчә миндә бу сыйфатларның барысы да бар дип әйтә алсам да, бәләкәй генә бер эшеңне башлап җибәргәнче, дистәләгән киртәләрне үтү, көнемне гел көрәшеп үткәрү кулымнан килмәс иде. Ыгы-зыгылы, мәшәкатьле бу мәйданга җаны кайнап торган, иртәгәсе көнгә ышанычы булган, «үлсәм – үләм, калсам – калам!» диюдән дә курыкмаган батыр йөрәкле кешеләр килә дә. Кемнәр килә? Әлбәттә, көч-гайрәте ташып торган яшьләр! Күп алар хәзер. Дөрес, үз эшләренә керешкән кешеләрнең яртысыннан

күбрәге, каршылыкларга очрап, ярты юлда туктап та кала. Акча эшләргә дә өлгермәгән кечкенә генә фирмага бер-бер артлы тикшерүләр килеп төшә башласа, «крыша кирәкме», дип теңкәңә тисәләр, ишегеңә йозак элмичә кая барасың? Безнең илдә коррупциянең беткәне юк бит әле. Ни рәвешле генә тырышмыйк, бетмәячәк тә ул.

Бүген без хатын-кыз эшмәкәрләр турында сөйләшербез. Әйе, авыр юлга чыккан ул ханымнарны сәүдә һәм халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсе кызыктыра. Алар шул юлны сайлый да. Безнең илдә 30 яшькәчә булган эшмәкәрләрнең саны миллионнан артып китә икән. Күпме бу, азмы?! Әйтүе кыен. Ник дигәндә, үз кибетләрен, матурлык салоннарын, икмәк пешерү заводларын (завод дигәч тә, аптырап калмагыз, ике-өч мичтән торган кечкенә генә биналарда урнаша алар) ачып җибәргән мәлдән башлана да инде «ник тотындым» көненә калдырган проблемалар. Үзеңә эшләү дәрәҗәсенә, әйе, әйе, нәкъ менә дәрәҗәсенә ирешкәнче, сират күпере кичәргә, бер пот тоз ашарга кирәк була әле. Актаныш якларында туып-үскән булачак эшмәкәр Алсу Гомәрова дә шулай ди әнә.

«Аның бер фишкасы булсын...»

Ул бер-бер артлы Мәдәният һәм сәнгать институтын, ТИСБИны тәмамлаган. Шул арада Татарстанның Икътисад министрлыгында, Эшмәкәрлекне үстерү комитетында, Петербург шәһәренең «КСИЛ» компаниясе филиалында эшләргә өлгергән. «Соңгысында әле бер генә ел эшлим. Инде бүлекне җитәклим», – дигәне дә мактанудан түгел. Барына өлгерә, булдыра, димәк. Әле моның белән генә дә тукталып калмаган, Алсу һаман укый. Дөресрәге, укуын дәвам иттерә, чөнки аның белем эстәү мәсьәләсендә тукталышлар ясап торганы юк.

– Күп ул минем хыяллар, – ди Алсу Гомәрова. – Шулай да күңелгә иң якыны, гел ымсындырып торганы – кешеләргә матурлык бүләк итү, шуның белән аларны бәхетле итү.

«Кешеләргә...» – дигәндә, әлбәттә инде, ул кешелекнең гүзәл яртысын күз алдында тота. Чөнки ул бүген – оста визажист, парикмахер... Бүген шулай... Ә алга таба?! Алга таба безне, ягъни Алсуыбызны заманча җиһазландырылган, кызларны тагын да чибәрләү өчен бөтен мөмкинлекләре, шартлары булган якты салон көтә. Юк, алай да түгел: үзе әйткәнчә, «Матурлык студиясе!» Шәп бит, әйеме?! Һәрхәлдә, булачак эшмәкәрнең хыялы шундый. Ә хыяллар якты булса, адәм баласын куандырырлык булса, һичшиксез, кайчан да бер гамәлгә аша бит ул! «Шуңа тырышам, шуңа бертуктаусыз укыйм», – ди ул. Дөресен әйткәндә, аның укымаган курслары, белмәгән өлкәсе калмаган да шикелле. Визажист, парикмахер, бортпроводница курсларын тәмамлаган. Хәтта телевизион тапшыруларны алып бару осталыгына да өйрәнгән. Бөтенроссия күләмендә уздырылган визажистлар форумында беренче урынны алып шаккаттырырга да өлгергән.

«ХАТЫН-КЫЗ ДЕКРЕТ ЯЛЫНДА ДА ЭШСЕЗ ТОРМЫЙ»



Татарстан Президенты каршында Эшмәкәрләрнең хокукларын яклау буенча тулы вәкаләтле вәкил Тимур НАГУМАНОВ:

Уйлавымча, икътисадны үстерүдә мөһим һәм алыштыргысыз факторларның берсе – хатын-кызның эшмәкәрлек белән шөгыльләнүе, үзен шул өлкәдә табуы. Бу иҗади мөмкинлекләргә дә киң юл ача. Ә безнең бурыч – аларга уңай шартлар тудыру, үз эшләрен ачып җибәргән ханымнарга һәрьяклап булышлык күрсәтү, ягъни административ киртәләрне үтәргә, эшлекле мохитне яхшыртырга ярдәм итү.

Бу бигрәк тә декрет ялында утыручы әниләргә кагыла. Аларның потенциалы бик зур. Үзләре дә эшләргә ашкынып тора. Көненә берничә сәгать кенә эшләп алсалар да, гаилә бюджетына күпме өстәмә акча дигән сүз бит бу. Хатын-кызның кулы бөтен эшкә ята.
Алар үзләре ошаткан, яраткан эшне сайлыйлар. Еш кына ул үз куллары белән ясаган төрле әйберләр була. Татарстан Президенты каршында Эшмәкәрлек советы үзләренә эшләүчеләргә ни комачаулый, бизнесын үстерер өчен ниләр җитми, дигән сорауларга җавап алыр өчен махсус тикшеренүләр алып бара. Без инде әниләр, эшсез калган ханымнар белән берничә мәртәбә очрашулар да үткәрдек.

Күбесе өйдә генә эшләүдән тәм тапмый башлаган икән. Хәзер алар үзләрен күрсәтү, легаль эшләү ягында. «Соры» эшчәнлек инде канәгатьләндерми. Аларның хезмәтенә тел-теш тидерерлек булмасын – максатлары шундый. Бер уйлаганда, бу бит тикшерү органнары белән килеп чыккан проблемалардан тыш, кирәге чыга калганда, аларга социаль гарантиянең, дәүләт ярдәменең булмавын да күрсәтә. Әгәр дә без бүген таләпләрне киметә төшәбез икән, ул чагында киләчәктә өйдә эшләүче ул әниләр үзләренең компанияләрен оештырып җибәрергә дә мөмкин. Әмма моның өчен тиешле шартлар булырга тиеш. Ләкин, шуның белән бергә, без Татарстанда мөстәкыйль эшләүчеләр өчен әйбәт, эшлекле мохит тудырырга да бурычлы.

Фото: www.pixabay.com

PRESSA



– Форум миңа һөнәри осталыкны чарлау өчен нык булышты, күп нәрсә бирде, – ди Алсу. – Без ул көннәрдә кемнәр белән генә аралашмадык, кемнәрне генә күрмәдек. Төннәрне йокламыйча үткәрдек дисәм, арттырмам. Чөнки ул аралашуның һәр минуты, һәр мизгеле кадерле, кабатланмас булды. Мин форумнан үземә тагын да ныграк ышанып, «үземнекен булдырам!» дип тәвәккәлләп кайттым. Үз эшеңне башлап җибәрү өчен стимул кирәк. Эшне ачтым да, эшләтеп җибәрдем генә түгел бит әле ул. Минемчә, аның бер фишкасы, беркемдә дә булмаган кызыктыргыч яңалыгы булырга тиеш. Шулай дип уйлыйм. Салоннар күп, ә менә аерылып, күзгә бәрелеп, үзенә тартып торганы?! Мин шундыйны телим!

Эшмәкәр ханымнар күбрәк сәүдә һәм халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсен сайлыйлар.

Күптән түгел генә «Эшмәкәрлек фабрикасы» дәүләт программасының гамәлгә керүен исегезгә төшерәбез. Яшь һәм тәҗрибәсез эшмәкәрләр өчен Икътисад министрлыгы башлап җибәргән әлеге программа зур таяныч, олы ярдәм булыр дип көтелә.

«Укулар нәрсә бирде?» – дигән соравыма, әңгәмәдәшем: «Күпне...» – ди. «Күпне» дигәне әллә нәрсәләрне колачлый. Салымның ни икәнен аңларга, бухгалтерлык рекламалары, «бурычларны дөрес итеп куярга» өйрәнү... Җыеп әйткәндә, «бизнесны төреп күрсәтү»... ягъни мәсәләнен. Чыны шулай: «кичәге система бүгенгә ярамый». Бизнес өлкәсенә генә кагылмый бу. Бер урында таптану – бизнесыңны, еллар буе тупланган эш тәҗрибәңне, ахыр чиктә, барлы-юклы байлыгыңны бер кизәнүдә югалту дигән сүз. Шуны тирәнтен аңлаган кеше генә бу эшкә алына.

...Иртәнге өчтә торып, Алсу кәләш бизәргә китә. Аннары – балаларга күңел ачу мәйданчыклары өчен яңа проектлар эшләргә. Аннан соң – студиягә! Күңелеңдә иҗади ялкын сүнмәгәндә, иртәгәсе бүгенгедән яктырак, яхшырак күренгәндә генә барып чыга бит ул уйлаганың!

Балага – авыл сөте

Декрет ялында утыручы Алина Буслаева, баласына күкрәк сөте җитмәү сәбәпле, танышлары аша авыл сөте, ә кызчыгы үсә төшкәч, эремчек, каймак ише әйберләр кайтарта башлаганда авыл белән мөнәсәбәтләрнең зурга китәчәген, моның үзенә күрә бер кеременбабыш чарасына әвереләчәген башына да китереп карамагандыр. «Уйламадым да...» – дигән эшмәкәр әнинең шуны күз алдында тотуыдыр. Авыл белән шәһәр арасына юлларны, бик теләгәндә, әнә шулай да табып була икән!

– Кешенең: «Авыл сөте, авыл тавыгы... кыскасы, авыл ризыгы», – дип исе китә. Андый «натураль продукт» балага да бик файдалы. Ихтыяҗ булачагына ышандым. Шуңа да кызыма өч ай ярым булганда, ирем белән интернет-кибет ачып җибәрдек, – ди ул. – Башта Кама Тамагы районы, ә берникадәр вакыттан соң Арча төбәге белән эшли башладык. Атнага 15 заказ туры килә. Халык күбрәк сөт, каймак, тавык сорый. Әкренләп кенә кереме дә килеп тора. Без әлегә канәгать.

Заказны авылдан курьер китерә икән. Китереп биргән өчен 120 сум түлисе. Күп тә түгел үзе. Шушы көннәрдә генә Казан шәһәрендә Алина Буслаеваның яңа кибете ачылды. Монысы инде интернет-кибет түгел! Барып, күреп, авыл продуктларын рәхәтләнеп сайлап алырга була. Башлап җибәргән эшенең барып чыгачагына ышана Алина. «Авылныкы бит ул: үзе чиста, үзе сыйфатлы, үзе файдалы, бәясе дә арзан...» – дип тезеп китә ул.

Декрет ялында утыручы ханымнарны эшмәкәрлеккә өйрәтергә җыеналар гына әле. Ә Алина инде үзе теләсә кемне өйрәтерлек, тәҗрибә уртаклашырлык эшмәкәр булып өлгергән. Татарстан Икътисад министрлыгының «Татарстан Республикасы эшмәкәрлеккә ярдәм итү фонды» белән берлектә гамәлгә кертелгән «Эшмәкәр әни» проекты декрет ялында утыручы әниләр өчен генә түгел, балигъ булмаган балалы һәм эшсез хатын-кызлар өчен дә бит. Укуларның бушлай булуын да әйтик. Уку дәвамында алар бик күп нәрсә үзләштерәчәк. Ә иң мөһиме: остазлары аларны бизнес-план төзергә өйрәтәчәк. Шунсыз үз эшеңне башлап җибәрү турында уйлама да. Бу укуларның янә бер отышлы ягы: курслар тәмамлангач, бәйгедә җиңүчегә 200 мең сум грант тапшырылачак. Бушлай укы да, өстәвенә, үз эшеңне ачып җибәрү өчен кулыңа акча да тоттырып җибәрсеннәр әле! Социаль мәгънәгә ия булган, ягъни халыкка файда китерердәй проектларга өстенлек биреләчәк. Июль урталарына дип торган әлеге чаралар Эшмәкәрләр йортында үткәреләчәк.



Әмма, Алина әйткәнчә, өйдә хезмәт күрсәтүнең, әлеге дә баягы интернет-кибетләр аша товар сатуның уйлап бетерелмәгән яклары да бар. Бу хакта Президент каршындагы Эшмәкәрлек советының киңәйтелгән утырышында ачык итеп әйтелде. Интернет-кибетләр аша сатылган ризыкларның сыйфатына шик белдерелде. Аның хуҗаларына салым түлисе дә, социаль фондка акча күчерәсе дә юк. Билгеле, болай эшләве рәхәт. Тик дөрес түгел, башка эшмәкәрләргә карата гадел түгел. Шуңа да җитдидән-җитди бу мәсьәләдә уртак фикергә килене: Татарстан Президенты әйткәнчә, кем өйдә торып эшли, өйгә барып хезмәт күрсәтә, андый эшмәкәрләрдән салым алынырга тиеш.

Аңлашылганча, эшне башлап җибәрү генә түгел, аны алып баруы да бик авыр һәм җаваплы.
Чөнки ул ипи пешерү йә әзер ризыкны сату гына түгел. Тынычлап эшләргә ирек бирсеннәр өчен башта тау кадәрле кәгазь белән баш ватасы, кирәкле документларны вакытында тиешле урынга илтеп җиткерәсе бар.

Һәркем шулай нәрсәдән булса да башлый.
Тик башлаганы гына күңеленә ятсын. Үзенеке булсын. Әйткәнебезчә, беркемдә дә булмаган, кабатланмаган, фишкасы – «кәҗәсе түгел, мәзәге» булсын... Шул чагында гына максатыңа ирешәсең ул. Моның өчен мөмкинлекләр җитәрлек әнә. Эшмәкәрләргә бит хәзер дәүләт булыша. Хатын-кызларны, әниләрне кече һәм урта бизнеска тартып кертү өчен илдә дистәләгән программа бар. Безнең республика да бу юнәлештә актив эшли. «Эшмәкәр әни», «Эшмәкәрлек фабрикасы» программалары – шуның ачык дәлиле. Ләкин әзерлексез булмый. Статистик мәгълүматларга караганда, өч ел эчендә эшмәкәрләрнең 10 процентка якыны гына эшләп кала. Яртысы исә бер ел да эшли алмый, ябыла. Сүз дә юк, бу – катлаулы, җаваплы эш. Алсу сыман «мин үз эшемне ачарга әзер!» дип торганда гына хәлиткеч адымга барырга, тәвәккәлләргә була.

БИЗНЕСНЫ НӘРСӘДӘН БАШЛАРГА?



Эшмәкәрлекне яклау
үзәге җитәкчесе
Тимур ГОМӘРОВ:

– Без кече һәм урта бизнес турында сөйләшәбез. Шуңа бу төшенчәләргә билгеләмә биреп китик әле. Федераль закон нигезендә, кече бизнес дигәндә нәрсәне күз алдында тотабыз? Әйтик, бу фирманың 100 дән дә ким булмаган хезмәткәре булырга һәм аның товар әйләнеше 800 миллион сум тәшкил итәргә тиеш. Ә урта бизнесның штаты 250 кешегә җитә, товар әйләнеше исә елына 2 миллиард сумнан да ким булмаска тиеш. Әйе, фирманы ничек теркәргә, нинди документлар тутырырга дигән үтенеч-сораулар белән безгә еш мөрәҗәгать итәләр. Шуны истә тотып, махсус программа эшләдек. Нидән башларгамы? Бизнесны башлап җибәрү өчен иң элек аның идеясе булырга тиеш. Әйткәнебезчә, сезне нәрсә кызыксындыра, нинди эшкә күңелегез ята?
Бу сорауга җавап биргәннән соң, икенче адым: базарны өйрәнегез. Җентекләп, иренмичә... Ник дигәндә, ул сезнең киләчәк уңышыгыз... Кирәкме ул сез җитештерергә уйлаган товар, азык-төлек, йә булмаса хезмәт күрсәтү? Әйтик, кибетегезне ачарсыз, ә кеше килмәс. Хәзер конкуренция бик көчле, һәм беркем дә сезне шатланып каршы алмас. Өченчедән, базар ихтыяҗын өйрәнгәннән соң гына бизнес-план төзисез. Монда барысы да исәпкә алынырга тиеш: кереме-чыгымы, документлар, мөһер әзерләү, исәп-хисабыңны ачып җибәрү өчен кирәкле документлар һәм башкалар.
Дүртенчедән, әлеге әзерлекне үткәннән соң гына үзең яшәгән урында салым хезмәтенә барып теркәләсең. Әгәр дә бизнес-планның барып чыгачагын дәлилләп күрсәтә алмыйсың икән, ул чагында кредиттан колак кагасың. Аннары пенсия фондына барып, эшчәнлегеңне белдереп кайтасың. Күпме керем керә, күпме чыга... фонд бу мәгълүматны белеп торырга тиеш. Тагын бер алтын кагыйдә бар: кеременең 80 проценты, һичшиксез, бизнесны үстерүгә тотыла. Аның нибары 20 проценты гына – кесәгә... Мөһер турында тагын бер кат искә төшерәм: шәхси эшмәкәргә кирәкмәсә дә, җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять өчен ул бик мөһим.

ЧЕМПИОНАТ АЛАРДАН БАШЛАНА

FIFA 2018 ВОЛОНТЕРЫ НИНДИ УЛ? ЯШӘҮ ДӘРТЕ ТАШЫП ТОРГАН, СӘЛАМӘТ ЯШӘҮ РӘВЕШЕ АЛЫП БАРГАН, ЧИТ ТЕЛЛӘРДӘ СӨЙЛӘШӘ БЕЛГӘН ҺӘМ ҺӨНӘРИ КҮНЕКМӘЛӘРЕ БУЛГАН КЕШЕ УЛ.

Ландыш ӘБҮДӘРОВА

Тырыш, эчкерсез хезмәттән һәм кешеләр белән аралашудан курыкмый... Нәкъ шундыйлар белән таныштык та без.

ЛАРА СИСА ЮЛИ АЛЕКСАНДРА:

«Валентина Терешкова иле бит бу!»



Александра, океан артындагы Колумбиядән үк килеп, Казанда ничек волонтер булып киттең?

– Мин Колумбиядә вакытта ук волонтер идем инде. Латин Америкасында тхэквандо буенча чемпионатта эшләгән тәҗрибәм бар (Александра үзе дә тхэквандо буенча кара билбау иясе – *авт.*). Казанга килгәч тә, волонтерлыкны ташламадым. Ул – кешенең дөньяга карашының бер өлеше, йә бар ул, йә – юк. Волонтер булу күп кешеләр белән аралашу мөмкинлеге бирә, чит телләрдә сөйләшәсең, дөньяң киңәя. Казанда дүртенче елымны яшим, авиация университетында укыйм. Узган ел Конфедерацияләр кубогында волонтер булдым.

Чемпионатта кайсы юнәлештә эшлисең?

– Мәгълүмат юнәлешендә. Ягъни мин стадионга килгән җанатарларга инглиз, француз, испан, рус һәм португал телләрендә кирәкле мәгълүматлар белән ярдәм итәм.

Ни өчен нәкъ менә Россия һәм нәкъ менә авиация?

– Валентина Терешкова! Мин монда нәкъ менә шушы шәхес аркасында килдем. Ул минем кумирым дисәң дә була. Ул бит Галәмгә чыккан беренче хатын-кыз! Россия бу яктан да беренче. Гомумән, Россия шундый ил: аны узып булмый. Сугыш чыкса, ул җиңә; әгәр дөньяда берәр яңа төр самолет ясыйлар икән, Россия аннан да зурракны, көчлерәкне ясап куя...

Кечкенә чагымда ук механика ярата идем. Әтием зур машиналар йөртүче булып эшли. Мин гел аның янында кайнашып үстем. «Кызым, машина төзелешенә барырсың инде», – дигәч, «Юк, миңа тагын да зуррак кирәк, мин самолетлар конструкторы булам», – дия идем. Хыялым чынга ашты диярлек, самолетлар төзү факультетында белем алам. Тагын Франциядә яшәргә хыялланам.

Казанда татарлар яшәвен белә идеңме?

– Колумбиядә яшәгәндә, Россиядә руслар яши, анда карлы кыш һәм аюлар гына бар дигән мифка ышана идем. Казанга килгәч, бөтенләй башка дөньяга эләккән кебек булды. Татарлар турында да белдем, чәкчәк тә, өчпочмак та ашап карадым. Авыл каймагы бик ошады. Сеңелләремә дә җибәрдем аны, тагын сорадылар.

Кешеләре бик ачык. Кызганыч, инглиз телен аңлаучылар бик аз, бу туристларга кыенлыклар тудыра дип ишеткәнем бар. Аңламасалар да, ярдәм итәргә тырышалар бирәдә.

Туган як сагындырамы?

– Туган шәһәрем Дуитама да, әни дә сагындыра. Алай да иялләштем инде.

Салкын кышларга дамы?

– Беренче тапкыр кар күргәч, әй сөендек! Без монда Колумбиядән берничә студент укыйбыз. Шулай ук Конго, Непал, Мадагаскардан килгәннәр белән дә аралашып яшибез. Колумбиянең мин яшәгән шәһәрендә ел әйләнәсе 20 градус җылы, кар күргән юк иде. Беренче айда кыш ошый, икенчесендә битарафлык ала, өченче айда туйдыра башлый, дүртенчесендә инде бөтенләй качасы килә.

Колумбия дигәндә, иң беренче күз алдына нинләр килә?

– Кофе, Габриэль Гарсиа Маркес, Шакира, валленато, сальса һәм футбол!

Син үзең дә футбол җанатарымы?

– Әлбәттә! Ничек инде футболсыз яшәп булсын, ди! Мин монда да университетта кызларның футбол командасында уйныйм. Сездә футбол – хобби булса, бездә ул дин кебек: футбол белән җенләнмәгән кеше юк. Футбол матчы булган көнне бездә эшләмиләр. Стадионда исә чирәмдә футбол уйныйлар, трибуналарда бииләр. Гомумән, бездә хәрәкәт яраталар. Валленато белән сальса биемәгән кеше юк. Кайда музыка ишетсәләр, шунда бии башлыйлар.

КАЗАНДАГЫ ИҢ ӨЛКӘН ВОЛОНТЕР ФИРДӘВЕС ГАРӘФИ КЫЗЫ ЗАКИРОВА:

«Безне көмеш волонтерлар, диләр»



Фирдәвес апа, үзегезнең волонтер булу тарихын сөйләгез әле.

– Пенсиягә чыккан идем инде. 2013 елгы Универсиадага 500 көн кала мине волонтер булырга чакырып алдылар. Спортны яратам үзем: яшь чактан ук чаңгыда шуу, йөгерү, йөзү белән шөгыльләндем, шашка, шахмат уйныйм. Әле дә заводка (Фирдәвес апа лаеклы ялга чыкканчы «Казаньоргсинтез» заводында эшләгән – *авт.*) ветераннарның шахмат түгәрәгенә чакырып торалар. Универсиадага кадәр тест режимындагы ярышлар булды, аларда катнаштым. Волонтерлык тормышым шуннан башланды.

Димәк, Универсиада-2013 – беренчесе, FIFA-2018 сезнең өчен соңгысы түгел?

– Әйе, Универсиададан соң шул ук елны Мәскәүгә җиңел атлетика буенча Дөнья чемпионатына волонтер булып бардым. Аннан соң 2014 елда Сочида Кышкы олимпия уеннарында, Паралимпиадада волонтер булып эшләдем. 2015 елда Ханты-Манси автоном округында Биатлон буенча дөнья кубогының йомгаклау этабына, шуннан ук Хабаровскига туп белән хоккей ярышларына киттем.

Быелгы Чемпионатта сез нинди юнәлеш волонтеры? Белүемчә, волонтерлар 20 юнәлештә эшли.

– Бу юлы билет алу юнәлешендә эшлим. Аңа кадәр Конфедерацияләр кубогында да шушы ук юнәлештә идем. Безнең эш билет алырга килүчеләрне каршы алу, аларга юнәлеш бирү, электрон билетларын терминаллардан бастырып чыгару. Кыскасы, билет белән бәйле барлык сорауларга җавап бирү, ярдәм итү.

Волонтер булганчы нинди этаплар үттегез?

– Безнең белән психологлар эшләде, телләр үзләштердек. Мин инглиз телен өйрәндем. Теләгән һәркем волонтер була ала. Моның өчен интернет аша гариза язып, анкета гына тутырырга кирәк. Шуннан соң әңгәмәгә чакыралар.

Лаеклы ялга чыккач, гадәттә, ял итәләр...

– Бу да бит үзенә күрә ял. Яшьләр белән аралашу яшәртеп җибәрә. Миндәйләр тагын бар безнең арада – өлкән яшьтәгеләрне көмеш волонтерлар, диләр. Без спорт белән генә шөгыльләнмибез, социаль проектларда да катнашабыз. Узган кышта авыру балаларга курчак театры күрсәттек. Сценариен да, режиссерлык эшен дә, курчакларны да – барысын да волонтерлар үзебез башкардык. Хәйрия ярминкәләрен оештыруга ярдәм итәбез. Әнә шулай мәшәкатьле дә, күңелле дә яшибез.

Фото: Гөлнара Сагиева

СҮЗ УҢАЕННАН

- Быел Футбол буенча дөнья чемпионатында 17040 волонтер эшли.
- Волонтер булырга килгән гаризалар саны буенча рекорд нәкъ менә Россиядәге Дөнья чемпионатында куелган: 176870 кеше! Ә бит Россиядә волонтерлык хәрәкәте турында кайчан гына әле белмиләр дә иде диярлек. Соңгы еллардагы халыкара спорт ярышлары аркасында илебез аларны белә, күрә башлады.
- 2018 ел – Россиядә Владимир Путин Указы белән Волонтерлар елы дип игълан ителде. Волонтерлык хезмәт хакына өмет итмичә, эчкерез ярдәм итүне күздә тота торган теләсә кайсы эшчәнлек төрен аңлата.



ӘЗЛӘП ТАПКАН БӘХЕТ КАДЕРЛЕ

ҮЗ ЭШЕҢНЕ БАШЛАП ҖИБӘРЕП, УҢЫШЛЫ ЭШМӘКӘР БУЛЫП КИТӘР ӨЧЕН, КИМЕНДӘ ДҮРТ ТАПКЫР ТӨП БАШЫНА УТЫРЫП КАЛУ КИРӘК ӘЛЕ, ДИЛӘР.



Эльмира ЗАКИРОВА

Кемнәргәдер берсе дә җитеп ашкан. Мөгаен, дөрестер. Язмышка ул сабаклар өчен рәхмәтле була белергә кирәктер, бәлки? Ә Фелура НУРИСЛАМОВАның андый сабаклары дүртәү генә дә булмагандыр!

Шул бәхетемне эзләп юлга чыктым...

– Әйдә, «Ел хатын-кызы» конкурсында катнаш әле, Фелура. Синнән дә булдыклырак бизнес-леди юк та әле безнең, – дип үгетлиләр аны.

Район данын якларга, эшеңне күрсәтергә кирәк, диләр. Көнне төнгә ялгап башкарган эшләргә, көндәлек мәшәкатьләргә һич көтелмәгән яңалары өстәлә: макияж, прическа, грация, көлмәкләр... Һәм көннәрдән бер көнне гап-гади, күз күреп күнеккән гадәти Фелураны... эшендә дә, урамда да танымыйлар. Киемнәр кибетенә күлмәк сайларга кергәч, сатучы кызлар сырып ала үзен, кайберләре телефонына ук төшерә башлый.

– Фелура, синме бу?!

– Абау, танырлык та түгел!

– Унбиш яшькә яшәргәнсең бит!

– Йөгез инде, куегыз. Күлмәкләр карыйк тизрәк, – дип, сатучылар янында уңайсызланып, әле зәңгәргә буй-буй төшкән, әле шакмаклы, әле күзләрен тагын да тирәнрәк күрсәтүче күкчәчәк төсендәгеләрен киеп караганда күңелен бер уй сызып үтте: «Чү, «Служебный роман» фильмында Алиса Фрейндлих уйнаган Людмила Калугина кебек булды түгелме соң? Халык белән эшлисе: хатын-кыз икәнеңне дә истән чыгарма шул!»

Сәхнәдә ул «бизнес-леди» номинациясендә иде. Ире – Рәсиме: «Бөтен Азнакаена бер бит ул безнең Фелура! Андый бүтән юк!» – дип гел әйтеп тора да бит. Аның өчен җан атып йөргән туганнан туган сеңлесе Рушания дә: «Бирешмә! Булдырасың! Җиңәсең!» – дип әзерләде. Район буенча «2017 елның иң яхшы эшмәкәре» дип тә танылды. Зал тулы туганнары, якыннары утырса да, каушата икән шул. Конкурсның район туры тамашасын алып баручы үзе белән таныштырганда, Фелура нык дулкынланды. Бөтен Азнакай халкы каршында әнә ничек бәялиләр аны!

«Нурисламова Фелура Мөбарәкша кызы бу югарылыкка ишегалдын себерүчедән башлап күтәрелә... Аңа бик күп каршылыклар үтәргә туры килә. Бүген 200 дән артык вак шәхси эшмәкәрнең исәп-хисап эшләрен алып барып, районыбыз бюджетына салым керемнәрен төгәл саннар белән кичектерүсез кертеп бара... Мохтаҗларга, авыру кешеләргә һәрчак ярдәм итә. Салымнар, пенсияләр, хезмәт хакларыннан күчкән керемнәрне исәпләүдән тыш, Фелура эш урыннары булдыру, халыкка хезмәт күрсәтү хакында кайгыртып йөри. Аның азык-төлек сату кибете, камыр ризыклары җитештерү цехы, «Хәләл» кафесы бар. Планнары зурдан. Тагын да күбрәк эш урыннары булдыру, 6 гектар җирдә теплица кору, җиләк-җимеш һәм яшелчә саклау һәм эшкәртү цехы булдыру буенча эш алып бара. Авыл җирлегендә көн күрүче шәхси хуҗалыклардан яшелчә, сөт ризыклары, ит, йомырка, җиләк-җимеш кабул итеп, сатуга куючы, җитештерү цехында тәмле ризыклар әзерләп, алыпсатар эшен дәвам итүче бердәнбер хатын-кыз ул республикада...»

Бердәнбер хатын-кыз... Ничек матур яңгырый бу сүзләр! Ничек бәхетле күренә ул! Ә бәхетен эзләп юлга чыгуы кайчан, кайсы төбәкләрдән, ничек башланды соң әле?

...Ерак Үзбәкстаннанмы? Сәмәрканд өлкәсендәге үзе туган Чархин бистәсеннәндер, бәлки... Тянь-Шань тауларына, Чирчик елгасына сыенып утырган Газалкенттанмы әллә? Бәлки... Ләкин бу дөньяда тагын Бакалы районында, Ык буенда Саскүл дигән авыл да бар бит әле! Фелура анда тумаса да, аның изге җир, ата-баба нигезе икәнен ничек кенә белә әле! Апалары Мәдинә белән Фәридә дә, энесе Зөфәр дә ерак Үзбәкстаннан җәй саен сагынып, ашкынып кайталар иде әтиләре авылына. Әниләре Дөрлефәхирәнең дә туган җире ерак түгел – Туймазының Кандра күле үзе бер җәннәт бишеге. Әтисенең бертуганы Мөхәммәдиша абыйларының кызы Рушания белән Ыкта су коенулар, чишмәдән су ташулар, көтү көтүләр, чөгендер эшкәртүләр, кич клубка чыгулар... Барысы Фелураның күз алдында. Рушания, безнең Мәрданша бабай Ногайбәк нәселеннән булган, дип сөйли. Ык аркылы чыгып, Саскүлгә нигез салган, ди. Үзе чабата үреп саткан акчага Дәүләкәндәге тегермәннән он алып кайтып, үзе ипи салып сата торган булган, ди. Әтисенең Гөлфәридә исемле сеңлесе заманында Украинада сәүдә министрлыгында эшли. Икенче сеңлесе Гөлнәзирә Мәскәү өлкәсенең Талдом совхозындагы тырыш хезмәте өчен Ленин ордены белән бүләкләнә, ВДНХда аңа «Жигули» автомобиле ачкычын тапшыралар. 1978 елда үзе эшләп җыйган 200 сум акчасын (ул чор өчен шактый сумма!) Тынычлык фондына күчерә ул! Ә үзенең иң олы апасы Мәдинә соң! Ташкентта икътисад министрлыгында эшли!

Менә шундый тырыш, үз хәләл көчен куеп көн күрүчеләр аның туганнары.

Мал табуга, сәүдә эшенә, исәп-хисапка хирыслык нәселдән килә бездә, ди Фелура. Ул инде Әлмәттә нотариаль конторада эшләүче кызы Фирүзәне, үзенә булышучы улы Русланны да күздә тотып әйтүе. Шулай булмаса, мәктәптән соң Сәмәрканд икътисад техникумына укырга кереп, аны кызыл дипломга тәмамлар идеме? Башта Багишамал районы мәгариф идарәсендә бухгалтер булып эшли, ярты елдан тырыш кызны өлкән бухгалтер итеп күчерәләр. Читтән торып Ташкент халык хуҗалыгы институтының бухучет факультетында укулар, торак-коммуналь хуҗалыкның, төрле кооперативларның баш бухгалтеры булып эшләүләр... Һәм шул елларда ул үзе өчен бик кирәкле булган алтын кагыйдәләрне дә үзләштерә. Үз көнеңне дөрес бүләргә, кешеләр белән аралаша белергә, көчле ихтыярлы, тырыш, төгәл булырга, үз-үзеңә ышанырга, максатыңа теләсә нинди юллар белән ирешергә... Төгәл саннар эченә әллә нинди серләр яшерелгән бик мавыктыргыч, кызыклы эш!

PRESSA





Ире Рәсим белән шулкадәр туры килгәннәр, диләр алар турында.

Мин табарга тиеш, табарга!

Шул бәхтемне эзләп тапканым юк, / Инде таптым дисәм – югалтам...

Ничек туры килә бу җыр Фелурага!

90 нчы елларда, СССР таркалгач, Үзбәкстанда эшсезлек башлана. Нурисламовларны да туган яклар үзенә тарта. Ире Рәсим – Туймазы егете бит, Фирганәгә күченеп кенә килгәннәр. Аның да бабалары – Бакалы якларыннан, Мостафа авылыныкылар. Илдә чыпчык үлмәс, дип, 1994 елда, 12 яшьлек кызлары Фирүзәне, 2 яшьлек уллары Русланны алып, Ташкенттан кайтып төшәләр. Башта – Мостафага, аннан Азнакайга... Эш табарга, куыш табарга, югалган бәхетне табарга... Тик монда да эш юк, халык хезмәт хакы алалмый, кибетләр буш икән. Берәү дә көтеп тормый, дисәң... Ярый әле хәлгә керә торган, һәрчак булышырга әзер туганнар бар! Таянычы – ире бар! Чиләгенә күрә капкачы, диләр бит. Безне дә өйләрендә Рәсим пылау пешереп көтә иде. Зира, куркумалардан бөтен өйгә үзбәк кухнясының хуш исе таралган. Берара Рәсим кафеда лагман, бишбармак, пылаулар пешерә, Фелура халыкка хезмәт күрсәтә. Кафе дигәннән, кемнәрдер аларның үзләре ачкан кафесын ике тапкыр яндыра, бер тапкыр гаражларын талыйлар; Ташкенттагы фатирларын сатып, УАЗикка алыштырып кайтканда, Казакъстан белән Оренбург чигендә билгесез кешеләр туктата: пычак белән янап, ярты көн тоткын итеп утырталар. «Язмыш безне төрле яклап сынады.Ниләр генә баштан кичмәде», – дип, Фелура тормышының Азнакай чоры турында сөйли.

– Туганыбыз Хәмит абый торак-коммуналь хуҗалык трестында механик булып эшли иде. Сүзен тыңлап, бер ай сынау срогы белән ишегалдын җыештыручы итеп алдылар мине. Рәсим пилорамга такта яручы булып урнашты. Миңа иң чүпле, ташландык җирләр эләкте. Җыештырып кына да бетерерлек түгел. Ярар, дим, без бирешә торганнардан түгел! Сизеп торам: яратмыйлар! Бирешмәскә, үземне табарга, күрсәтергә кирәк, дим үҗәтләнеп. Үз участогымны гөл кебек итеп куйгач кына санлаша башладылар. Ирле-хатынлы бер оешмада эшләгәч, тулай торактан кечкенә генә бүлмә дә бирделәр. Сөенүләребез! Контейнер белән кайтарган әйберләребезне Мостафадан тизрәк алып килергә ашыктым: эштән самосвал машинасы биреп тордылар. Бөтен нәрсәне төядек тә кайтырга кузгалдык. Юлда машиналар кычкыртып-кычкыртып уза. Ә безнең бару да бару! Һич төшенмибез. ГАИ тора дип кисәтүләреме соң? Бер машина безне куып узып китте дә, каршыга төшеп, туктарга сигнал бирә! Карасак – машинабыз дөрләп яна! Сәпәй тавы янында самосвал әрҗәсен бушатырга чак өлгердек! Келәмнәр, урын-җир әйберләре, балалар киемнәре... Бар да янып көлгә әйләнде! Шофер тәмәке төпчекләрен ачык тәрәзәдән ыргыта барган, җил аларны кузовка бөтереп кенә төшергән: очкыннан ялкын кабынган... Бер киемдәге кесәдә бердәнбер исән калган байлык – пар балдаклар иде! Еламадым, бәргәләнмәдем. «Менә нәрсәм калды минем!» – дип кенә әйтә алдым. Әйтерсең, коткаручы фәрештә шул балдаклар! Кем – савыт-саба, кем урын-җир белән булышты. Тормыш тагын нульдән башланды...

Ул арада көрәшче бер туганыбызга – Шакиров Әсләм абыйга бухгалтер кирәк булып чыкты. Аның «Чатыр-тау» ширкәтен оештырып кына йөргән чагы. Ризалашмыйммы соң! Иртән – ишегаллары җыештырам, өйдә – бухгалтер... Ул чакта Рушания тулай торакта комендант иде: «Әйдә безгә кил, вахтер кирәк, – ди. – Бер тәүлек эшлисе, өч көн ял итәсе», – дип ымсындыра. Яшибез болай булгач, дим. Ничек эшләвемне белеп алганнар: Гафиятов Әбүзәр абый да бухгалтерия эшенә чакырды.






Фото: Ксения Богданова

Берзаман «Тулпар» кибете хуҗасы Фәттахов Насыйх та миңа килде. Өйдә генә өч бухгалтерия эшен алып бара башладым. Башка бер кызыклы фикер килде. Нигә әле товар ташып сату итмәскә! Тик эшне башлап җибәрер өчен акча кирәк. Гомеремдә онытмам: Әбүзәр абый – 700 сум, күрше Римма апа 1000 сум акча биреп тордылар. Вахтадагы өч көнлек ялым Мәскәүгә барып товар алып кайтырга ярап кына куйды. Бөгелмәдән поездда бер тәүлек барасы, Мәскәүдән бер тәүлек кайтасы. Бер көн – чүпрәк, кием-салым җыяр өчен. Иптәшкә әни дә минем белән «челнок» булып йөри. Кайткач, базарга сатуга чыгам. Ишегалды себерергә инде җитешә алмый башладым...

Миңа кешеләр белән эшләү, аларны тыңлау, җайлаукөйләү бик ошый. Сәгатьләр буе бушлай консультацияләр бирергә дә әзер мин. «Кешеләргә артык ышанасың син», – дип шелтәләп тә куялар. Нишлим соң, табигатем шундый. Көз көне бер әби Әсәйдән ярты чиләк кишер алып килгән. Вак кына, чәнти бармак кадәрле генә кишерләре... Үлчәп карасам, 2 килога да тулмый. Әсәй тикле Әсәйдән килгән бит дип җәлләп, 12 кило дип яздым да 300 сум акча тоттырдым үзенә. Хәер булсын, дим эчтән генә. Әби: «Минем чиләк тулмаган иде бит, каян 12 кило булган ул?!» – дип аптырый. «Апа, тулган, тулган, күрмәгәнсез генә», – дим, үзем кишерләрен эшкәртү цехына җибәрәм. Минем белгән клиентларым да бар инде. Бүләктән – сөт, каймак, эремчек, Уразайдан бәрәңге китерәләр. Әлкәй, Күктәкә, Мәнәвез, Кәкре Елга, Әсәйләр кишер, суган, чөгендер, сарымсак, йомырка алып килә...

Исәп-хисап эше – бөтенләе белән минеке инде! Саннар эченә кереп чумам да дөньямны онытам. Төнгә дә калам, таң атканчы да утырам. Хәтерлисезме? «Семнадцать мгновений весны» фильмында Штирлиц йоклый, әмма нәкъ 20 минуттан ул уянасын белә инде. Шуның кебек, миңа 15 минут черем итеп алу да җитә... Төн дә димим, көн дә димим – / Алыштырам айны кояшка... Бу шигырь юлларын Рушания миңа багышлап язган иде... Рәсим генә шалтыратып искә төшерә вакытны. Гаиләдә ир аңламаса, алай эшли алмас идем. Хуҗалыкта бит әле 2 сыер асраган чаклар булды. 60 ар күркә, 100 әр каз, 40 ар тавык тагын...

Башкаларга яхшылык эшли алсам, күкләргә очам!..

Ә Ходай Тәгалә миңа барыбер көтмәгән җирдән булыша ул. Кешеләргә ярдәм итәсем, аларны сөендерәсем килә. Шуңадырмы, киңәшкә килүчеләр күп. «Бер дә борчылмагыз! Чишәлмәстәй проблемалар юк ул. Хәзер берәр юлын табарбыз», – дип әйтүем була, җиңел сулап куялар. Миннән дә бәхетле кеше юк андый чакларда. Эшем җиңел дип әйтмим. Җиңел килгән бәхет – бәхет түгел, / Эзләп тапкан бәхет кадерле!



Әниемнең догалары һәрчак булышты миңа.



ВИРА! МАЙНА!

– Ә СИҢА АНДА – ӨСТӘ КУРКЫНЫЧМЫ?

Кайда, кем булып эшләгәнен белгәч, Гүзәлгә һәрвакыт иң беренче бирелә торган сорауларның берсе бу. Кем белән сөйләшсә дә! Егерме ел эчендә ничә тапкыр ишетте икән инде ул бу сорауны?! Сокланып, гаҗәпләнеп, шаккатып... Ә җавабы исә гел бер аның: «Мин биеклектән курыкмыйм...»

Гөлнур ХӘСӘНШИНА

Сез ничек уйлыйсыз – ир-ат һөнәреме бу, әллә хатын-кызныкымы? Кран машинисты, кранчы турында әйтүем. Күпләргә – бу өлкәдән ерак торганнарга ул, әлбәттә, ир-ат эше булып тоелыр. Кранчы кызлар үзләре әнә бөтенләй башка фикердә. «Бу эшне бары тик хатын-кызга гына ышанып тапшырырга ярый!» – диләр. «Мин моны булдырам!» – дип, иң беренчеләрдән кранга үрмәләгән хатын-кыз кем булды икән ул? Тарихта исеме язылып калмаган. Беренче тракторчы Паша Ангелина заманнарында ук булгандыр инде бу хәл. «Без хәзер ир-атлар белән тигез хокуклы», – дип, гүзәл затларыбыз руль артына утырган, кулларына кувалда алган чорда ук.

Бөгелмә механика заводының 5 нче разрядлы кранчысы Гүзәл Гыйльманова да аны хатын-кыз һөнәре дип саный.

...Сигезенче сыйныфны тәмамлагач, Казан кооперация техникумына укырга керә Гүзәл, технолог булырга җыена. Укулар башлана, тик әти-әнисе яныннан беренче тапкыр шулай еракка чыгып киткән кызның күңелендә генә уку кайгысы бик тиз сүрелә. Сагына ул! Өзелеп әнисен сагына... Өйдәгеләргә бу хакта әйтергә йөрәге җитми яшь кызның, серен туганнан туган апасына ача: «Бу шәһәрдә башка бер көн дә тора алмыйм», – ди. «Аз гына сабыр ит, сеңлем, – ди апасы. – Үзебезнең училищедан белешим әле, чертежницага укырга алмаслармы икән сине?» Аннан хәбәр сала: «Кайт, барысын да хәл иттем!»

Шулай итеп, бер ай дигәндә, Казаннан кире Бөгелмәгә кайтып төшә Гүзәл. Әмма... сызым сызучы булып эшләү дә аныкы түгеллеген бик тиз аңлый ул. Артык вак эш – гомер буе кәгазьгә текәлеп, өстәл янында миллиметрлар исәпләп утырырга сабырлыгы җитмәячәк аның!

– Әни, сызым сызучы чыкмас миннән... Кызлар анда бар да кранчыга укый – кучим әле...

Әнисе, әлбәттә, каршы төшә. «Кранчы – ир-ат һөнәре бит ул. Син анда барыбер эшләмәячәксең. Укып йөреп, вакыт кына үткәрер-

ЗАМАН һәм БЕЗ


Фото: Ксения Богданова

Менә ни өчен кранчы һөнәрен сайларга кирәк дип саный Гүзәл Гыйльманова:

- тәҗрибәле кранчы беркайчан эшсез калмаячак: сирәк һәм кирәкле һөнәрләрнең берсе санала ул;
- хезмәтенә бәрабәр яхшы хезмәт хакы түләнә;
- кранчы кыз беркайчан ялгыз калмаячак: кран астында гел ир-атлар эшли – сайлап алырга һәрвакыт кемдер булачак;
- лаеклы ялга иртәрәк китәчәксез;
- аяк астын гына түгел, күзләр гел ерактагыларны да күрәчәк: борынгы акыл ияләре көн саен офыкка карау – сәламәтлек өчен файдалы, диләр;
- сирәк һөнәр иясе икәнеңне тою күңелгә рәхәтлек бирә, үз-үзең белән горурлану өчен бер сәбәп булып тора.

аның аерым детальләрен әле эшли генә башлыйлар. Аннан аларны бер-берсенә ябыштыралар. Цехның түренәрәк күчә барган саен, алар зурая, авырая. Башта ике тонналыга әйләнәләр, аннан биш, җиде, тугыз... Һәм, ниһаять, ун тонналы зур сыемнар әзер була.

Барлык детальләрне дә бер урыннан икенче урынга кран белән күчерәләр. Болтлардан калганын. «Без булмасак, цехта ир-атлар берни эшли алмый. Аларга һәммә нәрсәне без китереп бирәбез, – дип елмая әңгәмәдәшем. – Күзем гел цех өстендә: кемдер миңа күтәрелеп карый икән – димәк, аңа кран кирәк дигән сүз, шунда кузгалам».

Сүз уңаеннан: дөньядагы иң зур кран 1200 тонна авырлыкны 180 метр биеклеккә күтәрә ала.

сең», – ди. Тамчы тамып торып ташны да тишә: ярты елдан әнисен ризалата Гүзәл – кранчыга укучы дус кызлары утырган аудиториягә күченә.

– Ә үземнең беренче практикага барганчы күңелем тыныч булмады, – ди. – Группадашларым кызлар гына иде дә анысы, тик кранчы чыннан да ир-ат һөнәре булып чыкса нишләрмен, дидем. Беренче тапкыр заводка килгән көнне, ниһаять, тынычландым – кранда барысы да хатын-кызлар утыра иде.

Статистика мәгълүматлары буенча, һәр йөз кранчы ир-атка ике кранчы хатын-кыз туры килә икән. Бәлки кайдадыр андый җирләр дә бардыр, тик Бөгелмә механика заводында барысы да киресенчә бугай. Монда кранчы булып эшләүче бер генә ир-ат бар, калганнары барысы да гүзәл затлар. Ә кранчылар аз түгел аларда, Гүзәл Гыйльманова эшләгән цехта гына да, мәсәлән, унҗидәү алар.

Беренче эш көне... Әлбәттә, хәтерли ул аны! «Кранга кереп баскач, йөрәгем жу итеп, аяк табанына кадәр төшеп киткән иде. Әкренләп ияләштем. Ике дистә ел узганы сизелмәде дә менә...»

Завод цехы түбәсендә «йөзеп» йөрүче кранда эшләү, төзелештәге кранда (ул «башенный» дип атала) эшләүдән аерыла, әлбәттә. Башы болытларга тиеп торган төзелеш кранындагы кебек, берәр метрлы амплитуда белән тирбәлүләр юк рельслар буенча гына йөрүче «мостовой» кранда. Гүзәл шулай ди. Ияләшкәч, аңа юк кебек тоелса да, гаҗәп түгел. Чынлыкта, монда да шактый нык кына селкетә. Аның: «Безнең краннар биек түгел бит», дигәне белән дә килешеп бетәсе килми. Биеклектән курыккан кешегә 20–30 метры да аз түгел бит.

Гүзәлнең биеклек һәм авырлык кебек төшенчәләре безнекеннән шактыйга аерылуына шаккатырга кирәкми бугай. Бер кулы белән ун тонналы йөкне «ых» та итмичә күтәрә, урыннан күчерә бит ул!

Цехның «ТАНЕКО» нефть эшкәртү һәм нефть химиясе заводы өчен күп сыйдырышлы сыемнар әзерләүче участогында эшли Гүзәл. Аның кранынннан цех уч төбендәге кебек күренә. Аргы башта продукцияне,

Ниндидер детальләр салынган әрҗәләрне күчерү белән 10 тонналы сыемны, урыныннан кузгатып, әйтик, буярга кертү, әлбәттә, бер-берсеннән аерыла.

– Йөк авыр булганны кран да сизә – шаулап күтәрә. Дерт итеп китә... Нинди генә йөк булса да, башта мин аны идәннән ун сантиметрга гына күтәреп карарга тиеш: башка чит-ят әйберләр иярмәгәнме, ышанычлы эләктергәннәрме? Йөкнең тростан ычкынып яки өзелеп төшеп китүен күз алдына да китереп булмый... Нинди генә очракта да ул кешеләр өстенә төшәчәк. Андый фаҗигадән Ходай үзе сакласын... Миңа берничек тә ялгышырга ярамый!

Барысы да тәртиптә икәненә инангач, әкрен генә кузгалам. Ир-атларга: «Миңа карап тормагыз», – дим. Йөкне илтеп урнаштыргач кына маңгаеңнан елга булып тир агуын тоясың. Аны сөртеп аласың да, җиңел сулап куясың. Һәрвакыт шулай...

Гомумән, йөкне күтәрдем дә «йөгердем түгел». Ул бит әле әйләнә башларда да мөмкин. 7-8 яки 9–10 тонналы йөкнең троста әйләнә

башлавын күз алдына китерегез – бөтен нәрсәне ватып, җимереп бетерәчәк. Шуңа күрә аста кемдер берәү озын бау белән йөкне арттан тотып бара. Йөк аз гына борыла башласа да, мин тизрәк туктыйм.

Бездә һәркем – слесарьлар да, эретеп ябыштыручылар да «стропальщик»лар: йөкне кранга эләктерергә рөхсәт кәгазьләре бар. Аларга йөкне бер урыннан икенче урынга көнгә әллә ничә тапкыр күчерергә туры килә – эш беткән саен, завод буйлап махсус кешесен эзләп йөри алмыйсың бит.

Кранчы булырга теләгән яшьләр хәзер үзләре акча түләп укый.

Мин күтәреп барганда йөк астына кем дә булса керү? Юк, бездә андый хәл беркайчан була алмый! Заводта куркынычсызлык кагыйдәләре бик төгәл үтәлә. Йөкне күчерә башлауга: «Сак булыгыз!» – дип сигнал бирәм. Аны ишетмиләр икән – кычкырам: шунда ук барысы да борылып карый. Беләләр – тик торганнан кычкырмыйм бит мин.

Кранчыларның җирдәгеләр белән үз телләрендә сөйләшүеннән һәркайсыбыз хәбәрдар инде без. Йөкне өскә күтәрәсе булса – «вира», аска төшерәсе булса «майна», диләр. (Сүз уңаеннан: итальян архитекторларыннан безнең телгә кереп калган терминнар бу. Алар кайчандыр Россиядә күпләп эшләгәннәр, төзүчеләр белән исә үз телләрендә идарә иткәннәр.) Гүзәл исә бу сүзләрне бик сирәк кулланам ди. Ул эшләгән цехта нинди тавыш икәнен исемә төшерәм... Тоташ гүләү! Гел кычкырып торсаң, бер смена дәвамында тавышсыз калырсың! Йөкне кранга эләктерүчеләр белән ул, гадәттә, кул ишарәләре ярдәмендә аралаша: уч төбе кайсы якка таба хәрәкәт итә – кран шунда барырга тиеш. Тимер тузанына, майга чумып пычранган кулларда уч табаны күренмәгән чаклар – аерым очрак.

Тавыш дигәннән, аның эшендәге тискәре якларның берсе инде бу. Гүзәл мине алдан ук кисәтеп куйды: «Мин кычкырып сөйләшәм, – ди. – Сменадан кайткач, өйдәгеләр гел: «Әкренрәк сөйләш», – дип әйтеп торалар. Үзем сизмим дә... Иртән, колаклар ял иткәч, кухняда телевизорны ачам да, аптырап китәм кайчак – кичтән шулкадәр тавышын кычкыртып куеп тыңлаганмын бит. Әтиләргә баргач, ул да миңа гел: «Ипләбрәк сөйләш әле, кызым. Күршеләр талаша дип уйлар», – дип кисәтү ясап кына тора. Нишләтәсең, безнең профессиональ чир инде...»

Төзелештәге краннардан аермалы буларак, Гүзәл эшли торган «мостовой» кранның кабинасы юк. («Безнең кран кабиналы була да алмый: бертуктамый башны тыгып, кабина астына карарга кирәк. Шуңа күрә кабиналы, кондиционерлы кран турында хыяллана да алмыйбыз», – ди Гүзәл.) Җәен кранчы кызларга – эссе, кышын – салкын. Цех эчендә һәрвакыт үтәли җил йөри. Еш тому төшү, суык тию – һөнәри чирләренең тагын берсе.

Заводта һәр минут исәпле. Беренче смена иртәнге җидедә килә. Тугыз тулгач – унбиш минут тәнәфес. (Тәнәфес вакытында цехта тынлык урнаша: утлар сүнә, станоклар туктый.) Сәгать унбердән уникегә чаклы – төшке аш. Көндезге ике тулгач – тагын 15 минут тәнәфес. Сәгать дүрттә Гүзәл сменаны кулалмашларына – Гөлфиягә яки Любага тапшыра. Калган вакытта ул краннан төшәргә тиеш түгел. Теләсә кайсы минутта берәрсенә кирәге чыгуы бар. (Һәм киресенчә: электрик һәм слесарьлардан кала, аның янына кранга берәүгә дә менәргә ярамый!) Кул астында термосы – буш ара чыкса, чәй дә эчеп ала. Кабина түрендә – кечкенә генә көзге: хатын-кызлар эшләгән җирдә ансыз булмый!

– Ә кран ватылса нишлисең? – дим. – Цех түбәсендә – һавада эленеп калсаң?

– Андый хәлләр дә булгалый, – дип елмая Гүзәл. – Детальләрен – тросны, двигательне, редукторны алыштырып торсалар да, краннар үзләре яңа түгел инде. Йөк белән булсам, бик тиз килеп җитәләр. Ярты сәгатьтән артык көтмим. Башка җирдә мөһимрәк эшләре булса, электриклар башта мине «стоянка»га илтеп куя – кранны соңрак ремонтлыйлар. Ә мин бүтән кранга күчәм.

«Иң авыры төнлә эшләү», – ди ул. Хатын-кыз: «Төнге сменадан кайттым», – дип өйдә ятып кына тора алмый бит әле. Иртәнге алтынчы яртыда ире Илдар эшкә китә. (Башка күп кранчы кызларныкы кебек үк, аның да ире шушы ук заводта эшли.) Илдарны озатуга, улы Вилданның мәктәпкә барыр вакыты җитә. Бераздан алар кире кайта башлыйлар. Аннан инде Гүзәл үзе эшкә җыена. Быел исә беренче оныклары мәктәпкә укырга керә – аны каршы алу мәшәкатьләре дә өстәләчәк.

Тыңлыйм-тыңлыйм да, кранчы миңа инде иң авыр һөнәр булып тоела башлый...

– Алай түгел! – дип рәхәтләнеп көлә Гүзәл. Аннан җитдиләнеп дәвам итә. – Гомерне әр-яңадан башлыйсы булса, мин, мәсәлән, кабат кранчы гына булыр идем. Заводта эшләү, гомумән, дәрәҗә санала бездә. Хезмәт хакларыннан зарланмыйбыз. Ике елга бер тапкыр шифаханәгә җибәрәләр. Балаларга җәйге лагерьга юллама алырга була. Сәламәтлегебезне гел тикшереп торалар. Елга бер тапкыр махсус кием-салым бирәләр. Өстәмә алты көн ял итә алабыз... Юкка авыр һөнәр дип санийсыз, эш күп булган көннәрне сменаның тәмамланганын да сизми калам. Соңгы вакытта 4 июньне Кранчылар көне дип бәйрәм итә башладык. Эретеп ябыштыручы, токарь, мастерларга кызыгып карый идек, инде менә безнең дә көнебез булды. Дөрес, рәсми рәвештә бәйрәм ителми әле. Кызлар белән ул көнне ватсапта бер-беребезне котлаштык. Күңелле булып китте...

...Кранчының булдыклылыгын, беләсезме, ничек тикшерәләр икән? Әгәр ул сулы чиләкне җирдән ыргак белән күтәреп алып, бер тамчысын да түкмичә кире куя алса, димәк, ул инде үз эшенең остасы санала! Алар цехында кранчы кызларны берәү дә болай сынарга җыенмый, әлбәттә. Булдырганнарын болай да беләләр.



Чәчәкле күлмәктән, ак яулыктан иртүк җиләкле болында ул. Тик кулында кәрзин дә, чиләк тә түгел... чалгы! Их бу тынгысыз җанны! Шушы болынга кунак кызы кебек җиләккә генә йөрергә тиешле зат та бит югыйсә. Хәер, анысына да өлгерер. Җиләксез була димени инде? Җиләк вакыты бер генә дисәләр дә, авыл халкының йокыларын калдырта торган уттай печән өсте бар бит әле монда. Тизрәк чабарга, киптерергә, чүмәләгә өяргә, ихатага алып кайтырга булсын безгә! Менә шундый инде ул хатын-кыз! Ирләр белән бер рәткә басып печәнен дә чабабыз, алар ял иткәндә җиләген дә җыябыз. Болыннан кайтышка мең мәшәкать күтеп тора тагын... Хатын-кыз эштән туктаса, дөнья туктала. Кай җиреннән – этеп, кайсысыннан – тартып, кайда – йолкып, кирәк икән – юмалап, без тартабыз тормышны. Ирләр белән рәттән тартып алып барабыз. Күп вакыт алданрак та атлыйбыз әле...

Лилия ГӘРӘЕВА.
Фото: автор.

«ӨЙРӘТ МИНЕ...»

«Тормышта барысы да тигез генә, шома гына барырга тиеш диган беркатлы ышанудан арала... Иң кирәк чакта хакыйкатьне күземә карап (әмма миңа яхшылык теләп!) әйтә алырлык кешене юлыма чыгар... Йөрәкнең акыл белән бик еш бәхәсләшергә яратуын исемә төшереп тор... Үземә үзем теләгәнне түгел, чынлыкта минем өчен нәрсә мөһимрәк, дөресрәк – шуны җибәр... Кечкенә адымнар белән алга атлау серенә төшендер мине...» Иң авыр чакларда тукталып калмаска, алга таба атларга Антуан де Сент-Экзюпериның шушы юллары булышты, ди ул. Җан авыртуыннан йөгереп качып, җиңел генә, тиз генә котыла алмыйсың: иң мөһиме: кечкенә, вак адымнар белән булса да, һәр көнне иртәгәгә таба атларга кирәк. (Тормышның теләсә нинди сынавы алдында калганнарга да иң беренче киңәше шул аның: кеше яхшылыкка, яктылыкка ышанырга тиеш. Болытлар артында кояш барына! «Ул чакта сынауларның вакытлыча гына булганын әйтүче табылса, аларны кичерү миңа күпкә җиңелрәк булыр иде», – ди.)

Әмма кул сузымы кебек бик якын да һәм бер үк вакытта чиксезлек кебек ерак та тоелган әнә шул «иртәгәгә» ничек, нинди сукмаклардан барып җитәргә соң? «Интуициягә таянырга кирәк, – ди ул. – Аллаһы Тәгаләнең безгә нишләргә кирәк икәнен җан сиземләвебез аша аңлатуына күптән ышандым инде. Шуның бер юлы – без күргән төшләр...» Хәер, барысын да әңгәмәдәшем Гөлнара САГИЕВА (фотограф, Татарстанның атказанган матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр хезмәткәре, «Бәллүр каләм» бүләге иясе) үзе сөйләсен әле.

Гөлнур
САФИУЛЛИНА



Суд бинасыннан чыгып, икебез ике якка ят кешеләр булып атлап киткән мизгел... Ул чакта нинди халәттә булганымны хәзер дә аңлата алмам, аны үз башыннан кичергәннәр генә белә... Кирегә инде юл ябылды. Гәүдәңнең бер әгъзасы, кулың яки аягың юк дип күз алдыңа китер – яра бәгыреңә төшеп әрни, һәм аны басарлык бернинди дару уйлап табылмаган. Мин ул көнне судтан соң машинама утырдым да китеп бардым. Кая барам, нигә барам, белмим... Аңыма килеп тирә-юнемә күз салганда, шәһәр күптән артта калган иде инде. «Раифа монастыре» дигән язу күзгә чалынды. Нигәдер шунда борылдым. Февраль ахыры иде әле – күл кар астында, әмма шул тынлыкта туңганчы басып торгач, йөрәккә мең энә булып кадалган әрнү беркадәр басылды... (Эчтә, күкрәк тирәсендә авырту күтәрелә башлаганын сизгән чакларда, мин соңыннан да гел Раифага бара торган булдым. Күл буенда суга карап утырам. Аннан чәй эчәргә керәм. Икмәк сата торган кечкенә генә кибет бар анда. Берсендә шундагы сатучы хатын белән сөйләшеп киттек. «Нишләргә белмим... Сорауларыма җавап тапмаммы дип килгән идем, булмады...» – дим. «Алай булса, ниндидер карарга килергә ашыкма», – диде ул миңа. Бер белмәгән кешеләр ярдәм итте миңа ул чакта: кем – киңәше, кем – җылы сүзе, ә кем җылы карашы белән... Шул вакытта күргән төшләремнең берсе менә: мине ниндидер коточкыч җанвар әзәрлекли. Исән каласым юк икән дип уйлыйм. Һәм каяндыр кемнеңдер тавышын ишетәм: «Авырту, әрнү аша ялгышлардан котылабыз...» Аерылышкан хатын-кызлар мине аңлар: никахыбыз таркалуга күп вакыт без үзебез дә гаепле булабыз. Әмма үз ялгышларыңны күрү күпкә авыррак... Күкләр миңа шуны әйтергә теләгән, тик күзләрем соңрак ачылды шул.)

...Ә бит барысы да шундый матур башланган иде. Ирем белән бер-беребезне бишенче сыйныфтан бирле беләбез. Унөч ел бергә яшәдек. Кызыбыз үсә. Икебез дә иҗат белән шөгыльләнәбез. Тик холыкларыбыз төрле, шуның аркасында гел газапланабыз. Дуслык – бер нәрсә, ә гаилә корып яшәү – башка шул... Торып калсак, бер-беребезгә яраклашып беткән булыр идек тә... Ирек яратуым да үзенекен итте. Миңа бит иркенлек, киңлек кирәк, шуның өчен бик еш кына ялгызым Чулман буена чыгып китә идем. Яр өстендә басып торам. Җил, су, һава... Менә ул минем стихия! Кыскасы, берсүзсез иремә буйсына алмадым, зирәклек җитеп бетмәде. Бүгенге акылым булса, үземне башкача тотар идем, билгеле. Тик яшь идек бит... Аннан, ул гел кешеләр арасында, ә мин өйдә идем... Әйе, безнең өлешкә сынауларның башкалары да төште шул. Казан төзелеш-архитектура институтын тәмамлап диплом алган вакытым туксанынчы елларга туры килде. Эш юк! Проектлау институтларын йөреп чыктым – алмадылар. Аннан кызыбыз укырга керер чак җитте: аны мәктәпкә озатасы, каршы аласы... Тагын өйдә, дүрт стена арасында калдым. Эш таба алмау, кирәксезлегем үземә үзем биргән бәяне шактый төшерде. (Җитмәсә, ирем адым саен: «Глобаль итеп уйлый белмисең», – дип битәрләп тора.) Хатын-кызга эшсез калырга ярамаганлыгын кияүгә чыкканчы ук аңлый идем: ни булмас?! Дөньяда аерылышу гына түгел бит, төрле хәлләр бар... Ял көннәрендә дус кызым белән очрашканда үлеп аңардан көнләшәм: шимбә-якшәмбе димиләр, аңа гел эшеннән шалтыраталар, нидер сорыйлар, киңәшләшәләр... Ул: «Туйдым! Арыдым!» – дип зарлана, ә мин аңа кызыгам...

Борчулы чакта кеше югалып кала, моңарчы белгәнен дә оныта – юл күрсәтүче кирәк.

Ирем белән аерылышканчы ук фотограф буларак беренче адымнарымны атлаган идем инде. Шулай дип әйтергә яраса... Буш вакытыгыз күп дип, мине ата-аналар комитетына сайладылар. Балалар белән стена газеталары чыгарам. Минем дә кирәгем чыкты – рәсем ясыйм! Аннан тормышка компьютерлар үтеп керә башлады. «Кулдан ясап утырыр чак узды, – дим класс җитәкчесенә. – Замана техникасын белүчеләр безнең балаларның әти-әниләре арасында да бардыр». Ул мине «Сөембикә» журналының җаваплы сәркатибе Лариса Маликова белән таныштырды. Беренче тапкыр «Идел-Пресс» бинасына – аның эш урынына килгәнемне хәтерлим. Ишекне ачып керүгә үк ошады миңа монда. «Биредә эшләр идем!» – дим Ларисага. «Ә нәрсә эшли беләсең?» – диде ул. «Белмим... Әмма теләгем бик зур!» Җавабым сәеррәк яңгыраса да, ул минем үтенечемне онытмаган икән. Икенче килүемдә «Ялкын» журналы редакциясенә, рәссам Зифа Мөхәммәтҗанова янына кертеп җибәрде. «Менә шушы шигырьләргә фотошопта рәсем ясарга кирәк», – ди Зифа. «Фотошоп» сүзен беренче тапкыр ишетүем! Әмма эчемнән уйлыйм: «Белмәгәнемне сиздермим! Ничек тә өйрәнермен!» Югалып калуым барыбер йөземә чыкты бугай. Ишеккә җиткәч, мине кабат туктаттылар. «Безнең бит вакыт чикле, – ди Зифа. – Сезне ничек табарга? Телефоныгызны язып алыйм әле». Минем фамилиям исә аңа нигәдер бик таныш тоелды. «Рәсемегез безнең тышлыкта чыкты бит!» – диде ул исенә төшергәненә сөенеп. Минем рәсемем яшүсмерләр журналында?! Юк, мине монда кем беләндер бутыйлар! Бераздан барысы да ачыкланды. Әйе, рәсемем чыккан, дөресрәге, мин төшергән рәсем. Лариса тәкъдим иткән булган икән. Кызларыбыз укыган сыйныф укучылары кая барса да, мин алар белән бит, ә кулымда исә һәрвакыт фотоаппарат. «Ялкын» тышында – шул рәсемнәрнең берсе. «Фоторәсемнәрегез тагын бармы?» – ди Зифа. «Бик күп!» – дим. «Алып киләсезме?» Ничек алып килмим – очтым гына! Ул мине редактор янына таныштырырга ук алып кереп китте. «Яңа фотограф таптым! – ди. – Ә фотошоп турында онытыгыз, анысын башка берәүгә тапшырырмын». Мин – фотограф?! Кызык!

Фото: Наил Зыятдинов

Шул көннән башлап «Ялкын»нар миңа эш бирә башладылар.

Ә аннан без ирем белән аерылыштык... (Бу урында тагын бер төшемне сөйлим әле. Каяндыр ашыгып өйгә кайтып кердем. Һәм кинәт фатирыбыз диварында ишек күреп алдым! «Ни гомер яшәп, бу ишекнең барлыгын ничек белмәгәнмен?!» – дип шаккаттым. Шикләнебрәк кенә ишекне ачтым. Ә анда... анда иркен, якты бүлмә, болыт кебек җиңел пәрдәләрне җилфердәтеп, ачык тәрәзәләр аша җиләс, рәхәт җил исеп тора... «Минем монда яшисем килә!» – дигән уй белән уянып киттем. Бу төшемне нигәдер шактый соңрак искә төшердем. Нигә шунда ук юрый белмәгәнмен дип бик үкендем инде. Тормышыңда үзгәрешләр көтелә, курыкма, барысы да әйбәт булачак, дип әйтергә теләгәннәр ләбаса миңа!)

Тынычланып, йөрәгеңне тыңласаң, ул барысын да үзе әйтә...

Иң авыры беренче ел булды. Еллар буе төзелгән мөнәсәбәтләр җимерелгәндә, әлбәттә, кыен. Сез бит моңарчы бербөтен идегез. Ул китте дә, син ярты гына булып калдың. Алдыңда ике юл: йә бертуктамый елап, үз-үзеңне җәлләп кенә утырасың, йә шул бушлыкны тутырырга керешәсең. Мин икенчесен сайладым.

■ Мондый чакта үзеңне нәрсә белән булса да шөгыльләнергә мәҗбүр итәргә кирәк. Уйларны читкә юнәлтү өчен. Башта фатирны алыштырдым. Бөтен нәрсә аны хәтерләткән диварлар эчендә яшәү көн саен үземне газаплау белән бер иде... Яңа фатирга ремонт ясау мәшәкатьләренә кереп чумдым.

■ Дус кызлар белән аралашудан берничек качарга ярамый. Әмма бертуктаусыз үзеңнең проблемаң турында сөйләшмәскә кирәк. Мине хәтта аларның: «Әгәр тагын бер тапкыр ireңнең исемен әйтәсең икән, торабыз да китәбез», – дип туктатканнары да булды.

■ Спорт! Миңа нәрсә иң нык ярдәм итә. Мин ул чакта бассейнга да йөрдем, тренажерларга да. Хәлсезләнеп егылганчы шөгыльләнгән вакытларым булды. Хәзер дә, берәр проблема туса яки кемдер авыр сүз әйтеп үпкәләтсә, хәтерне калдырса, спортны искә төшерәм. Бер-ике сәгать шөгыльләнсәң, барысы да уза – ул кешеләргә күңелемнән рәхмәт укый башлыйм.

■ Эш! Менә нәрсә коткарды мине! Ирем белән торганда әле мавыккан гына булсам, аерылышкач, фотограф һөнәренә чатырдап ябыштым. Темалар табам да: «Ә фотога үзем төшерәм», – дип, редакцияләргә тәкъдим итәм. «Казань» журналына да шулай барып кердем. Аның баш мөхәррире Юрий Анатольевич Балашов белән озак кына сөйләшеп утырдык. Кинәт башыма суккандай булды: аңламый да торам – ул бит мине эшкә чакыра! Шунда ук: «Риза!» – дип җавап бирдем.

Редакциягә эшкә килгәч, минем өчен тормышның башка яклары ачылды. Журнал геройлары, аларның язмышлары белән якыннан танышу, аралашулар, әлбәттә, эзсез уза алмый. Никадәр күренекле шәхесләр, эшләре, иҗатлары белән ил-көнгә мәгълүм кешеләр белән очраштырды мине фотограф һөнәре! Әмма иң зур ачышым – үзем булды. Мин дә төшеп калганнардан түгел икән бит! Моңарчы үземне күрсәтергә җай гына чыкмаган. Сәнгать мәктәбен тәмамлавым, геннарым (рәссам Илдар Зарипов әнием белән бертуганнар), архитектура буенча алган белемем беркөн тышка бәреп чыкты – фотосурәтләр булып. Әллә нәрсә эшләмим дә кебек, фотосурәткә генә төшерәм, ә тирә-юнемдәгеләргә ошый!

Аз гына кәефем төшкәнне сизсәләр, редакциядә шунда ук эшкә күмделәр ул чакта мине. Тын да алырга вакыт калмаслык итеп! Гел онытмыйм, инвалидлар турында бер сан әзерләдек. Бер үзәккә фоторепортаж әзерләргә җибәрделәр. Коляскадагыларны төшердем, алар гел шаярттылар, көлдерделәр. Соңыннан миңа: «Ә беләсезме, иң күп мәзәк сөйләгән ир-атның ике ай гомере калды», – диделәр. Үземнең күз яшьләрем өчен миңа оят иде...

Тормышта бар нәрсә дә уза... Бу көннәр инде күптән артта калды, мин алар хакында хәзер тыныч кына сөйли алам. Кызым да үсеп буй җитте. (Дөрес, бала тулы гаиләдә үссен өчен, бәлки, безгә соңрак аерылышырга кирәк булгандыр дип уйлыйм кайчакта. Әмма анысын инде аның кем белә?!) Ул Мәскәүдә яши, менә дигән эшкә урнашты. «Үзеңнән еракка җибәргәнсең», – дип әйтүчеләр бар. Мәскәү белән Казан арасы бүгенге дөнья өчен еракмыни ул?! Барлык әниләр кебек мин дә баламның бәхетле булуын телим. Хатын-кыз буларак мин кичергән сынаулар аны әйләнеп узса иде!..

...Диңгез яры. Иксез-чиксез су дәрьясына карап, артлы урындыкларда икәү утыралар. Янәшә урындыктагы кешенең йөзе күренми. Гөлнара аның үзе өчен бик якын, кадерледән-кадерле берәү икәнен җаны, йөрәге белән генә тоя. Рәхәт... Бик рәхәт... «Кечкенә адымнар белән алга атларга өйрәт мине», – дип пышылдый ул.

Гөлнараның тагын бер төше бу. Әлегә чынга ашмаган төше.

Әлегә!



ХАТЫНЫМ АВЫЛГА КАЙТМЫЙ

«Атна ахыры җитсә, безнең өйдә тавыш чыга. Сәбәбе: хатынымның авылга – әни янына кайтасы килми. Өйләнешкән генә елларда болай түгел иде ул. Атна ахыры җиттеме, авылга җыена идек. Анда мең төрле эш көтеп тора: тиресен чыгарасың, печәнен чабасың, көтүенә чыгасың... Хатыным – шәһәр кызы, аны ишегалды, абзар тирәсендә йөртмәдек, ул өйдәгесен карап, ашарга әзерләп, әнигә булышкалап йөрде. Авыл һавасын, авыл мунчасын ярата да кебек иде. Ник хәзер үзгәрде ул – аңламыйм. Әни дә картайды, кайтып булышмыйча булмый. Миңа үземә генә кайтып килүе берни дә түгел анысы, инде печән чабып, тирес чыгарып йөрисе юк, әни терлекләрен күптән бетерде. Без парлап кайтып, бергәләп чәй эчеп, мунчасын кереп, аз-маз эшен карашсаң, ул шуңа да бәхетле. Әниләре кайтмагач, балаларның да кайтасылары килми. Хатыным белән сөйләшеп тә караганым булды. «Синең туганнарга беркайчан да минем кирәгем булмады. Эшләгән эшемне дә ошатмадылар. Шәһәр кызы эшләгән эш, дип, мыскыллап көләләр иде», – ди. Ялгыз каз кебек йөрүе әни алдында да, күршеләр алдында да читен.

Рамил С.
Чаллы шәһәре».

♀ **Нурия Гатина, 43 яшь:**

Мин инде 18 ел килен. Әтиәниләребез күрше авылларда яши. Бер кайтканда иремнең әти-әнисенә керергә дә, безнекеләргә дә җитешәбез. Соңгы вакытларда кайнана-кайната янына кайтасым килми башлады. Яшьрәк вакытта игътибар ителмәгәнме, шулай тиеш дип кабул ителгәнме – нәрсә генә эшләсәм дә кайнанама ошамый икән бит. Бер-ике генә мисал: кайнанам без кайтышка шулпа куеп, ашны булдырып тора. Аш бүлүне миңа тапшыралар. Ләкин ничек кенә бүлсәм дә, кайнанама ярап булмый. Куерак итсәм, артымнан чүмеч белән шулпа өстәп йөри. Сыеграк бүлсәм: «Бер дә токмачын салмагансың бит», – дип, токмач китереп сала. Кискән ипидән дә гаеп таба. Чәй ясау – монысы инде бөтенләй бер фәнни эш сыман. Чәе яхшы икән әле, шуны гына ясыйм, дисәң, монысын ташла, дип, ташлаттыра. Икенче юлы яңаны пешерим дисәң: «Бая гына пешергән идем бит, ник аны түгәсең?» – ди. Куе ясасаң – чифир иткәнсең, сөтен күбрәк салсаң – «Мәскәү күренә»... Анда кайтсам, нәрсәне гаеп итәрләр дип, гел киеренкелектә торып арып бетәм, шуңа да кайтмый калу җаен эзлим.

♂ **Зөлфәт Зиннуров, 36 яшь, җырчы, шоумен:**

Хатыным белән гаилә коруыбызга 8 ел. Ике якны да тигез күрергә тырышабыз. Күз тия күрмәсен, әни килене белән уртак телне тиз тапты. Һәрнәрсәне киңәшләшеп эшлиләр. Берәр нәрсә булса, әни гел Гөлназ ягына баса.

Әнием белән хатының уртак сүзгә килә алмасалар, яшәве кыендыр ул. Тавышка кала икән, иң яхшысы – аларның күрешми яшәве. Хатын авылга кайтып, әни белән әрләшеп, бер-берсеннән гаеп кенә табалар икән, үзем дә аны алып кайтып, әнинең йөрәген боздырмас идем.

Ләкин яратмауның да ниндидер сәбәбе була. Димәк, сүз ишеттергәннәр, эшен килештермиләр... Бу очракта уртага салып сөйләшеп караргадыр, бәлки. Олы кешегә дә үзен олыларча тотарга, яшьләрдән акыллырак булырга кирәк. Дуслашуга беренче адымны ул ясаса да ярый. Һичьюгында әнинең үзен шәһәргә алып килергә була. Хатын белән икесенә концертка билет аласың да... Яисә Коръән ашы укытасың. Ә мулла белән алдан ук сөйләшеп куясың: «Әни белән хатын тату түгел. Шул темага вәгазь сөйлә әле», – дисең.

Өч фикер



Ләлә БӘҺРАМШИНА, психолог

– Бу ситуацияне дүрт яссылыктан карарга кирәк. Беренчесе – хатын. Ул кайнанасы янына кайтып, аңа булышудан баш тарта. Сәбәбе билгеле кебек: эшен тәнкыйтьлиләр, булдыксызлыкта гаеплиләр. Гаҗәп түгел: ул шәһәр кызы, авыл тормышын белеп тә бетерми. Ә бит моны хатын-кызның иренә булган мөгамәләсенең көзгедәге чагылышы дип тә уйларга була. Авыл егете дә шәһәр тормышын баштарак белеп бетермәгәндер. Хатын үзен ничек тотты икән соң, ирен тәнкыйтьләмәде, аны булдыксызлыкта гаепләмәде микән? Бәлки, ул да аны аңлап бетермәгәндер, кайдадыр ярдәм итеп, булышып җибәрәсе, кечкенә генә уңышларын да күреп үсендерәсе булгандыр... Тормышта нәрсәнедер үзгәртәсең килә икән, иң элек аңа мөнәсәбәтеңне үзгәртергә кирәк. Бу очракта хатын-кыз иренә мөнәсәбәтен үзгәртергә тиеш. Шушы гамәле белән ул бит аның нәсел тамырларын ихтирам итмәвен белдерә. Югыйсә кайчандыр ул бу егетне үзе сайлаган, аның әти-әнисен дә кабул итәргә риза булган. Тамырларыннан өзеп, ул ирен яшәү энергиясеннән мәхрүм итә.

Парлы мөнәсәбәтләр өч ноктага таяна: аралашу, симпатия, уртак шөгыль. Уртак шөгыль ул – фатир да, балалар да, әтиәниләр дә... Хатын, моннан читләшеп, гаилә мөнәсәбәтләрен куркыныч астына куя. Аралашу һәм симпатия җитәрлек булганда гына бу гаилә сакланып кала алачак.

Хатынына булган тәнкыйтьне ир кеше дә күргәндер бит. Ул аның шәһәр кызы икәнен белә, авылдагы бөтен эшне дә кечкенәдән өйрәнеп үсмәгәнен аңлый. Шулай булгач, ул әнисе, туганнары белән җайлап кына сөйләшергә, аларга аңлатырга тиеш иде.

Килен кайнана туфрагында үсә, диләр. Аңа карата әни кешегә дә йомшаграк булырга, аның тырышлыгын күрергә кирәк булгандыр. Килен ул – балаңны яраткан кеше, газиз оныкларыңның әнисе.

Дүртенче яссылык – балалар. Алар – нәсел агачының җимешләре. Әти-әни – ул агачның кәүсәсе, әби-бабалар тамыры. Тамырларда – нәсел көче. Аннан өзелгән балалар яшәү көчен кайдан алырга тиеш?

ТАТАР, ДӨНЬЯНЫҢ НИНДИ ГЕНӘ ИЛЕНӘ БАРЫП ТӨПЛӘНМӘСЕН, КАЙСЫ ГЫНА ХАЛЫК АРАСЫНА КЕРМӘСЕН, ҺӘРВАКЫТ БЕР АДЫМ АЛДА, БЕР БАСКЫЧ ЮГАРЫДА БУЛЫРГА ОМТЫЛА. МОҢА МИСАЛЛАР ШАКТЫЙ.

Бүген сезне күпкырлы талант иясе – спортчы, театр һəм кино артисты, язучы һəм журналист Лалə ОРАЛОГЛУ белəн таныштырасым килə.



Рушания АЛТАЙ









«САРЫ ГӨЛЕБЕЗ...»

Лалə ханымның əтисе Əхмəтлəбиб ага Каран табиб була, Төркиягə беренче бөтендөнья сугышыннан соң килə. 1950 нче елларның башында Лəбиб Каран оештырган «Сөембикə» татар җəмгыяте (Төркиядəге беренче татар оешмасы!), гомере озын булмаса да, миллəттəшлəребезне бер учак тирəсенə җыйнауга, татар миллəтен, тарихын, гореф-гадəтлəрен таныту һəм саклауга хезмəт итə. Лəбиб ага гаилəсендə дə татарлыкны саклауга зур игътибар бирə: туган халкына мəхəббəтне кызлары Лалə белəн Чулпанда тəрбиялəргə тырыша.

Бер əңгəмəсендə Лалə ханым əтисенең аны Сөембикə кебек үстерергə телəвен əйтə. Сөембикə кебек, ягъни көчле рухлы, зирəк, уңган-булган, тырыш... Юкка гына Лəбиб абзый кызын Төркиянең иң абруйлы француз һəм алман мəктəплəрендə укытмаган. Лалə тырыш, сəлəтле бала булган, күрəсең: 7 яшендə пианинода уйнарга өйрəнгəн, биеклеккə сикерү һəм ишкəк ишү кебек спорт төрлəре белəн профессиональ дəрəҗəдə шөгыльлəнгəн. Ишкəк ишү буенча ул җитəклəгəн төркем җиде ел рəттəн Төркия чемпионы исемен яулый. Лалə бигрəк тə йөзəргə ярата һəм спортның бу тарма-

гында да сынатмый: 100 метрга чалкан йөзүдә, 200 метрга кроль стиле белән йөзүдә Төркия чемпионы исемен алуга ирешә. 400 метрга йөзү буенча да берничә тапкыр ил чемпионы була. 1951–1958 еллар арасында сикерү буенча бәйгеләрдә алдынгы урыннар яулый: алты – алтын, ике көмеш медаль ала.

Лалә Каран Истанбул университетының инглиз филологиясе бүлеген тәмамлый. Инглиз, немец, француз, итальян телләрендә иркен аралаша. Югары уку йортын тәмамлагач, күп телләр белгән кызны «Япы Креди» банкына эшкә чакыралар – ике ел анда эшли. Ләкин сәнгать аны үзенә күбрәк тарта – ул консерваториягә укырга керә. Бер үк вакытта опера театры курсларына йөри. Соңрак консерваториядә укыта башлый: фортепиано һәм вокал дәресләре бирә.

Әнисе Лаләнең артист булуын хупламый, шуңа күрә кыз сәхнәдән ераграк торырга тырыша. Әмма кияүгә чыккач, барысы да үзгәрә: журналист ире аның сәхнәгә чыгу теләгенә каршы килми, киресенчә, хуплый гына. Нәтиҗәдә, Лалә ханым Төркиянең атаклы артистларының берсенә әверелә. 1951 елда беренче мәртәбә «Ярыш» пьесасында уйнап, чыныгу ала. Төркиянең «театр атасы» – чорның иң мәшһүр артисты Мүһсин Эртугрул аның талантын югары бәяли. Милләттәшебез соңыннан театр сәхнәсендә генә түгел (20 ел эчендә ул 62 спектакльдә уйный!), кинофильмнарда да төшә башлый – 35 фильмда төп рольләрне башкара.

1961 елда үз театрын оештыра. Ире фамилиясен йөрткән Лалә театрының исемен дә «Оралоглу» дип атый. Бу коллектив Төркия театры тарихында профессиональлеге белән тирән эз калдыра. Лалә һәм аның ире әлеге иҗат коллективын булдыруга гына түгел, аны югары баскычка күтәрү өчен дә байтак көч сарыф итәләр. Төркиянең иң күренекле, иң талантлы артистларын җәлеп итеп, һәм төрек, һәм чит ил авторларының пьесаларын сәхнәләштерәләр. Кыска вакыт эчендә «Оралоглу» театры киң танылу ала, абруй казана. Аның үз традицияләре, үзенә генә хас алымнары, тамашачы белән эшләү серләре барлыкка килә. Труппа Төркиянең бер сәнгать әһеле аяк басмаган, халык җанлы театрның нәрсә икәнлеген белмәгән иң караңгы районнарына кадәр барып чыга, тәүлек эчендә өчәр спектакль уйный.

Шәхси театр булгач, дәүләттән бер тиен ярдәм көтә алмыйлар: коллективта эшләүче һәркемгә лаек хезмәт хакы түләү, сәхнә чыгымнарын каплау зур тырышлык таләп итә. Труппа ил буенча гастрольләрдә йөри, көннән-көн танылуы арта: кайсы шәһәргә яки районга барма, бөтен җирдә «Оралоглу» театрының афишаларына тап булу гадәти күренешкә әйләнә. Кайберәүләрнең көнләшүенә шушы сәбәп була да инде. Лалә ханымга аяк чалулар башлана…

1974 елда театр Төркиянең көньяк-көнчыгыш районнарында спектакльләр күрсәтеп йөргәндә, Агры районы җитәкчелеге, алдан төзелгән килешүгә карамастан, труппаның ул көнге тамашасын халыкка ирештерү өчен көтелмәгән шартлар куя. Лалә Оралоглу моның килешүгә дә, канунга да туры килмәвен әйтеп, ул шартларны үтәргә ризалашмый… Кире кайтып китәр алдыннан, коллектив белән Агры шәһәрен карап әйләнергә уйлыйлар. Шул вакыт аларны бер кибеткә алып керәләр. Лалә ханым кибеттә чәй сервизы сатып ала. Ә юлда автобусларын полиция туктата һәм тикшерә башлый. Лалә Оралоглуның затлы тартмага салынган чынаяклары «Төркиягә рөхсәтсез кертелгән мал» дип бәяләнә (ул елларда мондый хәл Төркиядә еш күзәтелә). Урланган мал үзләштерүдә гаепләп, акт төзелә. Эш судка барып җитә. Лалә Оралоглуны 10 айга ирегеннән мәхрүм итәләр. Өстәвенә, шактый күләмдә акча түләргә дә тиеш була. Үзенең алдан оештырылган капкынга эләгүен ул яхшы аңлый, ләкин хаксыз суд карарына каршы килә алмый…

Лалә Оралоглуның юклыгы театрны бик авыр хәлдә калдыра. Район һәм шәһәр җитәкчеләре белән күптәннән килешүләр төзелгән, спектакльләрдә Лалә ханым үзе дә уйнарга тиеш… Оралоглу төрмәдә дә тик утырмый – яңа пьесалар иҗат итә.

Күңелдә театрга булган мәхәббәтне ничекләр бастырасың?!

Озак та үтми, Лалә Оралоглу тагын бер гаделсезлек белән очраша. Аның труппасы уйный торган бер спектакльне, «порнографик чалымнар» бар дип, полиция туктата. Югыйсә шушы ук пьесаны Әнкара дәүләт консерватория студентлары да уйный, аларга беркем бәйләнми. Лалә Оралоглу мондый хаксызлык каршында баш иеп торырга җыенмый һәм… ачлык игълан итә. «Мин моны үземә карата гына түгел, барлык театр әһелләренә карата басым дип бәялим. Шуңа протест белдерәм. Төрек театрының гомере минем гомеремнән озын, ул – җан фида итәрлек кыйммәтле сәнгать», – ди. Матбугатта шау-шу куба. Тәнкыйтьчеләрнең күбесе Лалә ханымны яклый. Вакыйга дәүләт җитәкчелегенә дә барып ирешә. Төркия парламенты, Җөмһүрият сенаты тикшерү эше башлата. Нәтиҗәдә, «Лалә Оралоглуны аклау кануны» чыга. Документка Төркия премьер-министры Бүләнт Әҗәвит һәм мәдәният министры Танэр Кышлалы имза куя. Бу канун теге суд карарын, Лалә Оралоглуга тагылган барлык гаепләүләрне дә гамәлдән чыгара. Аның көрәшче рухын бүген дә, демократияне, сәнгатьне, кеше хокукларын яклауда үрнәк дип, ихтирам белән искә алалар.

Лалә Оралоглу – күпкырлы талант, ул үзенең сәләтен кинорежиссерлыкта, продюсерлыкта да сынап карый. Һәм зур уңышка ирешә! Сценарийлар авторы буларак та таныла. Пьесалар яза башлый. Чит телләрдәге пьесаларны төрекчәгә тәрҗемә итә. Утыздан артык пьесага музыканы да үзе иҗат итә. Сәнгатьнең бу тармагындагы хезмәтләре кинофестивальләрдә югары бәяләнә: аңа «Иң яхшы сценарий авторы», «Иң яхшы режиссер», «Иң яхшы хатын-кыз артист» дигән исемнәр бирелә. Милләттәшебез 1950–1970 елларда төрек театр һәм

кино сəнгатендə якты йолдыз булып балкый, дəрəҗəле исемнəр, мактаулы урыннар ала. 1952 елда – Төркиянең «Йылдыз» журналы, 1953, 1954, 1955 елларда – төрек фильмнары бəйгесе, 1969 елда төрек фильмы фестивале аны «Елның иң яхшы артисты», 1956, 1957 елларда чорның иң күп укылган «Миллият» газетасы – «Елның зур уңышларга ирешкəн артисты», 1959, 1960 елларда «Соңгы сəгатьтə» газетасы «Елның иң яхшы театр артисты» дип игълан итə. Лалə ханымга 44 яшь тулган көннəрдə Төркия хатын-кызлар җəмгыяте тарафыннан аңа «Елның иң талантлы сəнгать əһеле» исеме бирелə.

Лалə Оралоглу ул чорның иң атаклы «Илһан Фəйман» оркестры белəн бергə Шарль Азнавур, Мирей Матье, Эдит Пиаф репертуарындагы французча җырларны яңгырата, төрекчə җырлар да башкара – сəнгатьнең бу тармагында да ул тирəн эз калдыра.

Лалə ханымның тынгысыз күңеле гел эзлəнүдə, гел иҗатта була. Ул хəтта мюзикл иҗат итəргə алынудан да курыкмый. Сүзлəрен дə, музыкасын да үзе яза. Беркайчан шигырь язып карамаган кешенең алты көндə мюзикл язуын исəпкə алсак, аның ташып торган талантына сокланмый мөмкин түгел. Əлеге чор өчен ул уңышлы əсəр дип кабул ителə.

Үз башыннан үткəн бу хəлне сəнгать тамырына балта чабуга тиңли ул.

Төрки халыкларда «Җимешле агачка таш атучы күп була» дигəн əйтем бар. Бу җəһəттəн Лалə Оралоглуның да хезмəтлəрен, талантын танырга телəмəүчелəр, иҗатына түбəнсетеп карап, аны төпкə батырырга тырышучылар табылып кына тора. Мюзикл иҗат итеп, аны сəхнəлəштергəннəн соң: «Кем соң əле ул Оралоглу? Ул ничек музыка яза алсын?» – кебек тəнкыйди чыгышлар күбəеп китə. Ə бит Лалə Оралоглу консерваториядə ул чорның иң атаклы белгечлəрендə укый: сольфеджио дəресен Җəмал Рəшит Рəй һəм Рəшит Абеттəн ала, фортепиано серлəренə – Фəрди Стацер, вокал осталыгына Алис Розенталь өйрəтə. Моның өстенə җиде ел Истанбул мэриясе хорында профессиональ җырчы булып эшли. Лалə Оралоглуны театр режиссеры буларак та тəнкыйтьлилəр. Ул Жан-Поль Сартрның «Затворники Альтоны» əсəрен сəхнəлəштерер алдыннан, газеталар: «Сартр хакында берни белмəгəн килеш Оралоглу аның əсəренə ничек тотына ала икəн?» – дип язалар. Лалə Оралоглуны хур итəргə телəүчелəр, аның инглиз филологиясе факультетын тəмамлавын, өстəвенə, Шекспирның «Гамлет»ы белəн Сартрның «Затворники Альтоны» əсəрендəге Францның холыкларын чагыштырып, аларның рухи халəтлəрен ачу җəһəтеннəн диплом эше яклавын белмилəр шул… Лалə Оралоглу кебек ике югары уку йорты тəмамлаган, берничə тел белүче талант ияләре Төркиядə ул вакытта бармак белəн генə санарлык булган.

Лалə ханымның журналистлык хезмəте турында да искə алмый мөмкин түгел. Ул 1950 елда «Галатасарай» спорт клубының журналын чыгара, «Истанбул-Экспресс», «Яңа сабах», «Ахшам» кебек газеталарда хəбəрче булып эшли. Шул елларда чарланган калəме аны «Кызым» дигəн детектив-роман язарга этəрə. Əсəр «Хөррият» нəшриятында басыла.

2001 елда Төркия мəдəният министрлыгы Лалə ханымның 50 еллык иҗат кичəсен Истанбулның иң абруйлы мəдəният мəркəзендə зурлап оештырды.

Лалə Оралоглуны соңгы юлга озатканда табуты «Галатасарай» спорт клубының байрагы белəн төрелде. Төркиянең алдынгы газеталары һəм мəгълүмат агентлыклары аның үлемен «зур югалту» дип хəбəр иттелəр. Лалə Оралоглу төреклəрдəн тышкы кыяфəте белəн шактый аерылып торганга, бу авыр хəбəр «Сары гөлебез сулды» дигəн баш астында чыкты.

Шунысы игътибарга лаек: Лалə Оралоглуны бүген дə матбугатта гел искə алып торалар. Журналист, тəнкыйтьче Бүлəнт Һабораның мəкалəсендə мондый юллар бар: «Лалə Оралоглу белəн очрашуга барганда, үзем дə белмим, нигəдер, бераз шүрли торган идем. Кием-салымнан алып, сөйлəү манерама, хəтта җөмлə төзелешлəремə кадəр игътибар итəм. Аның янында хата ясамаска тырышам. Чынлыкта, бу – курку түгел, аңа карата аңлатып булмый торган хөрмəт иде. Аның белəн таныш булуым һəм аралашуым белəн горурланам». Төркиянең танылган киноактеры Җүнəйт Түрəл Лалə Оралоглуның вафаты уңаеннан: "Төркия чын «егетен» югалтты. Лалə – театр, мəдəният һəм замана көрəшчесе иде», – дип интервью бирде.

Аның турында язылган кайсы мəкалəгə тукталсаң да, авторларның Лалə Оралоглу иҗаты каршында баш июлəрен тоясың: барысы да аны Төркиянең беренче өч хатын-кыз кинорежиссеры арасына керүенə басым ясап, аеруча олылый.

Əнə шундый күпкырлы талант иясе булган ул. Без, татарлар, исəн вакытында үзе белəн танышып, ни аяныч, горурлана алмадык. Лалə ханым бер тапшыруда: «Онытыласым килми», – дигəн иде. Татар миллəте өчен, бəлки, зур-зур эшлəр башкара алмагандыр (ул яшəгəн чорның үзенчəлеклəрен, дəүлəт сəясəтен һич онытырга ярамый!). Əммə тамырларында аккан татар канына, əти-əнисе тарафыннан бирелгəн тəрбиягə хыянəт итмəгəн һəм форсат чыккан саен төреклəргə – хезмəттəшлəренə, студентларына Сөембикə һəм Казан ханлыгы тарихын сөйлəгəн. Менə шуның өчен генə булса да без аның исемен хəтерлəп торырга бурычлы.

Истанбул

БИОГРАФИК МƏГЪЛҮМАТ: Əминə Лалə Каран (Оралоглу) 1924 елның 28 сентябрендə Измир шəһəрендə туган. Бала вакытында əти-əнисе белəн Истанбулга күченə. Гомеренең 54 елы иҗатка багышлана. 2006 елның соңгы аенда «Җаннан да артык» фильмына тавыш яздырганда инсульт кичереп, хастаханəгə озатыла һəм 2007 елның 15 гыйнварында 82 яшендə бакыйлыкка күчə. Истанбулның Зинҗирликую зиратына җирлəнгəн.

БЕЗ ҮСКӘНДӘ ИРЛӘР – ИР, ХАТЫННАР ХАТЫН ИДЕ



Ркаил ЗӘЙДУЛЛА

Без үскәндә малайлар белән кызларга тәгаенләнгән эшләр нык аерыла иде. Кызлар өй эчендәге эшләр белән мәшгуль булса, малайлар, гадәттә, тышта – терлек карау, аларның астын арчу кебек эшләрдә. Көтүдән ач кайткан сыерларны җитәкләп үләнле җирләргә алып барганда да, ферма атларын сакларга куна-төнә йөргәндә дә арада кызлар булуын хәтерләмим. Утын кисү, яру шулай ук без – малайлар өстендә иде. Кызлар исә әниләргә булыша: кер юалар, идән ышкыйлар... Хәер, өй эчендә дә, ихатада да тавык чүпләп бетермәслек иде эш. Ул заманда, дип әйтүем...

Бу өлкәннәр арасында да шулай. Кемдер хатын-кыз эшенә килеп тыгыла икән, ул инде хатынша булып телгә керә. Ирләр эшеннән чирканмаучыны, әлбәттә, ирдәүкә дип атыйлар. Андыйлар да сирәк кенә очраштыргалый иде. Меңгә бер...

Авыл мин үскәндә кадими, ягъни шактый консерватив иде әле. Гасырлар дәвамында урнашкан яшәү рәвеше бер көйгә дәвам итә. Искә төшерсәң исең китәрлек: безнең авылга электр уты 1965 елда гына кергән. Мин әле куыклы лампаларны хәтерлим. Сигезле лампа дигәне бик якты яна, аны кунаклар килгәндә рәешкә генә кабызалар. Мунчада исә «пелт-пелт» дип аталган сукыр лампа. Чып-чынлап «мин чыра яктысында тудым!» дип әйтерлек. Менә шул яктыдан интернет заманына кадәр килеп җиттек. Кыска гына гомердә. Уйласаң, бик зур тетрәнүләр, планетар үзгәрешләр кичергән буын без. Шуңа күрә ул замандагы аршын белән бүгенге чынбарлыкка якынлашырлык та түгел. Тарихи күзлектән караганда, күз ачып йомганчы вакыт үткән, ә аерма күк белән җир арасы! Ләкин бит безнең күңел шунда, рәшәгә төренгән үсмер чакта; нинди генә яңа технологияләр тормышыбызга кермәсен, артта калган патриархаль тормыш һаман безнең итәгебездән тарта, авызыбызны ачсак бәрәңге күренә.

Без үскәндә ир-ат – ир-ат, хатын-кыз хатын-кыз иде. Һәрберсе үзенә тәгаенләнгән, үзе булдырган эшне башкарды. Ир-ат – төпкә җигелсә, хатын-кыз мичәүдә иде.

Билгеле, шәһәрне инде авыл белән чагыштырып булмый. Ул һәр заманда да «алга киткәнрәк» була. Хәер, «алга китүне» куштырнакка алмасаң да була. Мәдәни дигән сүз үзе үк мәдинә – гарәпчә «шәһәр» дигән сүз белән бер тамырдан, цивилизация дә (civilis) шәһәр белән бәйле. Ләкин алгарыш кешелекне төрле уңайлыклар белән тәэмин иткәндә еш кына халыкны кешелектән дә чыгарып ташлый. Шәһәрдә үзара мөнәсәбәтләр дә, вазгыять тә, максатлар да бүтәнчәрәк. Ертлачлык аеруча югары бәяләнә. Ялган, төрле бизәкле киемнәргә төренеп, еш кына хакыйкать ролен уйный, сәясәт дип атала.

Хатын-кызларның эмансипациясе дә шәһәрдә башланган. Аларны ир-ат белән тигезләргә авылда беркемнең дә башына килмәс иде. Татар авылында хатын-кыз беркайчан да изелгән җенес булмаган. Аның безнең җәмгыятьтәге мәртәбәле урыны борынгы төрки тарихлардан ук билгеле. Галимҗан Ибраһимовның «Татар хатыны ниләр күрми» әсәрен мисалга китерүчеләр татар хатынын кыерсытылган, кимсетелгән дип күрсәтеп ялгыша: Гөлбануны чынлыкта кем изә? Кайнанасы! Ә ул шул ук татар хатыны түгелмени?

Совет заманында хатын-кызны ир-ат белән чынлап та тиң иттеләр. Ул шпаллар да ташыды, окоплар да казыды, урман да кисте. Өстәвенә, «сез ирләр белән бер сафта!» дип шатланырга боердылар. Бу «тигезләүнең» авыр башы авыл хатын-кызы өстенә төште.

Шәһәрдәге улында кунак булып кайткач, әбием (мин аңа картәнәй дип дәшә идем) бик ярсынып, ризасызлык белән бабайга сөйләп торганын хәтерлим. «Беткән безнең малай, – диде ул, – мин килеп кергәндә идән ышкып ята иде! Килен җирбит икән, адәм тәганәсе, ыржыктай улымны идән чүпрәгенә әйләндергән!»

Миңа бу сүзләр нык тәэсир итте, әлегәчә идән чүпрәген кулга алганым юк, идән ышку турында сүз дә булырга мөмкин түгел!

Тик бит аның хәзер кирәге дә әллә ни юк – тузан суырткыч бар, кер юарга – машинасы... Бүген инде авылда да эшне монысы – ир-атныкы, бусы – хатын-кызныкы дип төгәл генә аерып булмый. Малай-шалайга берәр авыррак эш куш, шунда ук канатын җәеп анасы каршы киләчәк – җан пәрәсе биртеләчәк – җан пәрәсе биртелә күрмәсен!

Авылга кайтасың, анда урамнар Сәгыйть Рәми шигырендәгечә буш һәм тын. Балалар да аз, булганы да компьютерга капланып, телефонда бармак уйнатып утыра. Нинди эш?! Малайлар эше дә юк, кызлар эше дә.

Мондый шартларда җенесләрнең аерымлыгы да җуела бара. Ир-егетлек сыйфатлары юкка чыга. Европада әнә гейлар инде законлы «гаилә» кора. Моңа каршы төшүчеләрне фашистларга тиңлиләр. Ә без беләбез, Европадагы һәрнәрсә иртәме-соңмы Рәсәйгә күчә, чөнки урыс халкының элитасы гомер-гомергә көнбатышка карап сәҗдәгә киткән. Хәзер дә, мәктәпләрдә урыстан гайре халыкларның тел-әдәбиятларын, тарихын кысрыклап чыгарганда, Европа телләре мәҗбүри укытылачак, андагы халыкларның тарихы өйрәнеләчәк. Алар безгә үрнәк, өлге! Андагы яшәү нормалары бездә дә шулай итеп гадәтигә әйләнер. Минем фашист буласым килми, тик әйтми дә булмый – бу бит бетүгә юл!

Татарга хас яшәү рәвешен кире кайтарсак кына безнең ирләр – ир, хатын-кызлар хатын-кыз булып калачак. Аларның нәкъ татар тәрбиясе биреләчәк бала табуларына да шул чакта гына өмет бар. Ләкин моның өчен үз мәгарифебез, үз тәрбиябез гамәлдә булу кирәк. Юкса безне упкынга өстериләр.

КҮҢЕЛЕ АЧЫКНЫҢ – ЮЛЫ АЧЫК



МӘСКӘҮ ҮЗӘГЕНДӘ – МӨСЕЛМАННАР ӨЧЕН СПА-САЛОН! БАШКАЛАНЫҢ ИҢ ЯХШЫ БИШ САЛОННЫҢ БЕРСЕ! ҺӘМ УЛ АНЫҢ ХУҖАБИКӘСЕ!

Ике-өч ел элек кемдер аңа: «Ә бит бу юллар синең хакта, Юлия!» – дисә, ул, әлбәттә, ышанмас иде. Әкиятләргә ышаныр яшьтән күптән чыккан лабаса... Тормыш бу сабакны аңа әллә кайчан биргән инде: кызганыч, чынбарлык әкиятләрдән шактый ерак ул. Әйе, ерак...

«Алайса мин иртәгәдән эштән китәм...»

Кызның болай диюе берәүне дә гаҗәпләндерми. (Соңрак ишетә Юлия: аларның мондый «тәҗрибә»не инде беренче генә кабатлаулары булмый бу – ерактанрак берәр сәләтле кызны шулай чакырып китерәләр дә, ике-өч ай эшләткәч, бер тиен түләми чыгарып җибәрәләр.)

– Ә нигә иртәгәдән? Синең белән сөйләшергә аннары вакыт булмаячак безнең. Урынны бүген үк бушатырсың.

Кызның: «Мин әле кая барырга икәнен белмим», – дигәне дә туктатмый аларны. «Ярый, син алайса тиз генә хәл ит, бераз көтәбез», – диләр. «Мин, чынлап та, кая барырга белмим! Кунарга урыным юк!» – дип әйтергә горурлыгы комачаулый. Кичке сәгать дүрттә була бу сөйләшү.

Төнгә каршы шулай урамда кала ул. Метрога дип, 50 сум акча бирәләр бирүен...

Юлия Абитова (Хәсәнова) – Пермь краеның Барда районы Барда авылы кызы. Мәктәпне тәмамлагач, Пермь дәүләт сәнгать һәм мәдәният институтында укый. Белгечлеге буенча – режиссер. Кечкенәдән биергә-җырларга яраткан, халык алдында чыгыш ясаудан тәм тапкан кыз киләчәген бары тик сәхнә белән бәйле итеп кенә күрә. (Әмма бизнес белән беренче тапкыр Пермьдә укыганда ук шөгыльләнә ул. Дус кызы белән туй агентлыгы ачалар. Монысы аңа ачы тәҗрибә өчен кирәк була: үз эшләрен башлау өчен уртакка алган кредитларын Юлия өстенә калдырып, ул «дус кыз» юкка чыга. Бурычны бөтен гаилә белән түләп бетерәләр. «Минем өчен бүген йөз илле мең сум акча, бәлки, ул кадәр күп тә булып тоелмас иде. Ә ул чакта... Әйтерсең, миллионнар тиеш идем», – ди Юлия.) Тик диплом алгач, Бардага кире әйләнеп кайтырга туры килә аңа. Гомер буе төзүче булып эшләгән этисенә кинәт инсульт була – урын өстендә кала. Гаиләдә утырып киңәшләшәләр дә, этиләрен карашырга өйгә ике кызның кечесе – Юлия кайтырга тиеш, дигән карарга киләләр. («Ике кыз» дигән сүзне мин әйтәм, Юлия үзләрен өч туган дип саный. Ятим балалар интернатында төнге шәфкать туташы булып эшләүче әнисе, Юлиягә 10 яшь булганда, өйләренә бер кызны кунакка алып кайтып йөри башлый. Олеся, Юлия һәм Ләйсән бергә мунча керәләр, бергә пилмән бөгәләр... Ләйсәнгә инде 16 яшь була – аны кызлыкка алырга шактый соң. Ул Хәсәновларга болай гына килеп йөри: төрмәдә туган һәм беркайчан әни җылысы, өй җылысы күрмәгән кыз аларда якын кешеләрен таба. Юлиянең әнисе аңа укырга керергә дә, фатир алырга да булыша. Хәтта фатирына ремонт ясарга да! Шуңа да Юлиянең аны үзенең икенче апасы дип санавы гаҗәп түгел.)

Район җирендә сайланып тора алмыйсың – Юлия администрациягә эшкә урнаша. Әтиләренә алган дарулар бик кыйммәт – гел акча җитмичә тилмерәләр. Ял көннәрендә тагын бер эш тәкъдим иткәч, уйлап та тормыйча ризалаша Юлия. (Кайчандыр аның төнге клубта арт-директор булып эшләвен белүчеләр бүген аптырыйлар. Хиҗаб кигән, яулык бәйләгән Юлияме?! Булмас, диләр. «Теләгәнгә түгел, кирәк булганга эшләдем бит», – ди ул.)

«Долгопрудный шәһәре татар милли үзәгенә оештыру эшләре буенча белгеч» кирәк дигән игъланны күреп, ул аларга үзенең резюмесын җибәрә. Ике көннән инде Мәскәү яныннан: «Стажировкага килегез», – дип шалтыраталар. Әнисе белән утырып киңәшләшәләр дә тәвәккәллиләр: барып эшләп карарга кирәк. Әнисе этиләрен тәрбияләр, ә Юлия аларга акча җибәреп торыр.

Музей йортында торырга тиеш булып чыга ул. Өч кушетканы кушып, ятарга урын ясыйлар, матрас бирәләр. Баштанаяк эшкә чума Юлия: музейда экскурсияләр алып бара, үзәкнең чараларын оештыра, кирәк икән, җырлый, бии... Тик: «Без бит сиңа торырга урын бирәбез», – дигән сылтау белән, аңа берәү дә хезмәт хакы түләргә ашыкмый. Ике ай ярым түзә. Ә аннан урамда кала...

– Кире Бардага кайта алмый идем... Бөтен авыл белән озатып калдылар, акча эшләргә киттем бит. Мытищида бер танышым бар иде, шуларга шалтыраттым – мине ул кичне алар сыендырды. Икенче көнне берьюлы өч эшкә урнаштым. 2014 елның октябре иде бу. Әмма тиздән кризис башланды да, мин аларның берсендә дә акча эшли алмадым. Кулым белгән бер эш калды – массаж ясау...

«Массаж ясыйм» дигән белдерүне, кайда мөмкин, шунда урнаштыра Юлия: социаль челтәрләрдә, бушлай игълан бастыручы газеталарда, кулдан язып – подъездларда... «Һәр чакырган кешенең өенә барып массаж ясау, әлбәттә, куркыныч. Кемгә туры килмәссең? Әмма башка юлым юк иде», – ди Юлия. Алар нәселендә бөтен хатын-кызның да кулы җиңел: әбисе кан агызу, сөлек салу белән шөгыльләнгән, хәзер бу эшне әнисе дәвам итә. Юлия дә мәктәптә укыган чакта ук дус кызларының колакларын үзе тишкән. Курсларга йөреп, массаж ясау серләренә төшенгән. «Массаж ясарга алыну өчен, кешенең физиологиясен яхшы белергә кирәк, аннан кулың тоярга, сизәргә тиеш. Ә калганы тәҗрибә аша килә, уку гына әле берни дә бирми», – дип саный.

Пермьнән бер дус кызы эшкә дип килә дә, алар Мәскәүгә күченәләр – икәү бергә фатирга түләргә дә җиңелрәк бит. Эшләр аз гына җайлаша төшә. Шушы ыгы-зыгы арасында Юлиянең тормышында шактый зур бер вакыйга була: ул яулык бәйли башлый.

Тормыштан зарланмыйм, зарланучыларны да яратмыйм.

– Үзем эшләп киткән Долгопрудный татар милли үзәгенең юбилее иде. Мине дә чакырдылар. «Акча әлегә түли алмыйбыз, бәлки, соңрак җай чыгар», – дип калганнар иде бит – хезмәт хакымны бирәләрдер инде дип уйладым. Өмет гел бар бит... Бәйрәмгә барыр алдыннан, чәчемне юдым, әмма киптерергә өлгермәдем – феным ватылды. Башыма палантин урадым да, чыгып киттем. Янымда башкасы булмагач, бердәнбер озын күлмәгемне кидем. Очраклы бер туры килү идеме – ул көнне минем тирә-юнемдә нидер үзгәрде: кая гына керсәм дә, егетләр миңа ишек ачып тордылар, урын бирделәр... Кайчаннан бирле елмайганым юк иде – кәефем күтәрелде. Ничә айга беренче тапкыр! Долгопрудныйга барып җиткәч, мин, әлбәттә, башымнан палантинны салдым. «Нәрсә, Юлия, этиеңнәргә булыша аласыңмы инде хәзер?» – дип сорап, элеккеге җитәкчеләрем җиргә бик тиз төшерде. Юкка өметләнеп килгәнмен – үзләрен бурычлы дип санамыйлар да. Күңелсез уйлар белән кире юлга кузгалдым... Берничә станция баргач, чәчләрем-



АВЫР ХӘЛДӘ КАЛГАННАРГА ЮЛИЯДӘН БЕР КИҢӘШ
– Иң элек, күзеңне йомып, барысын да Аллаһка тапшыру кирәк. Сынаулар юкка бирелми: Аллаһы Тәгалә безне туры юлга кертәсе килгәндә генә җибәрә аларны. Ул үзенә мөрәҗәгать итүләрен, искә алуларын, аңардан сорауларын тели... Диндәге кешегә сынауларны кичү җиңелрәк: син аның Аллаһтан икәнен аңлыйсың, сабырлык белән кичерсәң, бүләкләячәген дә беләсең. Раббыбыз кушмаса, яфрак та селкенми. Ул кушса, бер мизгел эчендә барысы да үзгәрергә мөмкин. Минем мисал – шуңа ачык дәлил.

не җыйдым да, башыма палантинны яңадан бәйләп куйдым. Һәм... башка салмадым. Яулык бәйләрмен, дигән хыялым бар иде анысы, әмма кияүгә чыккач кына ябынырмын дип уйлый идем. Ә ул минә ничек көтмәгәндә килеп чыкты...

Беркайчан: «Мин моны беркайчан эшләмәм», – димә. Намазга басармын, гардеробым тулысынча үзгәрер дип мин дә уйламадым.

«Массаж ясыйм» дигән игъланнарны инде күбрәк мөселман төркемнәренә урнаштыра башлый Юлия. Клиентларының берсе чечен хатыны булып чыга. Танышуга, шактый сәер үтенечен җиткезә ул: «Прокатка күлмәк алып торырга җыенам. Әмма сайлаган күлмәгемнең миңа яраклы үлчәме юк. Аңа сыю өчен тиз арада ябыгырга тиешмен. Ике көнлек прокат өчен 700 мең түләп куйдым инде. Акчамны суга сала алмыйм. Сез миңа ябыгырга булышыгыз!» Күлмәкнең рәсемен дә күрсәтә – аны киеп каядыр бара алу өчен бил тирәләре, ким дигәндә, хәзергедән 15 сантиметрга зифарак булырга тиеш. Юлия тәвәккәлли. Әмма клиентка ашыгыч рәвештә Грозныйга кайтырга кирәк булып чыга, һәм ул үзе белән аны да алып китә.

Чакырылган тантанага гарәп кутюрьесының Махачкаладагы бөтен Төньяк Кавказга билгеле Гранд Плаза сәүдә үзәгеннән алган күлмәкне киеп китә клиенты. Ә ул арада... Юлиягә ул ханымның дуслары, туганнарыннан чират тезелә. Барысы да: «Без дә шулай ябыгырга телибез!» – диләр. Грозныйга күп булса ике-өч атнага дип килгән кыз, хушлашыр өчен әтисе янына гына кайтып килә дә, ярты елга биредә кала.

– Ул ханымнарның берсе дә мохтаҗлардан түгел. Андыйлар янына, гадәттә, мөмкинлек чыкканда акча савып калырга теләүчеләр җыела. Ә мин беренче урынга кешелеклелек мөнәсәбәтләрен куям. Эшемнән канәгать калган клиент минем өчен күпкә мөһимрәк. Нәтиҗә әйбәт булса, ул бу хакта башкаларга сөйли – алар сиңа килә. Алары тагын кем беләндер уртаклаша... Үземә массажга йөргән чечен хатын-кызларының һәммәсе белән дә араларыбыз җылы булып калды, соңыннан да алар мине кабат-кабат Грозныйга чакырдылар.

Чечнядан Юлия үзгәреп, инде үз көченә, булдыра алачагына ышанып кайта. Иң беренче эш итеп – клиентлар кабул итү өчен кабинет таба. (Фатирдан фатирга йөреп массаж ясауларга нокта куярга вакыт!) Көненә тугызар кеше кабул итә. Янәшәдә урнашкан затлы салонга да аның кадәр йөрмиләр!

Пермьнән массажга бергә укыган дус кызы Лилия килгәч, өч бүлмәле фатирны арендага ала – мини-салон ача. Эшкә косметолог, маникюр ясаучы останы чакыра. (Бүген кул астында эшләүчеләр арасында якташлары байтак аның. Күбесе аның белән аралаша, эшли башлагач дингә килгән, яулык ябынган.)

Дөнья бер урында тормый: аннары инде СПА-салон ачар көн җитә. Ремонтны алар үзләре ясап кергән: клиентлары арасындагы бер дизайнер буш стеналарны керсәң чыгасы килмәслек салонга әйләндергән. Биредә һәркем үзен иң кадерле кунак итеп тоя: аның алдына шунда ук бал белән чәй, төрле тәм-томнар китерәләр. Тәнең дә, җаның да ял итә.

Юлия ачкан салон башкалардан күпкә аерыла: монда хезмәткәрләр дә, клиентлар да – барысы да мөселманнар.

– Минем өчен процедураларның «бисмилла» белән башлануы бик мөһим, – ди ул. – Нинди генә яхшы белгеч булса да, ул яңа гына тәмәке тартып кереп, әйтик, чәч кисә башласа, хәрам эштән соң аның мөселман кешесенә кагылуы дөрес булмас иде. Ә массаж, гомумән, энергия алышу бит. Аны кичтән аракы эчкән кеше ясаса, ничек сиңа рәхәт була алсын?!

Массажның барлык төрләре, спа-процедуралар, эстетик косметология, аппарат белән ясый торган процедуралар, организмнан сыеклыкны чыгару, маникюр, педикюр, стоун-терапия, ЭЛОС-эпиляция, хамам, ванналар (ылыслы, сөтле, хөрмәле), йога һәм хореография курслары... Салонда күрсәтелгән хезмәтләрнең барысын санап чыгу мөмкин түгел! Инде икенче салоннары да ишегән ачкан.

– Хатын-кызлар хәзер үз-үзләрен бик карый. Һәм бу бик дөрес тә. Аллаһы Тәгалә безгә тәнебезне әманәт итеп биргән – аны сакларга бурычлыбыз. Гәүдәңдә, тәнеңдә ниндидер проблемалар булмаса, ирең алдында да үзеңне иркен тотасың, ул да синнән канәгать. Күпләр, әлбәттә, ябыгырга дип килә. Камералар урнаштырылмаган, тренерлар бары тик хатын-кызлар гына булган бердәнбер салон без Мәскәүдә. Күпләр шуның өчен дә безне сайлый...

Ә, минемчә, Юлиянең салонын аның өчен генә сайламый башкала ханымнары!

Гөлнур САФИУЛЛИНА

АДӘМНЕҢ ҖИМЕШЕ — БАЛА



Илнар хәзрәт ЗИННӘТУЛЛИН, «Туган авылым» мәчете имам-хатыйбы

Күп вакыт хатын-кызлар баланы ире табарга рөхсәт итмәгәнгә төшерә. Бу очракта гөнаһысы хатын-кызга гына буламы, әллә ир-атка дамы?

– Ислам дине буенча, хатын-кыз һәрвакыт иренең сүзен тыңларга, ягъни аңа буйсынырга тиеш. Әмма иренең әйткән сүзе шәригатьтән читкә чыгып китмәгән очракта гына. Шәригать кануннарына каршы килә торган берәр сүз әйтсә, нидер таләп итсә, хатын-кызның аны тыңламаска да хакы бар. Әйтик, бу сорауда яңгыраган: «Балаңны төшерт, тапма, ул миңа кирәкми», – дигән сүз шәригатькә каршы килә. Хатын-кыз иренең бу сүзенә колак салып, туачак баласының гомерен өзсә, моның гөнаһысы аның үзенә генә була. Чөнки карарны хатын-кыз үзе кабул итә. Ә ир кеше аңа бу сүзне әйтүче, тәкъдим итүче генә. Сүз генә бит ул! Урамда әнә сиңа нинди генә сүз әйтмәскә мөмкиннәр?! «Асылын», диюче булса, кайтасың да кулыңа бау аласыңмыни? Һәр әйткән сүзне башта анализларга, аннары гына карар кабул итәргә тиешсең. Ирнең бер кыек сүзенә карап, тизрәк табибка йөгерергә, балаңны төшертергә нигә ашыгырга?! Ир: «Югыйсә аерылышабыз», «Балаңны төшертмәсәң, үзеңне ташлыйм», – дисә дә, хатын-кыз бу адымга барырга тиеш түгел. Әлбәттә, бу эшне хатыныннан таләп иткән өчен гөнаһысы ир кешегә дә була аның. Әмма барыбер хатынына караганда, анықы азрак була.

Ә менә ул хатынын мәҗбүр итә икән – бу инде бөтенләй икенче мәсьәлә. Аңа кул күтәреп, кыйнап, эченә тибеп яки башка төрле ысуллар белән баланы төшертә икән, моның гөнаһысы инде иргә була. Бу очракта хатын-кыз гөнаһлы саналмый.

Бу гөнаһысын хатын-кыз ничек юа ала?

– Бу гөнаһны бары тик тәүбә итеп кенә юып була: Аллаһы Тәгаләдән әлеге адымың өчен гафу сорыйсың һәм яңадан бу эшне кабатламыйсың. Дөрес, үзенә нинди дә булса шәхси җаваплылык алучылар да бар. Әйтик, кемдер ятим бала алып үстерергә карар кыла, бу ниятен: «Төшергән балам өчен», – дип аңлата. Ятимнәр йортына даими рәвештә азык-төлек яки акча илтеп торучылар да бар. Әмма болар, әйткәнемчә, барысы да хатын-кыз үз теләге белән эшләгән нәрсәләр – аларда бернинди катгыйлык юк. Теләгеңдә булса, шундый өстәмә игелекләр кылу вазыйфасын үз өстеңә ала аласың. Бу – синең шәхси эшең. Аңлагансыздыр, әлеге гөнаһтан арынуның төгәл ысулы юк: тәүбә итәсең һәм шул тәүбә белән Аллаһы Тәгаләнең сине кичерүенә генә өметләнә аласың.


Кызганыч, бала төшертүнең нинди зур гөнаһ икәнен күп хатын-кызлар олыгайгач кына аңлый, чөнки яшьрәк чакта аларга моны аңлатып бирүче юк. Икенче яктан караганда, кеше тормышының кадере дә бетте хәзер. Җан иясе, тереклек дигән төшенчә, аның изгелеге, кагылгысызлыгы бүгенге җәмгыятьтә мәгънәсен югалтты. Ә ана карынындагы бала, гомумән, җан иясе дип кабул ителми. Биологиядән без аны «эмбрион» дип өйрәнәбез, аңа кан кисәге, ит кисәге дип кенә карыйбыз. Менә ни өчен мөнәсәбәт тә шундый аңа. Инде моның нәтиҗәләрен дә күрәбез хәзер. Кайбер хатын-кызлар абортка баруны – бала төшертүне бернигә санамый, аның хәтта исәбен дә белми. Барып кайта да, икенче көнне инде эшкә чыга... Җәмгыять өчен моны нормаль күренеш дип булмый. Статистика мәгълүматлары буенча, Россиядә һәр өченче хатын-кызның бала төшерткәне бар икән.

Тумый калган бу балалар хатын-кыздан – әниләреннән дога көтәме?

– Юк, көтми. Дөресрәге, җан кермәгән булса – ә ул дүрт айлык чакта гына иңә – көтми. Бу нарасыйлар теге дөньяда – кыямәт көне җиткәч терелмәячәкләр дә. Әлеге сабыйларга гына түгел, хәтта җан кергәч төшкән яки туугa үлгән балаларга да дога кирәкми. Алар инде болай да җәннәттә – шуңа күрә берәүдән дә өстәмә дога көтмиләр. Ашларын – өчесен, җидесен, кырыгын да үткәрергә кирәкми аларның. Киресенчә, бу балалар ананың үзенә ярдәм итәләр, ул – аларга түгел, ә алар аңа күбрәк файда китерәләр. Теге дөньяда алар әниләренә шәфәгатьче булалар, ягъни Аллаһы Тәгаләгә каршында аны яклап чыгалар. Ләкин монда сүз, әлбәттә, үтерелгән, ягъни төшерткән бала турында бармый, ә үзе төшкән яки туганнан соң, сабый чагында ук үлгән нарасыйлар хакында сөйләнә.

Тарихтан, дин китапларыннан укып беләбез, гарәпләрдә кыз балаларны тугач та үтерү гадәте булган. Бу хакта Аллаһы Тәгалә Коръәни-Кәримдә болай ди: «Кыямәт көнендә җир астына тере килеш күмелгән ул кыз балалардан: «Нинди гөнаһларыгыз өчен сезне үтерделәр?» – дип сорарлар ди. Бу, әлбәттә, риторик сорау. Психологик яктан моңа җавап юк. Аборт ясатучылардан да сораячаклар: «Нинди гөнаһлары өчен үтердегез бу баланы, ул нарасый сезгә нәрсә эшләде, аның сезгә нинди зыяны тиде?» – дип.

Аллаһы Тәгалә Коръәни-Кәримдә әйтә: «Хәерчелектән, фәкыйрьлектән куркып балаларыгызны үтермәгез. Без аларны ашатабыз. Һәм сезне дә ашатабыз», ди. Ягъни, сезнең дә, аларның да ризыклары – бездән, ди. Хәерче булырга язган икән, ул бала туса да, тумаса да, юклыктан, мескенлектән башыгыз чыкмаячак. Әгәр байыйсы булсагыз, ул бала туса-тумаса да, муллыкта яшәячәксез. Тагын бер бала дөньяга килгәнгә карап, бер генә әтиәнинең дә ризыгы кимеми. Киресенчә, бала тугач, ул арта гына. Кайвакыт бала үзе белән үзеннән дә артыграк ризык алып килергә дә мөмкин.


Роберт МИҢНУЛЛИН

Роберт Миңнуллин... Тукай премиясе лауреаты. Халыкара Андерсен бүләге иясе. Алиш премиясе лауреаты. Татарстанның халык шагыйре. Депутат, күренекле җәмәгать эшлеклесе. Әллә нинди зур исемнәргә, дан-дәрәҗәләргә ия булса да, ул укучылары өчен бик якын, үз кеше булып кала белә: алар белән аларча сөйләшә, һаман гади һәм ачык, ихлас һәм җайлы, тапкыр һәм шаян. Матур лирик шигырьләрен һәрчак эзләп укыйлар. Җырларын яраталар. Ул – балалар шагыйре дә, ул – мәхәббәт шагыйре дә. Әниләргә багышланган шигырьләре, җырлары исә иҗатының тәхете сыман...
Тиздән – 1 августта Роберт Миңнуллинның зур юбилее. Яраткан шагыйребезне гомер бәйрәме белән котлыйбыз. Яңа шигырьләре туып торсын. Көн саен инстаграммда аның «Хәерле көн, замандашларым, инстадашларым!» дигән сәламләвен күреп сөеник. Иҗат бәхете телик. Ә бүген өр-яңа шигырьләрен укып куаныйк.

МӘХӘББӘТЛЕ КӨЗЛӘРЕМ

Син тагын китәсең инде...

Син тагын китәсең инде...
Инде ничәнче кабат.
Тагын ялгыз калам инде
Син киткән якка карап.

Сер бирмәгән булам инде,
Берни булмаган кебек:
Йөрәгем янмаган кебек,
Күңел тулмаган кебек...

Ярар, тормыйбыз елашып,
Тормыйбыз үбешеп тә...
Безнең яшьтә төчеләнү
Бетмидер килешеп тә.

Әгәр калсам моңсуланып,
Әгәр калсам боегып,
Моңсу йөзем калыр иде
Күңелеңдә уелып...

Ах, бу китүләр, көтүләр,
Күңелне кузгатулар!
Китүләргә караганда
Авыррак озатулар...

Вокзалга гына булса да
Озата барам инде...
Син тагын китәсең инде,
Мин тагын калам инде...

17.12.17

Бүгенге төн...

Сүрән генә, сүлпән генә
Ай нурына күмелде төн...
Өтеп ала күңелне төн...
Бигрәк суык бүгенге төн...

Ай моңаймый, ай пошынмый...
Бүген кышкы ай шушындый...
«Тыныч йокы!» – диеп минем
Колагыма ул пышылдый.

Нинди гүзәл төн буласы!..
Юк янымда ярым гына.
Юк, мин генә түгел икән...
Ай да бүген ярым гына.

19.01.18

Сине сагынганда...

Киткән идең әле кичә генә,
Киткәнеңә сәгать ничә генә?!.

Чәчләреңне рәтләп алуларың,
Мөлдерәпләр карап алуларың

Әле һаман да күз алларымда.
Суынмаган әле җаннарымда

Карашыңның рәхәт сирпелүе,
Йөрәгемнең моңсу җилпенүе...

Миңа да бик кыен... Түздем инде...
Сизми каламмы соң? Сиздем инде

Еларга дип тулышканыңны да,
Елмаерга тырышканыңны да...

Кочагыма елышканыңны да,
Еш-еш алган сулышларыңны да...

Аптырыймын вакыт үткәненә,
Кайчан гына әле киткәнеңә...

Тик син генә минем башларымда...
Бөтен эшләремне ташладым да,

Сине сагынып һәм сине уйлап,
Утырамын айфон белән уйнап...

18.12.17

Бик сагынам...

Йә Хода, мин бит әле дә
Сагына беләм икән.
Сагынам, тик сагынулар
Бәгырьне телә икән...

Минем ничек сагынганны,
Ах, җаным, белсәң иде...
Минем сагышлы йөземне,
Ах, җаным, күрсәң иде...

Булмаса да канатларың,
Син кайтыр идең очып!
Кайтыр идең дә син очып,
Кочаклар идең кысып...

Кайнар кочагыма кереп,
Син китәр идең эреп,

Минем яратканны белеп...
Нәкъ яшь чактагы кебек...

Көтү авыр...
Кавышкачтын,
Әй рәхәттер инде ул...
Бик сагынам...
Сагыну шул
Мәхәббәттер инде ул...

22.12.17

Кайт инде...

Соңгы вакытта эшләрем
Бер дә пешмәгән иде.
Каләмемнән юньле шигырь
Бер дә төшмәгән иде...

Син киткәчтен рәхәтләнеп
Эшләрмен дигән идем.
Эшләрмен дип, өстәлемә
Кәгазьләр өйгән идем.

Өйдә тыныч, яз, рәхим ит!
Өйдә беркем шауламый,
Беркем эш кушмый, борчымый,
Беркем комачауламый.

Бөтен шартлар тудырылган,
Тик нигәдер эшләнми.
Күңел никтер илһамланмый,
Күңел никтер хисләнми...

Юк икән шул, минем күңел
Мондыйга өйрәнмәгән.
Минем шигъри халәтем дә
Тынычка көйләнмәгән...

Кулга каләм тоткан килеш
Утырам менә изрәп.
Юк, язылмый, язып булмый...
Кайт инде син, кайт тизрәк!

19.12.17

Ярый әле кайттың...

Болай көткәнем юк иде
Сине тилмереп.
Елардай булдым син юкта
Үксеп, илереп...

Мин мең тапкыр дөрләп яндым,
Мең тапкыр туңдым;
Мин мең тапкыр дуладым да
Мең тапкыр тындым...

Әллә нәрсә булды әле,
Никтер үзгәрдем.
Бик нечкәрде күңелләрем,
Моңсу – күзләрем...

Әйе шул, бик нык үзгәрдем...
Ул каян икән?
Әллә инде мин чыннан да
Картаям микән?..

Тәрәзәдән һәм ишектән
Күз дә алмадым...
Сине яратуымны мин
Ныграк аңладым...

Синең өчен бик борчылдым.
Тышта бит буран...
Ярый әле кайттың, җаным...
Үләм дип торам.

24.12.17

Син кайткач...

Син кайтып кергәчтен, өйгә
Ямь кереп китте!
Син кайтып көлгәчтен, миңа
Җан кереп китте.

Күзләрем дә сөенечтән
Яшьләнеп китте,
Күңелләр дә кинәт кенә
Яшәреп китте.

Син кайтып кергәчтен, өйгә
Якты нур тулды.
Сагышлы, моңлы җаныма
Татлы җыр тулды...

Син янымнан берчакта да
Китмәгән кебек...
Мин үзем дә сине бер дә
Көтмәгән кебек...

Гомерләр дә һич кенә дә
Узмаган кебек...
Тик барыбер җанда нидер
Сызлаган кебек.

Нидер сулкылдаган кебек,
Авырткан кебек...
Шактый яшәлгән бит инде...
Арыткан кебек...

Нишлисең, йөзеп булмый ул
Майда, балда гел...
Син кайткач, миңа шул җиткән.
Дөньям – ал да гөл!

27.12.17

Мәхәббәтле көзләрем...

Син миңа бик кирәк, җаным,
Су кебек, һава кебек!
Янымда синең булуың
Миңа бер дәва кебек!

Син миңа гел кирәк, җаным,
Көн саен, сәгать саен!

Син һәрчак кирәк буласың
Юк кына сәбәп саен...

Янымда гына басып тор!
Кирәкми бер сәбәп тә...
Янымда син булсаң гына
Мин бөек бер халәттә!..

Җитә миңа бер сулышың,
Җитә күз карашың да...
Мин үземне күрәм, җаным,
Синең күз карасында...

Син – минем кыюсызлыгым,
Син – минем кырыслыгым.
Син – минем шаулы яшьлегем,
Бүгенге тынычлыгым!

Син – минем елмаюларым,
Шатлыклы күз яшьләрем.
Яратуымны аңлата
Кайчакта сүз дәшмәвем...

Ярый әле син янымда,
Син – минем сабырлыгым.
Синең өчен генә язам,
Син – минем шагыйрьлегем.

Син бит минем гомеремнең
Мәгънәсе һәм асылы...
Килә генә әле безгә
Чын мәхәббәт фасылы.

Син – минем җырлы, сагышлы,
Мәхәббәтле көзләрем...
Күңелемдә йөргәннәрне
Яздым инде, түзмәдем.

27.09.17.



Асия
ЮНЫСОВА

ЯРКАНАТ

(Хикәя)

Кикри-к-ү-к!

Уятты, каһәр. Туйганчы йокларга иде бит исәбе Морадыймның. Кайтып ятканына өч сәгать кенә ләбаса. Морадыйм икенче ягына әйләнеп ятты. Юрганы белән башыннан ук томаланды. Яктыра башлаган иде инде. Әнисе исән булса, сыртыңа кояш төшкәнче ятмакчы буласыңмы әллә, дип оялта башлар иде дә. Күптән гүр иясе шул инде ул.

Сукранырга хатыны да юк. Хәзер юк. Юк икән – юк! Шулай булгач, оялтучы, сукранучы булмагач, төнге сменада эшләп кайтып яткан Морадыймның туйганчы йокларга хакы бармы – бар!

Ике тәүлек эшли, ике тәүлек ял итә торган аның эше. Ике тәүлек нефтьчеләр белән йөри дә ике тәүлек бакчасында казына, йә мунчасында матавыклана. Төзеп бетерәсе иде бит инде шуны. Үз мунчасын эшләтеп җибәргәч, ике тәүлек руль тотып, тәгәрмәчләр өстендә ватылган тәнен кабат язу җиңелрәк булыр кебек тоела иде аңа.

Кик-ри-к-үк!

Морадыйм «кикрикүк»ләрне санап ята башлады. 38 тапкыр кычкыргач кына дәрте басылды Кызыл Кәпәчнең. Тагын кычкыра күрмәсен дип, торып чыгарга, бер коштабак кибәкле бөртекне ялгашка сибәргә туры килде. Шуннан соң гына Морадыйм керфек очларында чак-чак кына эләгеп калган йокысын чайпалдырмаска, өркетмәскә тырышып, кабат урынына кереп ятты.

Таң йокысын тәмләп йоклап алгач, кәефе яхшырган иде. Болдыр баскычына басып бер киерелде дә, иркен итеп иртәнге саф һаваны сулый-сулый, бер чеметем арада күргән төшен уйлый башлады. Менә шул төшендә булырга тиеш хикмәт! Төштә күргән кызыл күлмәкле хатында. Кем булыр ул? Нигә кергән аның төшенә? Өнендә Морадыйм тирәсендә мондый хатыннар йөргәне күренми. Эзләгәне дә юк. Тегесе белән араны өзгәненә дә сөенеп бетә алмыйча йөргән чагы әле. Хатын кирәк булсамы? Таба ул аны. Берне түгел, бишне! Беркем алдында да, берни өчен дә хисап тотмыйча яшисе киләдер аның, бәлки...

Кичтән калган ашын җылытып ашаганда да, сөтләп чәй эчкәндә дә төшенә кергән кызыл күлмәкле хатын аны гел күзәтеп торадыр шикелле тоелды. Кем булыр ул?

Бераздан күңелгә шатлык хисе салып уяткан төш онытылды. Ниятләп куйган эшләрен тәртибе белән башкарырга тотынды Морадыйм. Кала җирендә яшәгән җиреннән кубарылып, туган нигезен тергезеп яшәп китеп маташкан чагы аның. Хатын кәмәше шәһәр фатирында калды. Җиткән кызлары Питерга ук укырга китеп барды. Кайчандыр тату гына кебек тоелган өч кешелек гаиләнең хәзер өчесе өч җирдә мөстәкыйль тормыш корып җибәрде. Хатыны Зөлфәнең авылга кайтмаячагы көн кебек ачык. Шәһәр кызы ул. Гомер буе яраган шофер ире-

нең эшен дә соңгы вакытта яратмый башлады. «Эшең эш түгел: йә син вахтада, йә син әвен базында», – дип сукранды. Дөресе дә шулай. Йокламаганда Морадыйм авылга, шушы туган нигезенә кайтып, җирдә тырмаша. Бәрәңге утырту, аны тәрбияләп үстерү изге бер ритуал кебек аңа. Югыйсә Зөлфә, аның шушы хирыслыгына үч итеп, бәрәңге дә ашамый башлаган иде инде.

Ярар, бәрәңге дә үстермәсеннәр, ди. Беләгендә егәр тойган ир-егеткә шәһәрдә ни шөгыль, ни кызык бар соң? Спорт, кино, театрмы? Тагын ни? Гел ял да ял була алмый бит инде. Адәм баласы гел хезмәттә булырга тиеш. Руль тотып арыганнан соң, кулына көрәк-балта тоту ошый Морадыймга.

Менә мунча җиткерә. Аннары өйне яңабаштан төзеп чыгу ягын чамалар. Күршеләр белән ике арада алмагачлар үсәр. Беренче утырткан алмагачлары ни сәбәпледер бик тиз корыды. Барысы да. Аннан тагын утыртты. Болары да тернәкләнә алмый торалар әле. Күршеләрнең этлегеннән шикләнә Морадыйм. Аларга бу ихатаның буш торуы кирәк иде. Үлән баскан ихата мал йөртергә бик кулай булган икән. Морадыйм кайтып яши башлагач, бу хөррият бетеп китте. Шикләнүнең нигезе дә бар. Ике тәүлек вахтадан әйләнеп кайтканда алмагачларга су сибелгәнен күреп гаҗәпләнде ул. Су сибәсе юк иде. Бу хәл берничә тапкыр кабатланды. Шуннан соң матур гына үсеп китәргә азапланган әнисләрнең төсе китте. Алай да Морадыйм күршеләре белән тәмсезләнергә ашыкмый әле.

Хыялда – туган нигезне гөл итү. Менә шул чагында аңа акыллы, аны аңлый белә торган эшчән хатын кирәк булачак. Бүген үк кирәк тә бит ул. Әнә кыярлар өлгерде. Кышка банкаларга ябып, базга төшереп куясы иде бит инде. Банкаларга кич тотыныр. Әле мунча сайгакларын иплисе булыр.

Ул көн буе мунча белән өй арасында йөрде. Ниләр эшләгәнеңне хатыныңа сөйләп, мактанып алсаң иде дә бит. «Менә, карчык, мунчаның ләүкәсен ясап куйдым. Менә, карчык, коена торган урынны рәшәткәләп алдым», – дип, хатыныңа күрсәтеп, икәүләп сөенешсәң иде ул. Мунча мәшәкатеннән туеп, әбәт ашап алгач, Морадыйм бакчасына чыкты. Помидорларның салынган ботакларын бәйләштереп куйды. Кызаралар, сабактагы килеш кызаралар... Алла боерса, берәр атнадан эшкә үзе белән помидорлар да алып барып булачак. Гел дә гел йомырка белән ипи ашаган ише булмас әле. Йорт ризыгы болай да бик тәтеми. Ике-өч көнгә җитәрлек итеп аш пешереп куеп, шуңа рәхәтләнә инде буйдак ир.

Төштә күргән хатын тагын күз алдына килде. Һе, кызыл күлмәкле инде алайса. Әнә теге күл артындагы санаторийда бардыр инде алар. Бардыр гына түгел, күптер. Бу җәйне ул тарафка барылмады. Бүтән җәйләрдә аяклары ут янганчы биеп кайта торган иде.

Көн яктысында майтарыласы эшләр бетеп килә. Ишек тирәсен яктырта торган утны кабызып, ир кеше көндез үк хәстәрләп, эскәмиягә тезеп куелган пыяла банкаларны юмакчы булды. Көндез үк җыеп куйган кыярлар салкын сулы зур табакта чират көтеп ята. Иртәгәгә калдырсаң да була торгандыр да... Иртәгә тагын нинди мәшәкать чыгасын кем белгән? Җыймый торасы булган икән лә кыярларны. Иң әүвәле банкаларны әзерләп куясы калган. Банка авызына Морадыймның ирләр эше өчен яралган зур куллары сыймый икән бит әле монда. Банкаларның эчен юуның башка төрле берәр хәйләсе бардыр инде аның. Пумала беләнме шунда.

Морадыйм банка авызына сыешлы берәр пумалаише әйбер караштырды. Күзенә берни чалынмады. Ул арада күл аръягында музыка уйный башлады. Талгын көйләрне дәртле бию ритмнары алыштырды. Авыл белән санаторий арасында зур гына күл бар югыйсә. Музыканың әкрене дә шул күлне җиңел генә «йөзеп» чыга. Ул тарафка җәяү бара башласаң, кимендә ярты сәгатьлек юл булыр. Музыка дәшә, чакыра, ашкындыра иде. Берәр сәгать биеделәр инде тегендә. Танцы дигәне ике сәгатьтән арыга бармый торган иде.

Әллә? Өлгерәдер әле.

Морадыйм банкаларны почмакта калдырып өенә кереп китте. Бераздан ишектән өстенә ак свитер, джинсы чалбар, ак туфлиләр кигән ыспай бер кеше килеп чыкты. Машинасын кабызды да музыка дәртләндереп чакырган тарафка элдертте.

Ул килеп җиткәндә парларның вальска әйләнгән чагы иде. Бу бию аныкы түгел. Ул, үзен танып, янына килгән белешләре белән кул биреп күреште дә ишек катында басып калды. Алар авылыннан санаторийда эшләүчеләр байтак. Кайсы музыка куеп тора, кайсы тәртип саклый, кайсы аның кебек маҗара эзли. Елның елында шушы санаторийда ял итүчеләр арасында да аны белүчеләр табылды: «Ярканат килде, Ярканат», – дип пышылдашып алдылар. Аны электән белмәгәннәр, бу адәм төн җиткәндә генә килгәнгә күрә ярканаттыр инде, дип уйлап куйдылар. Чыны бүтәнчәрәк иде.

Музыка куючы егет чынын белә. Берзаман чит ил музыкасы авазларын саф татарча җыр – дәртле музыка алыштырды:

Төнге юлдан кайтып килә,
Кайда йөргән Ярканат?
Безнең янда ял итеп кит,
Канатларың каккалап!

Көйнең беренче аһәңнәре, җырның беренче авазлары ишетелүгә ишек катында битараф бер кыяфәт белән ял итүчеләрнең күңел ачуларын күзәтеп торган Морадыйм бер омтылышта зал уртасына атылды да биеп тә китте. Калган биючеләр, һавада тилгән барын күргән чебиләр кебек, бер читкә савылдылар.

Морадыйм, мәйданның үзенеке генә икәнлеген барлап, бер бөтерелде дә, кош кебек канатын җәеп, тиз-тиз әйләнеп килде. Аннан кулларын артка таба җибәреп очып китәргә җыенган очкыч сыман биеп үтте.

Әй ярканат – яры канат,
Яры канат – ярканат!
Бер киләсең, бер китәсең,
Йөрәгемне яралап...

Биюче, җырның кушымтасына туры китереп, бер урында ут чыгарып тыпырдап алды, тагын очып китте. Мондый бию хәрәкәтләре татар биюеннән генә алынмагандыр. Анда кавказ халыклары биюләре дә төсмерләнә, молдаваннар биюләреннән дә нидер бар.

Хатын-кыз галәме эчтән генә, эх, шушы ир заты белән танышсаң иде, дип уйлый булыр. Шулай шәп итеп бии белгән егет иллене түгәрәкләсә дә, биегән минутларында ул егет була иде, чынында да бик гаярь, бик кызыклы кешедер, һичшиксез, шулайдыр, дип фараз итәләр иде алар.

Зифа да бу санаторийга, ялгыз башыма бер-бер иптәш, тиң таба алмаммы диебрәк килгән иде. Хыялында йөрткән кеше шушы биюче сыман булырга тиеш иде. Ләкин егет биюен тәгәлләгәндә аның бүлмәдәше каршына килеп тыпырдап, биюне Гөлүсәгә тапшырды. Димәк, Гөлүсәне сайлады. Ә залдагы күпчелек музыкаль калейдоскопның кабат «Ярканат»ка әйләнеп килеп җитүен көтә иде.

Бию сусынын канәгатьләндергән ир заты, халыкның чираттагы биюгә кузгалганын көтеп алды да, бию нияте булмаган ханым янына килеп утырды. Әдәп өчен генә аны биергә дә чакырып караган иде дә, ханым баш тартты: «Иртәгә биербез, яме. Мин биек үкчәле туфлиләремне киеп килгәч. Бигрәкләр дә оста биисең үзең. Синең белән һәрбер хатын-кыз бик теләп биер иде. Бии торсыннар, әйдә. Аннары мин сиңа үзем тиңемне күрсәтермен». Алар бу ханым белән музыка дөмберәсе арасында мизгелләр аулый-аулый кызык кына сөйләшеп алдылар. Кайдан килгән, болай шәп итеп биергә кайда өйрәнгән? Күптән игътибар тоймаган Морадыйм ачылып китте.

Биергә өйрәнү тарихы кызык булган икән аның. 27 яшькә җиткәнче биеп карамаган егет дустының туенда биер өчен бер кичтә өйрәнгән. Себердәге вахтовиклар арасында кем генә юк. Морадыйм сынатмасын өчен, һәркайсы бер бию элементын өйрәткән. Асылда, Морадыймда бию куәсе булган икән бит. Югыйсә бер кичтә генә шултиклем соклангыч килеп чыккан биюне отып ала алмас иде ул. Аяк табанын китереп куешларына кадәр сәхнәдә биючеләрнеке кебек килеп чыга бит. Морадыймның Себердән алып кайткан биюе «Ярканат» җырына менә дигән ятты. Кушаматлы да булды. Хәер, бу кушаматны аны яхшы белгән кешеләр генә әйтә. Ә менә бу биюнең Морадыйм өчен чын кыйммәтен бер кеше дә белми. Ул аны хәтта үзе дә аңлап бетерми. Шушы – үзенеке генә булган биюне биегәндә ул үзен чыннан да һавада канат каккан бөркет кебек, җирдәге шаман кебек хис итә. Ирешелмәгән хыяллары вак-төяк булып кала. Ә бит бәләкәйдән анасына сарык фермасында ярдәмләшеп, авыр эштә изелеп, зур хыяллар корырга да кыймыйча үскән, зур укулардан мәхрүм калган авыл малае да күккә баккан, очкыч эзләренә карап күзен талдыргандыр. Санаторийдагы танцыларга килеп йөрәгән басу кадәресеннән дә еш кына тыела ул. Чөнки кыяфәте чын егетләрчә булгач, затлы гына тоелган ханымнар аның муенына сарылалар. Ә ул алар белән ни турында сөйләшергә белми. Югыйсә белә инде, күбесе сүз сөйләшергә түгел, мәхәббәткә, сөелүгә зарыгып килгәннәр. Ләкин барыбер Морадыймның да кеше арасында кеше буласы, дөнья хәлләрен сөйләшәсе, сәясәткә кагыласы – кыскасы, заман тоткан ирләр кебек кыланасы килә. Тик барып чыкмый, шул – фермада узган бала чагын искә төшерүдән уза алмый. Бервакыт, артистка бугай иде ул кәмәш, әйтеп куймасынмы: «Синең эчтәлегең формаңа туры килми», – дип. Озак уйлап йөрде ул әлеге артистканың сүзләрен. Башына барып җиткәч, бик үртәлде. «Сезнең эчтәлекләрегез формаларыгызга яраш лы булсын өчен кемнәрдер кулларын кара майга катырып, кара эштә йөриләр, кәнтәй!» Кычкырып әйтмәде инде бу ачы сүзләрне. Әмма шуннан соң тиңнәрен генә караштыра башлады.

«Ярканат» тагын бер-ике биелде әле. Аннары Морадыйм, яңа танышы ишарәләгән ак плащлы хатын-кызны чакырып, кара-каршы биегәннән соң, кинәт төшендәге кызыл күлмәклене исенә төшереп, як-ягына карангалады. Әмма, кичләр салкынча булгач, хатын-кыз затларының күбесе плащтан иделәр. «Төшкә алданып йөргән мин юләр», – дип уйлады да ир, Зифаны корпусларына кадәр озата китте. Аллея буйлап бер-ике кат әйләнделәр. Беркатлы Морадыймга хәл-әхвәлен сөйләп алырга шул кыска ара да җитте. Аның кыяр тозлыйсы банкалар белән әвәрә килүеннән Зифа рәхәтләнеп көлде. Күл артындагы авылда гына яшәгәнен белгәч, бу тиклем авыр эшне башкаруда булышу өчен Гөлүсә белән килеп китә алуларын әйтеп сөендерде.

Морадыйм иртәгәсен төшке аштан соң кызларны килеп алды. Зифа плащын салып чөйгә элгәч, кызыл күлмәгеннән калды. Морадыйм сискәнеп китте. Әллә... төше рас киләме?

Өчәүләшеп ун банка кыярны кышка маринадллап та куйдылар. «Ашашырга да килербез, чакырсаң», – диешкән булдылар.

– Ә берәрегезне алып калсам? Ул чагында икенчегез килә дә килә инде.

– Юк шул, абзыкай, без үзебез алып китә торганнардан. Кунакка чакырырбыз.


Әйе, хатын-кызлар баш бирми хәзер. Берсенең дә торган җирен, эшләгән эшен ташлап, Морадыймның яңа мунчалы йортына килен булып төшәсе килеп тормый.

– Карарбыз әле анда. Кич танцыга киләм. Шунда дәвам итәрбез сүзне. Сезнең тагын тугыз көнегез бар түгелме соң? Теттереп биибез әле сезнең белән, Алла боерса.

Кызлар күл буйлатып җәяү генә кайтмакчылар иде дә Морадыйм аларга көмеш сулы чишмәне күрсәтергә булды. «Шул чишмәләрнең суын эчкәнгә күрә бу төбәк халкының тешләре шикәр кебек. Картаясыгыз килмәсә, китмәгез бу авылдан. Берегезне барыбер алып калам – аны белегез!» Кемне алып каласын тәгаенләп, Зифаның битеннән үбеп алды:

– Кич белән дә шушы кызыл күлмәгеңне ки, яме!

– Матур күлмәкләрем тагын да бар минем.



Рәсем: Наталья Васильева

* * *

Бу кичне дә Морадыйм, гадәтенчә, соңлап килде. Бу кичне дә: «Ярканат! Ярканат!» – дип пышылдашып алдылар. Аның килүен концерт көткәндәй көтәләр иде кебек.

Зифа да көтте. Бу кичне могҗиза булыр сыман көтте. Морадыйм «Ярканат»ны, мөгаен, аның өчен генә биер сыман көтте. Гөлүсә бераз көнләсә дә, сиздермәде. Икенче бер иш табып, биергә гел аның белән чыга башлады. Ошатыштылар, ахрысы. Инде әкрен биегән чагында яңаклары яңакта ук иде. Ял иткәндә романнарның әйләнеше тизләнә.

Морадыйм ишек катына килеп баскач ук, Зифа бер тыйнак рәвеш алган иде. Хисләрен сиздермәскә өйрәнеп беткән ул. «Ак танец» игълан ителгәч тә Морадыймны биергә чакырам дип атылмады. Аның каруы, бер чытлык нәстә, йөгереп барып, Морадыймның муеныннан кочып алды да карышырга азапланган ирне уртага алып кереп китте. Һәм... бүтән ычкындырмады да.

Аларның биеп азапланганнарын бераз карап-карап торды да Зифа бүлмәләренә кайтып китте. Чәй кайнатып, табын әзерләп, Гөлүсәне көтә башлады. Бер мәлне ишек шакыдылар. Бу Гөлүсә түгел иде, аның үз ачкычы бар. Морадыйм булуы ихтимал. Зифа ачмаска булды. Әрәм булган киче өчен үпкәләгән иде ул аңа. Утны сүндереп, балконга чыгып басты да Гөлүсәне шуннан карап кына көтеп тора башлады. Балкон турлап, аллеяда чытлык кызның көлгәне һаман саен ишетелеп торды. Димәк, Морадыйм да шунда. Көлү аңа багышланган булырга тиеш. Бу Чытлыкның узган җәйдә үк Морадыймның күңелен кайтарган артистка икәнен белгән булса, бәлкем, Зифа үпкәләп тә тормас иде.

Үпкәләп маташканына, ишекне барып ачмаганына соңыннан ул үзе дә гаҗәпләнде. Битеннән бер үпкәне өчен генә ирне үзенеке дип тамгалап куярга ни хакы бар иде аның? Харап инде, кыяр тозлашкан, янәсе! Юк шул, бүтәндә шул хикмәт. Санаторийның, ял итү урынның логикасы бүтән. Монда сәламәтлек кенә түгел, бәхет тә эзләп киләләр. Ни өчендер адашкан бәхетләре ял иткән җирләрендә көтәдер сыман тоела. Зифа бу санаторийда иң бәхетле, иң сәгадәтле гомер мизгелләрен бер тапкыр кичергән иде инде. Ире белән. Аның вафатына биш ел тулганда сынган канатыма пар таба алмаммы икән дигән өмете бар иде. Аз гына, әмма бар иде. Морадыймда иренең чалымнарын күргән иде ул. Шуңа күрә танышыр-танышмас бу ир затының бүтән берәү кочагыннан ычкына алмавын Зифа хыянәт сыман кабул итте.

Бу вакытта Морадыйм, югарыдагы балконга каерылып-каерылып карап, бер генә җөмлә әйтте дә, Чытлыкны этеп җибәреп, авылына кайтып китте: «Тагын булмады. Рас килмәде төшем!»

Кадерле «Сөембикә» редакциясе!



Армиядән кайткач, Казанның «Татаргазпромстрой» берләшмәсенә рәссам-бизәүче булып урнаштым. Берничә елдан Роторная урамыннан бер бүлмә бирделәр.

Маляр булып эшләүче Миңнебай абый белән без шунда таныштык. Ул хатыны Гөлфия апа, ике кызы белән миннән бер генә кат өстә яши икән. Бүлмәмә ремонт ясарга да, өйләнгәндә туй уздырырга да алар ярдәм итте. Ул вакытта әнием вафат булган иде инде, туйга әти ялгызы гына килде. Аннары Гөлфия апаның 50 яшьлек юбилеен бергәләп үткәрдек. Шуннан күп тә үтмәде, үпкәсе ялкынсынып, Миңнебай абый үлеп китте. Гөлфия апа ялгызлыкны бик авыр кичерде, елады да елады. Нәрсә булса да булыр, дип, мин аны әти белән кавыштырырга уйладым. Башта Гөлфия апа бик каршы торды. Алай да авылдан әтине кунакка чакырып, үзләрен бераз аралаштырдык. Бер-берсен ошаткан кебек булдылар. 1982 елда Гөлфия апаны беренче тапкыр әти янына Чапшарга алып кайттым, никах укыттык.

Бик авыр булса да, әти Гөлфия апа янына Казанга күчеп килде. Башта Гөлфия апаларда яшәделәр, ул әтине үзе янына «Спартак» фабрикасына эшкә дә урнаштырды. Тора-бара үзләренә дә бер бүлмә бирделәр. Шулай итеп, әти Казан кешесенә әйләнде. Алай да авылны сагынды, Гөлфия апа белән гел Чапшарга кайтып йөрделәр.

Сабыр, мөлаем Гөлфия апаны авылда да бик яраттылар. Безнең гаиләнең чын-чынлап үз кешесенә әйләнде ул. Бәйрәмнәрне, юбилейларны гел бергәләп уздыра идек.

1993 елда әти пенсиягә чыккач, алар Чапшарга яшәргә кайтып киттеләр. Яңа мунча өлгерттеләр, бозау алып җибәрделәр, тавык-чебеш тоттылар. Мин дә вакытым булган саен авылга кайтырга тырыштым. Шәһәр кызы булган Гөлфия апаның, халат киеп, печән ташуына соклана торган идем.

Безнең якта чишмәләр күп. Гөлфия апа чишмәгә суга төшәргә ярата иде. Ашарга пешерергә бик оста иде ул, күз ачып йомганчы табынны кора да куя. Әле ул вакытта өйдә газлары да юк, электр плиткасында, мичтә пешерәләр. Суыткычлары да соңрак кына булды. Өебездән бер дә кеше өзелеп тормады, кергән берсен Гөлфия апа чәй эчертеп чыгара, аннары әти белән парлашып аргы якка, Тарих абыйларга чыгып китәләр.

Гөлфия апаның кияве Госман да Чапшарны яратты. Казанда берәр эше бармаса, күңеле үсмәсә, авылга кайтыр иде. Безнең авылның табигате бик матур: ул елгалар, таулар, болыннар, урманнар, чишмәләр! Шунысы кызганыч, бу кешеләрнең хәзер берсе дә исән түгел инде.

Әти Казанга кунакка килгән җиреннән бер тәүлек эчендә кинәт вафат булды. Сызланып, кеше күзенә карап ятмады. Без аны үзенең васыяте белән Чапшарга алып кайтып җирләдек. Гөлфия апа әтине, Чапшарны бик юксынды. Әтиебезне шулай яраткандыр дип башыма да китермәгән идем. Алар бергә егерме дүрт ел гомер иттеләр. Әтинең вафатыннан соң, Гөлфия апа җәйне үткәрергә дип минем бакчама килде. Миңа иптәш булды, киңәшләрен бирде, булышты. Кем уйлаган, көзгә таба үзе дә авырып, һич көтмәгәндә безне ятим итеп китеп барыр дип? Әтидән соң ул да бер генә ел яшәде. Соңгы сулышына кадәр телендә гел әти булды.

Инде хәзер бакчама барган саен Гөлфия апаны сагынам. Нигә тагын бер-ике ел булса да яши алмадың, дим. Мунча да өлгерттем. И шатланган булыр идең, дим. Ничек кенә булса да, бергәләп йөргән булыр идек әле. Гөлфия апаның каберенә барган саен: «Рәхмәт сиңа, әтине карадың, ике гомер яшәсәм дә, боларны сиңа түләп бетерә алмам», – дип рәхмәтләремне әйтәм. Үземне әле һаман да аның алдында бурычлы саныйм.

Зөлфәт ХӘЙРУЛЛИН.
Казан шәһәре.

Беркөн урамга чыксам, почта тартмасына «Сөембикә» журналын салганнар. Түзмәдем, кочаклап алдым журналны. Әй безнең татар кызларының матурлыгы!

Былтыр игезәк туганым «Триколор» бүләк иткән иде. Иң беренче татар каналларын эзләп таптым. Ай буе күземнән яшь кипмәде – елый-елый татарча тапшырулар карадым. Андагы кешеләрнең кайсын – әнигә, кайсын – әтигә, туганнарыма охшаттым. Рәхмәтуллин фамилияле кеше чыкса, туганым түгелме дип, таныш чалымнар эзли идем.

Әтиебез Мингали үлгәнгә 60 ел. Әниебез Гайшәбану 102 яшенә кадәр яшәде. Ун бала үстерделәр. «Геройана», «Хезмәт ветераны» дигән мактаулы исемнәргә лаек булды.

Әниемнең әтиләре Саба якларыннан булганнар. 1910 елда язмыш аларны Себергә китергән. Беренче елларны урманда землянка казып яшәгәннәрен беләм. Аннары Икшермә дигән авыл булып яшәгәннәр. Ихтимал, Саба районындагы Икшермә авылыннан күчеп килгән булганнардыр. Соңрак хәзер мин яши торган Коврига авылын салганнар.

Бүгенге көндә без – әти-әнинең алты кызы – исән-сау. Олы апабызга – 82 яшь, без – игезәкләргә 76 булды, иң яшебезгә – 60. Хәләхвәл белешеп яшибез. Яшьрәк вакытта Казанга кайтмавыбыз үкенderә. Картая-картая, туган җир, туган тел шулкадәр сагындыра икән. Без алтынчы класска кадәр мәктәптә татарча укыдык. Аннары уку рус телендә булды. Ун ел Украинада яшәдем, төзелеш кранында эшләдем. Тагын ун елым ерак Себердә узды. Туган телемне бик сагынам, дога урынына гел кабатлап йөрим: «И туган тел, и матур тел!» Әле ярый татарча газета-журналлар, татар каналлары бар.

Бәдерхәят РӘХМӘТУЛЛИНА.
Красноярск крае,
Пировский районы, Коврига авылы.



Әтием Гыйлаҗ Садриев 1916 елны Тәтеш районы-Алабирде авылында туа. Әтиләре Садрый бабай оста тегүче була, тормышын шуның белән алып бара.

Сәбәбе нәрсә булгандыр инде – этигә 2 яшь тулганда, дүрт баласын ятим калдырып, әниләре вафат була. Безнең әти дәү әти тәрбиясендә үсә. Калган туганнары үсеп, Донбасс шахталарына барып төпләнә.

Әти белән әниебез Маһруйбикә 1938 елны өйләнешә. Мин – аларның абыйдан соң туган икенче балалары. Аннары инде сугыш. Әтине сугышка озатканны хәтерләмим. «Абыеңны җитәкләп, сине күтәреп, капка төбеннән озатып калган идем», – дип сөйли иде әни. Ә менә кайтканы исемдә. 1946 елда, чияләр шау чәчәктә утырган май аенда кайтты ул. Бик чибәр кеше иде әти. Башында яшел пилотка, пилоткасы астыннан бөдрә чәчләре ташып чыккан. Тешләре ап-ак. Күкрәге тулы орден-медальләр – Бөек Ватан сугышының I, II дәрәҗәдәге орденнары, «Кызыл Йолдыз» ордены, Германияне җиңү медале...

Капкадан әти килеп кергәч, баскан урынымнан кузгала алмый торганымны беләм. Әти безне күтәреп алган иде. Бер беләгендә – абый, берсендә – мин. Шушы мизгел гомерем буена күз алдымнан китмәде.

Без аның кайтуын бик тилмереп көткән идек шул. Авылга солдатлар кайта башлагач, көн дә күпер төбенә барып басабыз да, берәр кайтучы безнең якка борылмас микән, дип, күз текәп көтәбез. Кайтучылар бар, тик берсе дә безнең капкага гына борылмый. Өйгә кайтып, дәү әнине кочаклап елыйбыз. Ул безне җитәкләп, яңа гына кайткан фронтовикның капка төбенә алып бара. Анда инде халык җыелган була.

Сугыш вакытында әниләр кичергән авырлыклар искә төшеп, йөрәкне телеп-телеп ала. Бер күренеш һаман күз алдымда. Кыш көне иде. Әни каяндыр кайтты. Аягындагы чабатасы шакырдап каткан. Пычак белән кисеп, дәү әни көчкә салдырды. Ул көнне алар колхоз эше белән җәяүләп Тәтешкә барган булганнар. Кайтканда буран чыгып, адашканнар. Шулай интегеп яшәгәнгә, гомере дә кыска булды, 54 яшендә китеп тә барды.

Әти баштарак 1248 нче Запорожье тар-мар итү – танкка каршы артиллерия полкында төзәүче булып хезмәт итә. Аларның полкы өч тапкыр Днепрны кичеп чыга. Беренче тапкыр 1943 елда, пулемет белән тез тиңентен суда килеш, бер карыш җирне яулап, сигез контратаканы кире кайтаралар. Әти 50 фашист солдатын дөмектерә. Икенче тапкыр елганы шушы елның 1 ноябрендә кичәләр. Өченче тапкырында каршы якта немецлар белән йөзгәйөз очрашырга туры килә. Кул сугышы башлана. Әтием өч немецны юк итә. Бу батырлыклары өчен «Кызыл Йолдыз» ордены белән бүләкләнә.

Сугыш бетеп, этиләр кайтса да, тормыш алай тиз генә җайланмады әле. Әти механизатор булып эшләде. Кыш көне бездән сигез чакрымдагы МТСка ремонтка йөри иде. Сентябрьдә энекәш туды. Абый белән җитәкләшеп, кырга этидән сөенче алырга киттек. Әти тузан эчендә икмәк суктырып ята иде. Безгә берәр йомырка бирде. Шул көн, чәчәкле болын, тургайлар, этинең шат йөзе әле дә күз алларымда.

Мин 1 нче сыйныфка кергән елны әти безне Донбасска алып чыгып китте. Анда дүрт ел яшәгәч, әнинең абыйсы янына Кыргызстанга күчендек. Биш елыбыз анда үтте. Белмим, язмышыбыз тагын кайларга әйдәкләр иде, әнинең авылда калган сеңлесе хат язды: «Апаҗизни, мин кияүгә чыгам, әни берүзе генә кала, кайтыгыз!» Шулай итеп, без авылга кайтып төпләндек.

Әнинең әтисе Шәвәли бабай хәлле кеше булган. Совет хөкүмәте бар мөлкәтен талап алып, өч катлы йортларын мәктәп иткән. Үзен дә авылдан сөрәсе булганнар, авыл халкы җыелып килеп, бабайны кудырмаган. Соңыннан да кем ничек булдыра ала, шулай булышып торган. Безнең Алабирде халкы әле дә шулай, бер-берсенә гел булышып, ярдәмләшеп яши. Үзем дә фельдшер булып авылда 30 ел эшләдем. Рәхмәттән башка сүз ишетмәдем.

Рузалия АДАЕВА.
Казан шәһәре.
Фото: Гыйлаҗ Садриев (сулда).

Хөрмәтле укучыларыбыз! Сездән хатлар көтеп калабыз. Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2. e-mail: ssuum@yandex.ru

PRESSA



АСЫЛЪЯРГА ХАТ

ТУЙГА ӘЗЕРЛӘНӘБЕЗ. КЫЗЫБЫЗ ТУЕНА. УЛ ӘЛЕ ТУМАГАН, ЛӘКИН МИНДӘ НИКТЕР ШУНДЫЙ ХИС. ЯҢА КЕШЕ ЯҢА ТОРМЫШКА АЯК БАСА, Ә БЕЗ, ӘТИ-ӘНИСЕ, АҢА БИРНӘ ӘЗЕРЛИБЕЗ...

Гүзәл СӘГЫЙТОВА

Матур, бик нәзакәтле әйберләр сайладык, махсус мендәр-юрганнар ясаттырдык, хәтта икебезгә бертөрле күлмәк тә тектердем. Дөрес, балага алдан әйберләр алып куярга ярамый дигән хорафат бар, ләкин ул инде дөньяга килгәч, бу әйберләрне кайчан сайлап өлгерергә дә, кайдан нәрсә эзләргә? Нәрсә, ничек туры килә шуңа ябышыргамы? Ашыгып, кабаланып күп яшәдек инде. Үзебезне кадерсезләп, уңгасулга карарга вакыт тапмыйча йөгердек тә йөгердек. Кызымны көткән арада миңа 36 тулды: ике шәһәр «яуланды», кызыл диплом, кандидатлык диссертациясе, сертификатлар киштәдә тузан җыеп ята. Кайчандыр, группадашларым: «Сәгыйтованың бала тәрбияләп, өйдә генә утыруын күз алдына китермибез», – диләр иде, хәзер исә мин әзер. Һәрхәлдә, шулай тоела. Бу бәхет-сынауны тулысы белән татып карыйсым килә. Юк, бала көтәм дип, мин бөтен дөньямны ташлап, шул бер вакыйгага гына табынып яшәмәдем, дистанцион рәвештә эшләвемне әле дә дәвам итәм: «Ком сәгате» тапшыруында мөхәррирлекне, «Калеб» белән җитәкчелекне. Консерваториядә дә онытмыйлар – шалтыратып, татар теленә кагылышлы киңәшләр сорап кына торалар. Еш кына мин, киресенчә, үземне карынымдагы бала алдында гаепле дә сизәм. Һавада йөрү, алдан ниндидер курсларда дәресләр алу, тудыру процессына әзерләнү урынына дөньям ноутбук һәм телефон тирәсендә әйләнә кебек... Күңелемнән мин аның белән еш сөйләшәм, әлеге сүзләрне ул дөньяга килгәч әйтә алырмынмы, дөнья мәшәкатьләренә чумып, бу кадерле сүзләр онытылмасмы? Ә, бәлки, мин үзгәрермен, каты күңелләләнермен... Ә бәлки... бөтенләй булмамын... Бу арада дустым Вәсиләне (Вәсилә Фәттахова – *авт.*) еш искә алуым да тәэсир иткәндер... Төрле уйлар килә, саташулы төшләр керә. Нечкә, бик нәзберек чак... Барысы да Ходай кулында. Теркәлсен ул сүзләр, гомере булса, кызым аларны укыр, кайбер фикерләрне, бәлки, хәтерендә саклар. Насыйп булса, үзе дә туачак кызы яисә улына хат юллар.

Кызым, ә син беләсеңме: мин бит сине күптән яратам. 20 ай буе көткән нәниебез син безнең! Ни өчен 20 ай дисеңме? Чөнки синең җаның безне сайлаганчы 11 ай вакыт узды, бер елга якын синсез яшәдек. Бу вакыт аралыгы шәхсән миңа бик озак тоелды, өметсезлеккә бирелгән чаклар да булгалады. Ә әтиең, тиздән синең дөньяга килереңне төгәл белгән кебек, тыныч кына яшәде дә яшәде, аның ышанычы мине хәтта гаҗәпкә калдыра, кайвакыт сәерсендерә иде... Зур шатлык хәбәре алып килгән 1 август көнен мин инде хәзер төгәл генә хәтерләмим – аңардан соң күпме сулар акты, күпме сынаулар үттек һәм менә шушы көннәрдә синең белән күзгә-күз очрашырга әзерләнәбез.

Нәкъ менә шушы бушлыкны тутыру өчен бүген кызыма хат язарга булдым.

Син туасы көнне бар нәрсә дә кулай килеп торсын иде, иң җаваплы мизгелләрдә син миңа, мин сиңа булыша алсак иде. Әлегә мин синең нинди булуыңны күз алдына китерә алмыйм. Әтиеңә охшарсыңмы син, миңамы, икебезгә дәме? Кара чәчле булырсыңмы, зәңгәр күзлеме? Матурмы, бигүк түгелме? Кайсыбызның кайсы сыйфатларын үз итәрсең?! Иң мөһиме: сау-сәламәт бул, кызым! Әлбәттә, Ходайдан һәрьяклап камил булуыңны сорыйм: сәламәт тә, акыллы да, матур да, сөйкемле дә, иманлы да. Ничек итеп сиңа эндәшербез икән? Кызым, күз нурым, кошчыгым, алтыным, җаным, акыллым, сандугачым, җимешем, Асылъярым?! Әйе, Асылъяр! Бу синең исемең. Яратырсыңмы син аны, әллә үскәч безгә үпкәләп йөрерсеңме? Ләкин аны син үзең сайладың. Без сиңа бик озак исем эзләдек, бервакыт уйлар Айсылу, Әминә тирәсендә бөтерелде. Зөләйха, Мәрьям, Мәдинә... Ләкин никтер ул исемнәр белән сиңа дәшәргә тел әйләнмәде һәм аерым берсенә тукталган вакытта да күңел һаман башкасын эзләде. Асылъярда исә шикләр булмады, шул ук минутта мин бу исем белән сиңа дәштем

PRESSA

һәм әтиеңнең исем-фамилиясен куеп карадым да, аңладым – артка чигенү юк. Яруллина Асылъяр Айнур кызы. Мирхәйдәр Фәйзи пьесасының исембашына чыккан Асылъяр. Бәхетең белән ту, балам! Исемең җисемеңә туры килсен!

Һәрбер кеше бу дөньяга нәрсәдер өчен килә, синең дә үз миссияң. Җаның әти белән әни итеп безне сайлаган икән, моның да үз хикмәте барлыгына ышанам мин! Һәм нәкъ хәзер, шушы урында, вакытта. Ходай безгә зур бүләк ясады һәм ул бүләкне тартып алмас, безне кара кайгылардан аралар дип өметләнәм. Сине саклар өчен хастаханәдән хастаханәгә йөргән вакытта, «бөтен нәрсә Ходай кулында диган» хакыйкать тә онытылып, күңелсезләнгән вакытлар булмады түгел. Бу айлар эчендә нинди генә язмышлы кешеләр белән очрашырга, интернетта нинди генә тарихлар укырга туры килмәде... Минем белән бер палатада яткан ханым бу бүләкне 16 ел көткән, карынындагы өченче нарасыен 40 нчы атнада югалткан. Икенчесенең баласы бер көн яшәп, бер сәбәпсез тын алудан туктаган... Юк, юк, бу турыда уйларга да куркыныч! Без үтәсе юл якты, матур булыр дип өметләнәм. Иң авыр чакларда да шуңа ышандым. Һәм без 9 аебызга җитә алдык.

Бергә-бергә үссәк, камилләшсәк иде! Син мине тагын да яхшы якка үзгәртсәң иде!

«Бала булса, кыз булсын» – яшьрәк чакта шундый уйлар белән яши идем, әтиең белән очрашкач, андый кискен фикерләрдән баш тартсам да, кыз турында хыял югалмады. Үземнең әбекәеңә мөнәсәбәтемне белгәнгәдер, бәлки. Кызларның күңеле бик сирәк «далада» буладыр. 95 яшьлек карт бабаң исә әнә: «Кыз булуы яхшы булган, курчак итеп уйнар» дип әйтә ди бит әле! Курчак итеп энекәшемне – Айдар абыеңны үстердем инде, сине мин дус итеп тәрбияләргә тырышырмын. Әлбәттә, күп нәрсәләр язасы килә. Ләкин бөтен булмышымны биләп алган хис-фикерләрне кәгазьдә җанландырыр өчен аерым бер сәләт кирәк. Шулай да исән-сау булсак, сиңа ел саен хатлар язарга тырышырмын, кызым. Әлегә бүгенгемнән берничә киңәш.

Кыю бул. Минем күп вакытым икеләнеп узды. Кеше нәрсә әйтер дигән фикер белән яшәмә. Бер кешенең дә икенче кешедә артык эше юк. Шул ук вакыт артык әрсез һәм үз-үзеңә ышану да начар. Алтын урталык сайларга тырыш!

Бәхет өчен күп кирәкми. Хатын-кызга бигрәк тә. Эштәге уңышлар, мәртәбә, югарыга омтылу – болар берсе дә шәхси бәхетне алыштыра алмый. Исемең Асылъяр, кемнеңдер асыл яры булырсың, озак ялгызлыкта йөрмәссең дип ышанам. Чөнки ялгызлык – зур сынау. Сиңа андый сынауларны узарга язмасын. Кайвакыт бәхетне озак көтәргә туры килә, вакыты килеп җитмичә никах сәгате сукмый, диләр. Ә инде бәхет кулга килеп кергән очракта син аны ваклама, нинди генә авыр чорда да **иң матур мизгелләрне искә төшер,** яныңдагы кешенең сиңа Ходай тарафыннан билгеләнгәнен онытма.

Гомумән, **син үтәсе юл күптән билгеләнгән,** мин моны үз тормышым аша аңладым. Шуңа күрә «ник алай, ник болай түгел» дигән бәргәләнүләр вакытны юкка сарыф итү – ничек булырга тиеш, шулай булган. Нинди генә очракта да язмышыңа **рәхмәтле бул!** Бу бик мөһим! Тормышта **һәр кеше үз дәресләрен уза,** иң кыен вакытларда шуны искә төшер.

Бөтен кешегә дә ярарга тырышма, **үзеңә хыянәт итмә.** Ничек бар, шундый бул. Яраткан кешеләр сине ничек тә кабул итәчәк, сөймәгәннәр исә кырык төрлегә әйләнсәң дә, бу корбанны бәяләмәячәк.

Башкаларга охшарга да тырышма, син – уникаль, тормышта синең кебек башка берәү дә юк – шуның кыйммәтен онытма. Үз-үзеңне тулысынча кабул итү, чын, табигый, ирекле булу – зур бәхет!

Ихлас бул! Ихласлык бүгенге көннең иң сирәк күренеше һәм шуның белән кыйммәт. Ихласлык турында иң күп сөйләүчеләр дә, ни кызганыч, аңардан ерак булырга мөмкин. Сүзләргә артык ышанма, кешенең эш-гамәлләренә игътибар ит!

Укуыңда, эшләреңдә **камиллеккә омтыл,** ләкин перфекционизм дигән сүзне оныт. «Лучшее – враг хорошего», дип юкка әйтмиләр, гадәттә, артык тырышкан саен, начаррак була. **Үзеңә хаталар эшләргә рөхсәт ит.**

Кешеләргә **үпкә саклама.** Кемдер сине рәнҗеткән икән, гафу итә бел. Ул кеше бәхетсез яисә шул мизгелдә кәефсез, шуңа да ниндидер начарлыкны үзеңә мөнәсәбәт дип кабул итмә. Гафу итү исә аларга түгел, үзеңә кирәк. Күңелеңдә начарлык саклый күрмә, аларның төрле авыруларга әйләнүе турында бүген еш сөйлиләр, ә син сәламәт булырга тиеш!

Үзеңне кара, дөрес туклан, кирәгенчә йокла, саф һавада йөр, юкка-барга борчылма. Үтүкләнмәгән, тишек, таушалган әйберләр кыз кеше өчен төс түгел, матур киен. Үзеңне ярат, иркәлә, физик күнегүләр турында онытма. **Тормышыңны** беркайчан да бер кеше, бер өлкә белән генә **чикләмә.** Кызыксынуларың, шөгылең, дусларың булсын. Шул ук вакытта **артык сибелмә** дә. Дәрт, рәхәтлек бирә торган тәкъдимнәргә «әйе» дип җавап бир, күңел кушмаган, аягың тартмаган, үзең теләмәгәннәреннән баш тарта бел.

P. S. Бала тудыру йортына киткәндә бу хатны иремә, йә берәр дустыма калдырырмын дип ниятләсәм дә, төгәлләнмәгәч, берсенә дә тапшырмадым. Менә хәзер, кызым туганга өченче ай киткәч, искә төште ул. Онытылыр да! Шушы кыска гына вакыт аралыгында күпме вакыйга, чынбарлык белән очрашу! Романтик дулкынга әле генә көйләнеп барабыз. Нәкъ шул дулкында яңа хат бөреләнә башлады. Хәзер инде адресатның нинди икәнен дә төгәл беләм. Шуңа да ул әманәттә бөтенләй башка сүзләр булыр кебек. Монысы исә шулай, тәмамланмыйча калсын.

КОНТАКТТА: ://syuyumbike



Вәлитова Резида Фәрит кызы

Башкорт дәүләт университетының филология факультетын тәмамлаган.

29 яшьлек улы, 10 яшьлек кызы бар.

Карьера: Уфада чыга торган «Кызыл таң» газетасының яңалыклар бүлеге мөдире, «Юлдаш» радиосы алып баручысы.

Тормыш шигаре:
«Тормышның кояшлы ягында яшәргә!»

https://www.facebook.com/suyumbike.zhurnaly

Илледә дә җиләк кебек икән!

«Илле яшьнең аръягында да тормыш булырмы икән?» – дип уйлаган чаклар бар иде... Бар икән! Кызыклы тормыш икән бит биредә.
Яшьлек эзләнүләре, үз-үзеңнән канәгатьлек таба алмыйча күңелне кыйнаулар, икеләнүләр, кыюсызлык артта калды. Бәхәскә керүчеләргә караганда, фикереңә колак салучылар, киңәш сораучылар күбрәк. Кемнең кем икәнлеге дә синең өчен ярылып ята, битлек астына яшерелгәнне күрә торган күңел күзе дә очланды.

Урамнарга чыгу күңелле!


Халыкның күпчелеге сәламәт тормыш белән яшәү яклы. Уфа урамнарында велосипедчылар арта, скандинав таяклары белән өлкәннәр җилдерсә, яшьләр күпләп йөгерергә чыга, чаңгы, тимераякка баса. Һәр авылда диярлек хоккей тартмалары бар, чаңгы юллары салынган. Район үзәкләренең күбесендә бассейнлы заманча спорт комплекслары төзелә. Тәмәке тартучыларга көн бетте, беркемнең дә төтенгә түзәсе килми. Яшьләр арасында сыра эчү, тәмәке тартулар елдан-ел кими. Узган гасырның туксанынчы еллары белән чагыштырсак, аерма – җир белән күк арасы, канәгать булып яшисе генә!

Сөембикә кавеменнән булу – горурлык!

Дөнья киңәйде хәзер, башка кыйтгага барып җитәр өчен 3-4 сәгать вакыт җитә. Кайсы илгә барсаң да, татарны беләләр, хөрмәт итәләр. Төркиядә хамамга кергәч, хатын-кыз юындыручыны сорадык. Андыйлар сирәкләргә генә эләгә икән. «Алар бит татар, Сөембикә кавеменнән!» дип, үзебез теләгәнне табып китерделәр, ул килеп җиткәнче милли ризыклары белән сыйладылар. Халкым өчен кимсенү, хурланудан сакласын, аның өчен горурлык хисе нинди татлы икән!

сөендерде

көендерде







Очканында ни булыр?

Кызым үсеп килә, минем бөреләнгән чәчәгем менә-менә ачылырга тора. Кыраулардан сакларгамы аны, әллә чыныгып үссенме? Аның белән яшь арабыз – 41 ел. Мин үсмер чактагы кайбер тәрбия кануннары бүгенге заманга туры килеп бетми. Балам заманча да булсын иде, иптәшләре арасында «ак карга» булып аерылып тормасын, шул ук вакытта дәү әниләр тәрбиясен дә онытмасын иде. Менә шушы «кылыч» өстеннән ничек итеп исән-имин үтәсе?!

Ни өчен 25 тапкыр?!

Озак еллар инде журналист булып эшлим. Шул вакыт эчендә, кем әйтмешли, агын да, карасын да күрергә туры килде. Ләкин бер нәрсәгә күңел һич кенә дә ияләшә дә, ризалаша да алмый. Күптән түгел генә хезмәт хакы минекеннән 25 тапкыр күбрәк булган бер халык хезмәтчесеннән интервью алдым. Әллә ни артык җире дә юк кебек: эшләгән эшендә дә, сөйләгән сүзендә дә. Безне, совет балаларын, һәркем тигез дип үстергәннәр иде. Ул да бит совет баласы булган кайчандыр...

Кемгә ышанырга белмәссең

Украинадагы танышлар белән сөйләшсәң, анда сугыш та юк, бер-бер артлы чыгып торган фетнәләр дә зарарлы түгел, диләр. Алар фикеренчә, Россиягә ышаныч юк: әле бер илдә, әле икенчесендә безнең илчелекләрне ябулары шул турыда сөйли, диләр. Әллә безнең нинди алга киткән, тынычлык сөюче ил булуыбызны белмиләр микән? Дөньябыз дөрес мәгълүмат җитмәүдән җәфа чигә, ахрысы.

PRESSA



Фото: Розалия Кәримова

АВЫЛ «БРАЧЫ» – РӘХМӘТ ФӘРЕШТӘСЕ

Роза КАМАЛЕТДИНОВА

КЕМГӘ КҮПМЕ ГОМЕР БИРЕЛГӘНЕН БЕРӘҮ ДӘ БЕЛМИ, ХОДАЙ КУЛЫНДА, ДИБЕЗ. ӘММА КИЛЕП ТЕРӘЛСӘ, АЛЛА УРЫНЫНА КҮРЕП, ТАБИБЛАРДАН ЯРДӘМ КӨТӘБЕЗ. ЧИР ЯКАҢНАН АЛСА, ВАКЫТ, АКЧА БЕЛӘН ИСӘПЛӘШМИСЕҢ.

Вәҗи агай

Һәр авылның үз Хуҗа Насретдине – бүтәннәргә охшамаган кызыклы берәр кешесе булмый калмыйдыр ул. Мәзәкчән, зирәк, холкы-табигате сәеррәк агай безнең Яңавылда да бар иде. Вәҗи агайны Хуҗа Насретдинга охшатуыбыз хак. Хәер, чын Насретдинны кем күргән дә, кем аның белән сөйләшкән соң әле?

Үсмер чак. Эче ак эмальле чиләк күтәреп, капкадан Вәҗи абзый Минһаҗев килеп керә. Атлап йөрүе дә, сөйләшүе дә тиз-тиз аның: «Әй, кем бар өйдә? Әйт, савыт чыгарсыннар! Бер аягың монда, икенчесе... Җәлт җөр димәдеммени, ник терәлеп каттың, ә?! Аю биетерләр дип белдеңме әллә?» Сөйләшүе шулайрак иде аның, теле үткен – пычак инде! Кырыс, таләпчән. Ә мин ак эчле яшел чиләктән, безнең якта бидрә диләр, күземне аера алмый, сихерләнгәндәй, тик басып торам икән. Бидрәдә мөлдерәмә тулы яңа аерткан яшь, сыек бал! Бәләкәй аш чүмече дә шәйләнә. Ул җәйне Вәҗи абзый

өй борынча йөреп, гаиләдәге кеше санынча, чүмечләп бал өләште. Гаиләсе авыл халкы өчен үрнәк, мул-җитеш тормышлы иде алар. Кара-каршы ике йорт, каралты-кура төзек, мал-туар ишле, умарта кортлары выж да выж очып, чәчәк балы ташып кына тора. Агай хуҗалыкчыл. Әле дә уйлыйм, ил буенча байлар гынамы, көннекен-көнгә ялгый алмый изаланучы ярлы халык та чутсыз үрчегән заманда яшибез бит. Яңа байларның кайсысы гына, урам буйлап, дөньяны тигезләргә теләп, чүмечләп-чиләкләп бал өләшеп йөри икән?! Ишеткән дә, күргән дә юк мондый хәлне. Юмартлык кына түгел, мондый эшгамәлләр кылыр өчен хәләл-хәрамны аера белү, күңел киңлеге дә кирәк шул. Эшчән, тырыш бу гаиләгә мәрхәмәт хисе өстән салынган булгандыр, бәлки. Гаиләгә дию-ем юкка түгел, сүз башым бит Шүрәле – Вәҗи агай килене Кафия апа – авыл «докторы», миһербанлы ханым турында. Ханым дип атау гаҗәп тоелса да, арттыру юк монда. Затлы-зыялы зат ул Кафия апа.

Вәҗи агай дигәннән, мәзәк итеп сөйләнә торган тагын бер вакыйга хәтергә уелып калган. Безнең авыл халкы кунакка йөрергә, кунак сыйларга әвәс. Хәер, борынгыдан килгән гадәт – кунак ашы кара-каршы. Берчак шулай туган-тумача, дус-ишне мәҗлескә чакыруны өйдәгеләр Вәҗи абзыйга йөклиләр һәм...

Аш вакыты җитүгә, Минһаҗевлар йортына халык агыла башлый. Олы якка әзерләнгән зур табын артына да утырталар мәҗлескә – ашка килүчеләрне. Кече өйгә дә тиз генә табын корып куялар, хәтта келәткә – бала-чагага дигән өстәл тирәли дә тезеп утыртып карыйлар. Юк, кунакларны урнаштырып бетерү һич мөмкин түгел. Вәҗи агай чакырган кунаклар ике өйгә, келәткә дә сыймый. Киң күңелле агай бөтен авылны ашка чакырган! Утырыр урын юк, дип, авылдашны борып җибәрү дә күңелсез. Икенче көнне дә кунак сыйларга туры килә хуҗабикәләргә.

Кафия апа

Алты яшәр юлдан кайтса, алтмыш яшәр күрешә керер, дигән борынгылар. Кафия апаны күптән күргәнем юк иде. Кайткач, хәл-әхвәлен белешәсе иттем. Ә ул өйдә юк икән. «Иртәдән бирле бакчада карлыган җыя. Чиләге тулмый керми инде ул. Хәзер чакырам», – ди оныгы. Туктале, аңа бит... узган ел ук 90 яшь тулды түгелме соң! Туксандагы әбине бөкерәйгән карчыктыр дип уйларга күнеккәнбез. Ә Кафия апа һаман да элеккечә: төз гәүдәле, зифа буй-сынлы, җитез хәрәкәтле сөйкемле ханым, мине әллә каян танып, кочаклап ук алды.

– Сөбханалла, күз тимәсен! – дим мин, аңа соклanып та, кызыгып та.

– Аяклар гына бетте, – дип куя ул, зарлануны килештерми, кыенсынгандай. – Ул кадәр йөрүгә соң! Сигез авылга хезмәт күрсәтү вазыйфама керә иде бит. Яңавыл, Бәзәкә, Әрем, Вольный Труд, Иске һәм Яңа Никольскийлар... Чокырча, Октябрь дигәннәре бар иде бит тагын. Хәер, ул бәләкәй авыллар юк инде хәзер. Әйдәле, чәй эчә-эчә сөйләшик. Кайтуың шәп булган, тамак та кипкән ие.

Өстәл тулы тәм-том. Оныклар әбиләренә күчтәнәч ташып кына тора. Хәер, әби дә димәссең аны, чәен пешерә, касәләргә бүлә-бүлә тәмләп сөйли дә сөйли:

– Безнең әнәй дә озын гомерле булды, йөзне тутырып бакыйлыкка күчте. И аның күргәннәре! Без җиде бала үстек: бер егет, алты кыз. Туганнарның икесе яшьләй гүр иясе булган. Әтиебез дә иртә китеп барды. Ә абыебыз – бердәнбер ир-егет – инде сугыш бетә дигәндә, 1945 елны хәбәрсез югалды. Бала хәсрәте аяктан екты әнәйне – көтә-көтә, елый-елый күзләре сукырайды. 12 яшемнән апалар белән бергә колхозда эшли идем инде мин. «Безнең кебек гомер буе колхозда чиләнәсең килмәсә, тырышып укы!» Әллә апаларның гел әйтә торган шул сүзе үзәк-бәгырьләргә үткән, әллә киресенчә, көч биргәндер дип тә уйлыйм, 1943 елда – 15 яшемдә Минзәләгә чыгып киттем.

Күңеле ак булсын кеше сәламәтлеге сагындагы шәфкать иясенең.

Минзәләдәге ФАШ – фельдшер-акушерлар әзерли торган көллияттә өч ел укыгач, таныклык тоттырып, Яңа Бәзәкә авыл советына кергән төбәкләргә медицина хезмәте күрсәтергә дип, юллама бирәләр аңа. Кем белә бит, яшь туташның шул чакларда армиядә хезмәт итеп кенә кайткан Илдархан Минһаҗев – сәер һәм киң күңелле Вәҗи агай улы белән танышуы, күп тә үтми, һөнәрле-акыллы егет белән чәчләре чәчкә бәйләнүе безнең авыл халкы өчен бәхет булгандыр әле.

Удмурт урманнары арасында адашып утырган Бәзәкә, Яңавыллар Татарстан өчен үгигә тиң дисәң дә, арттыру булмас. Читтәгене кем чутка-санга ала соң?!

Гали кызы Кафия туып-үскән Йолдыз бистәсе дә бездән егерме чакрымнар ары, олы юл өстендәге Кырындыга терәлеп кенә торган бәләкәй авыл.

Әйе, һөнәрле, егәрле, белемле кеше авыл өчен мактаныч кынамы, терәк тә ул. Күптән, балачакта бер якын дус авызыннан ишеткән бәян әле дә күңелемдә.

«Әнәй түр якта, ап-ак булып агарынып, ыңгырашып ята. Әби өйдәге барлы-юклы чүпрәк-чапрак, сөлге, тастымал, урын җәймәләрен бидрәләргә дыңгычлап тутырды да мине чишмәгә кер чайкарга җибәрде. «Әгәр кем дә кем очрап, бу ниткән кер, дип сораштыра башласа, йод түккәннәр ялгыш, диген. Башка бер сүз әйтмә!» – дип, кат-кат кисәтте. Чиләкләрне ялгашка бушатсам... Кер – лычма кан. Балаларның күлмәк-ыштаннарына кадәр кара кан – чайкап-чайкап та бетми. Шулчак берәү суга төшкәнен күреп йөрәгем өшеп китте. Авыл «брачы» Кафия апа икән. Оятыма каршы, очравын яхшыга юрамаган идем – чынында, бәхет булган ул. Күбекләнеп кан аккан ялгашка күз салуга: «Кем? Әнәңме?» – диде дә, җавап көтеп тормыйча, көянтә-чиләген ташлап, безгә йөгерде. Рәхмәт фәрештәсе канатын җәйгәндәй, биш сабыйны ятимлек-бәхетсезлектән саклаган сирәк очрак иде бу. Әгәр соңласа, әнисез каласы булганбыз ич!»

Җаннан җан яралганда

– Мин килгәндә Яңавылда медпункт та юк иде бит. Минҗиянтәйләрнең ике тәрәзәле почмак өендә ясап куйдык беренче «шифаханә»не. Кызлары Бәдәр – санитарка, җилкәгә җилкә терәп кырык ел бергә эшләдек. Мәнле, булдыклы рәис Рифкать Гыйльметдинов эшкә килгәч, медпункт төзетте. Сугыш чорында авырлы хатыннар кайсы өендә, кайната-кайнана белән яшәгәне исә мунчада бәбиләгән. Шөкер, баладан үлүче булмады.

«Брач» кынамы, разведчик булырга туры килә кайчак!

Им-том ясап авырын төшергән хатыннар турында сөйләү авыр. Аборт ясау тыелган заман бар иде. Санаулы гына ир-ат сугыштан исән кайтты. Халык фәкыйрьлектән, яра-җәрәхәтләрдән интегә. Унар бала үстерү һәркемнең кулыннан килми шул. Ә табигать үзенекен итә – йөккә уза хатын-кыз. Бәбигә авырган әниләрне район үзәге Әгерҗегә илтергә дигән күрсәтмә килде. Күрсәтмә бар, «Ашыгыч ярдәм» машинасы юк. Бездән ерак түгел – егермеләп йортлы Вольный Трудта бәләкәй хастаханә бар барын. Әмма шартлары... ташка үлчим. Берчак йөкле хатынны Вольный Трудка илтеп җиткердем. Баш табиб каршыма чыкты. «Бездә таба алмас, Әгерҗегә илт!» – ди. Әле дә ярый сөт ташый торган машина китеп өлгермәгән. Хатынны кабинага утырттым. Үзем йөк әрҗәсендә – сөт бидоннары арасына кысылып басып барам. «Ары китәргә хакым юк, путевкамда – Тирсә», – ди шофер. Өч юл чатында басып торабыз: хатынны тулгак тота, йөрәктә утлар яна. Яңгыр астында, юлда бәбили башласа, ни кылырмын? Сабырлыклар бир, мәрхәмәтле берәр адәм очрасын иде, дип Ходайга ялварам. Бәхеткә, йөк машинасы туктады. Ирем Илдарханның танышы икән. «Кафия апа, синең хакка гына утыртам, юлда милиция очраса, праваны алалар», – диде.

– Игелекләр күп кылгансыз. Фаҗигале хәлләр дә баштан кичкән...

– Әйе, һәммәбезне тетрәткән ул хәл әле дә онытылмый! Төнге сменада җир сукалап тәмам арыган ике сукачы, таң алдыннан юл читендәге чүмәләгә ятып, аз гына черем итмәкче була. Ул арада боларны алыштырасы механизатор килеп тә җитә, аны-моны абайламый, кабызып та җибәрә тракторын. Рәисебез Рифкать машинасы белән мине килеп алды. Гыйльмулла аңсыз. Носилка-фәлән юк. Киң, озын такта таптылар. Хатыны Мәгърифәгә хәбәр итәргә кирәк. «Мин әйтә алмыйм, үзегез... Зинһар», – ди Рифкать. Мәгърифә килеп җитте. Башы кара кан Гыйльмулланың, аңына килеп бер сүз: «Венераны ташламагыз!» – дип әйтте дә, күз алдында өзелде, бахыр. Мәгърифә – Сарман кызы, китапханәче, клуб мөдире. Мәхмүзәттәй, килен оныкны туган ягына алып китәр, дип өзгәләнә. Китмәде Мәгърифә, озак еллар авыл советы рәисе булып эшләде. Кызы ятим булмады, иренең энесе Нурулла белән бер егет үстерделәр.

– Шәфкать туташы, фельдшер, акушер-гинеколог – авыл «брачы» җитмеш төрле һөнәргә ия. Рәхмәт фәрештәсе ул, дисәләр, гаҗәпме? Әйтәләр иде бит.

– Фәрештә – күктә, адәм баласы – җирдә. Машина ватылса, сүтәләр; кое кипсә, күмеп куялар; мал чирләсә, суялар. Ә кеше авырса, күз текәп, сиңа килә: ярдәм итәр, терелтер, коткарыр дип ышана. Ышанычны аклау – мәртәбәле гамәл. Көн дими, төн дими, авыл халкы сәламәтлеге сагында торган апагыз. Еллары нинди иде бит. 1947 ел аеруча авыр булды. Сугыш бетәр, тернәкләнербез дип түзде халык, хәлсезләнде: тегесе юк, монысы... Кер сабыны – дефицит. Ачлыктан, юклыктан бетерешкән авыл өстенә чирләр ябырылды. Тимгелле тиф, корсак тифы, скарлатина, кызамык. Мәктәптә балаларны йогышлы чиргә каршы торырга өйрәтәбез. Йорт саен йөреп, хәл-әхвәл белешүне гадәткә керттек. Күп йөрүнең нәтиҗәсе булды: кемдер иярткән куркыныч чир – корчаңгы, трахома ише яман нәрсә таралмады. Беркөн ялгыз яшәүче Миргалим Саттаровларга кердек. Бетләгән карт белән карчык. Балалары да, мунчалары да юк. Күршегә мунча яктык, юындырдык. Бәдәр белән икәү, күмер үтүген кыздырып, эчке-тышкы киемнәрен җөйләре буенча үтүклибез. Чир таратучы вак хәшәрәтләрдән котылды картлар.

Баштан кичкән гыйбрәтле хәлләр күп инде. Әхияр ферма мөдире иде. Арлардан танышы сугымлык мал кайтарткан. Тиресен тунаганда бармагын кискән. Гөбе кебек булып шешкән беләге. Берәр дару бирсәң, үтәр, дигән була. Күрәм, начар чиргә охшап тора бу. Районнан белгечләр чакырттык. Казаннан ук килделәр. «Сибирская язва» авылга таралмаганга сөендек! Берсендә, эче авыртып, Рәсил атлы егет килде. «Сукыр эчәк, шартламасын, Әгерҗегә!» – дим. Кичен авыртуы басылган. «Эш кала, кайтам», – ди икән. Табиб – таныш егет: «Аппендицит дип, Кафия апаң белми әйтмәс», – дигән. «Күрәзәче икәнсез. Шартлый язган! Рәхмәт», – дип кайтты Рәсил.

Йокларга ятсаң да, мунча керсәң дә, бала имезгән чакта да, гүя сакта син: кемдер ишегеңне тартмыймы? Ярдәм өмет итеп кем килсә дә, өстеңә халат эләсең дә, бар эшеңне ташлап чыгып йөгерәсең. Әле дә ярый Илдархан абыегыз сабыр булды. Ат җигеп, матай белән авыру янына озатып куйган чакларын сагынам.

Үзем теләп алган язмыш – ике биана белән яшәдем. Биатайның сеңлесе ялгыз картайды. Йорты ишелеп төшкән бер көнне. Бала-чагасы юк. Кая барсын? Безгә килде исә, кызларны сөеп туялмый. Рәзилә, Гүзәлия, Җәүһәриягә энекәш – төпчегебез Җәүдәт туды. Күрәм, кызыга Фатыйма апа гаиләле тормышка. Ишленең эше дә күп юкса, ашы да... Биатайның бик сыендырасы килми. Вәҗи дигән атың бар, туганың, хәер сорашып, кеше өстендә йөрсә, ояты кемгә, дидем кыюланып. Юасы-җыясы, пешерәсе-төшерәсе сиңа – киленгә, түзәлсәң, диде бугай... Түздем. Шөкер, матур яшәдек.

Мәдинә
АВЗАЛОВА

ИДӘН ЮА БАШЛАСАҢ, КАРАВАТ АСТЫН ДӘҮ ӘНИ ЯТА-ЯТА КАРЫЙ ИДЕ.

ЯРАТУГА КОЕНДЫК

Дәү әнисенең җылы кочагын тоеп, назлы сүзләрен ишетеп, ул пешергән тәмле ризыкларны ашап үскән бала – дөньяда иң бәхетле бала. Мин дә шул бәхеткә ия идем. Аның чиксез яратуында «коенып» үскән дүрт оныгы өчен ул әби дә, дәү әни дә түгел, әни иде. Әйе, без аңа шулай дип дәшә торган идек. Үз әниебез гомер буе эштә булды. Ул ирләр шикелле гайрәтле иде. Йорт салды, бөтен тормышны гөрләтеп алып барды. Ә әти... авылларга чыгып китә дә, атналар буе өйгә кайтмый. Эше шундый иде.

Ә менә өйдәге бөтен эш – дәү әнигә. Дөресрәге, безгә... Көн саен өй җыештыру да, бакчадагы зур савытка егермешәр көянтә су ташу да, ишегалдын, капка төпләрен чистарту да... Идән юа башласаң, дәү әни караватастын ята-ята карый иде. Кул тимәгән җир калмаска тиеш. Кабат эшләтергә дә күп сорап тормый. Ә менә савыт-саба янына безне якын да китерми торган иде ул. «Кагылмагыз, үзем юам...» Безгә ышанып җитмәгән, күрәсең. Чиста, әйтеп бетергесез пөхтә иде ул. Безгә кергәләп йөргән күршекүлән дә өйнең «ялт итеп» торуына гаҗәпләнә иде.
Дәү әниебез Фәризә безне эшләтеп үстерде. Әмма мин аның безнең белән беркайчан да тавыш күтәреп сөйләшкәнен хәтерләмим. Эш куша, эшлисе. Тыңламыйсың икән, нотык сөйләми, ачуланмый. Тота да үзе эшли. Әле дә хәтеремдә, бәләкәй идем әле, булса шул 9-10 яшьләр тирәсе, дәү әнием су алып кайтырга кушты. Тышта коеп яңгыр ява, ә колонка шактый ерак. «Бармыйм, яңгыр ява», – дидем. Аның бер сүзне кат-кат әйтә торган гадәте юк иде. Чиләк-көянтәне алды да үзе чыгып китте. Ә мин аны кызганып тәрәзәдән карап калдым.

Кайта-кайта уйлыйм хәзер: үз гомерендә берсеннән-берсе тырыш-эшчән биш бала тәрбияләп үстергән, унөч оныгын караган дүрт сыйныф белеме дә булмаган гап-гади бер татар карчыгы, тәрбия мәсьәләсендә иң укымышлы педагогтан да шәбрәк, тәҗрибәлерәк булган бит ул!

Без дәү әнидән башка яшәүне күз алдына да китерә алмый идек. Бервакыт Донецк шәһәреннән дәү апам кайтты. Дәү әнине шунда алып китәргә җыена. «Берәр елдан кайтарырмын», – дигәнен ишеткәч: «Китмә, синнән башка ничек яшәрбез», – дип, тәгәри-тәгәри елаганыбыз хәтердә.

Дәү әнием минем балаларны да үстерергә булышты. Мин дә аны үзем белән Казанга алып киттем. Бакчага урнаштырганчы, әле берсен, әле икенчесен карады. Шулай бер көнне эштән кайтсам, тәрәзә янына баскан да, иске бер кәстрүлне кояш яктысына куеп, нәрсәнедер



җентекләп карый. «Әни, нәрсә бар анда?» – дим. «Ышкый торгач, кәстрүлеңнең төбен тиштем», – ди бәгырь кисәгем, тәмам хәсрәткә төшеп.

Ул бик картаеп, 93 яшенә җитеп арабыздан китеп барды. Кайчандыр безгә биргән җылылыкны, яратуны инде хәзер бездән тоеп китеп барды. Тормышны, якыннарын, кешеләрне яратканга шулай озак яшәгәндер ул. Аның өчен гомеренең һәр көне кадерле иде. Үзен безгә гел яшь итеп күрсәтәсе килде. «Әни, сиңа инде 94 тула», – дигәч, «Төне буе чутлап чыктым, миңа әле 93 кенә», – дигәнен дә онытмыйм. Ул пешергән тәмле коймакларны да онытмыйм. Зур мичне ягып җибәрер дә, коймак куяр, утынның чытырдап янганына, кисәү агачына таянып, озак кына карап торыр. Ә берзаман мичтән кетердәп торган коймаклар чыга башлар. Дәү әнием, җаныем, ул соңгы сулышына кадәр без диде, безнең өчен тырышты. Бертуктаусыз балага тәрбия турында сөйлибез. Баланы бит әнә шулай чиксез яратырга гына кирәк! Шул да җитә, минемчә.



КРУИЗ



Рәмзия КАШАПОВА

БҮГЕНГЕ ТОРМЫШТА МОГҖИЗАГА УРЫН БӨТЕНЛӘЙ КАЛМЫЙ ДИЯРЛЕК. ШУЛАЙ ДА, БИК ТЕЛӘСӘҢ, ГАДӘТИ СОРЫ КӨННӘРНЕ ЯКТЫ ХАТИРӘЛӘР, ҖЕТЕ ТӘЭСИРЛӘР БЕЛӘН БИЗӘРГӘ БУЛА.

Көннәр буе берни эшләмичә кояш астында пляжда яту – ялкыта торган ял минем өчен. Шуңа күрә башкача, яңача ял итеп карыйсым килде. Таныш дус кызымның үз туристик фирмасы бар. Европа диңгез круизын ул тәкъдим итте инде. Иң мөһиме: артык кыйммәт тә түгел.

Берничә ел элек үк круиз ялына тукталган идем. Мондый төр ялның нәрсә икәнен аңлау, аның тәмен татып карау өчен бер генә бару җитми, әлбәттә. Европача круиз ничек була соң? Уңайлыклар, затлылык, искиткеч сәяхәтләр. Әлбәттә, ул этикет кагыйдәләрен үтәүне, әдәплелек, тәрбиялелекне дә таләп итә. Аның каравы, гомергә истә калырлык сәяхәт була ул.

Үтә зиннәтле лайнер бортында матур табигатькә сокланып, дулкыннар шавын тыңлап, диңгез һавасын сулап йөрүләр, диңгез өстен йөзләгән төсмерләргә манчып, кояшның офык артына тәгәрәвен күзәтүләр... Европа шәһәрләре белән танышу, берьюлы берничә илдә булу...

Круиз лайнеры дигәнем уналты катлы зур туристик лайнер ул. Анда ниләр генә юк: казино, төнге клублар, рестораннар, гольф өчен мәйданнар, балалар өчен уен мәйданчыклары, бассейннар, кино һәм концерт заллары, хәтта үзләренең сәүдә үзәге һәм дюти фри да бар. Беренче күрүемдә гаҗәеп зур лайнер үзе таң калдырды мине. Аны тәки астан өскә кадәр карап та бетерә алмадым. Дөресен генә әйткәндә, вакыт җитмәде. Искиткеч дизайн, баскычлар, сваровски кристаллары белән бизәлгән рояль. Әлбәттә инде, кичке ашка дресс-код каралган, капитан белән очрашу һәм аның белән фотога төшү дә көтә кунакларны.

Беренче тапкыр шундый круизга ирем белән чыктык. Ул чакта без Урта диңгез буйлап атналык круизны сайладык. Лайнерга Италиянең Генуя шәһәрендә утырдык, аннары Испаниянең Барселонасына йөздек, аннан Франциянең Марселенә юл тоттык, алда – Тунис, һәм кабат Италиягә кайтып төштек. Икенче сәяхәтебездә безне Мальта кызыктырды, ә өченчесендә инде географиябез Атлантик океанга һәм Төньяк диңгезнең Португалия, Дания һәм Германия кебек илләренә кадәр киңәйде.

Без тукталган беренче шәһәр гүзәл Барселона иде. Алга китеп, шунысын да әйтим әле: ирем Барселонаны шулкадәр яратты, бу шәһәргә тәмам гашыйк булдым диде. Барселонага килеп төшүгә үк автобус экскурсиясенә киттек. 25 еврога колакчыннар бирәләр, шәһәр турында бай мәгълүмат аласың, экскурсия көн буена сузыла. Аерым бер тукталышларда чыгып, шәһәр белән танышып йөрисең, күңелеңә хуш килгән урыннарны фотога төшерәсең. Икенче автобус, сине утыртып, Каталония башкаласы белән таныштыруны дәвам итә. Барселонада шунысы яхшы – ул порт шәһәре, порт үзе дә шәһәр үзәгенә урнашкан. Бик уңайлы! Анда адашу мөмкин түгел. Автобуста азәрбайҗаннар белән туры килдек. Әтиле-кызлы «Барселона» футбол клубының штаб-квартирасын күрер өчен махсус килгәннәр. Казаннан икәнебезне һәм кайчандыр безнең «Рубин» бер матчта «Барса»ны җиңгәнен әйткәч, кыз җиңелчә генә кашларын җыерып куйды, «Барса» барыбер шәбрәк, ди. Әйе инде, шәбрәк, әлбәттә. Баланың хыялларын җимереп буламы соң! Меңнәрчә чакрымнар үтеп, яраткан футболистларын күрергә килсен дә ди...


Сәяхәтебез Генуя шәһәреннән башланды.

Искиткеч матур урыннарны карап йөреп, Гаудиның гаҗәеп архитектурасына сокланып, лайнерыбызга әйләнеп кайттык, сәфәребез дәвам итте.

Чираттагы ил һәм безнең өчен яңа шәһәр Марсель иде. Марсель – Париждан кала, Франциянең иң зур шәһәре. Эре сәнәгать төбәге буларак, илнең шактый бай мәдәни һәм тарихи мирасын үзенә туплаган. Урта диңгездәге иң зур порт та әле ул. Марсель илнең көньягында, Лион култыгында урнашкан. Безнең эрага кадәр 600 нче елда Кече Азиядән килгән греклар шәһәргә нигез салган. 1481 елда Марсель Франция корольлеге территориясенә кергән.

Киңәш

Сәяхәткә юлламаны сигез ай алдан алдым мин. Броньны никадәр алдан кайгыртсаң, шулкадәр арзанрак. Бу суммага бар да кергән була: туклану, яшәү, лайнерда тәкъдим ителгән ял төрләре: бассейннан башлап кичке концерт программаларына кадәр, музыкаль салондагы тере музыка да кергән хәтта.
Урта диңгез илләреннән кайсын сайларга белмәсәгез, иң башта кая барыйм дип аптырасагыз, круиз сезгә берничә илне күрү мөмкинлеген бүләк итә.

Фото: www.pixabay

PRESSA



■ Испаниядә, Виго урамында. Яшәр урыны да булмаган сукбай, ипине ваклап, күгәрченнәр сыйламакчы, әрсез акчарлак тәкәллефсез генә кошның ипиен талап алып ашыйю Сукбай тешсез авызы белән шуңа елмая.

■ Порттан Виго шәһәренә нәкъ шушы урамнан кереп китәсең.



Франциянең гимны – «Марсельеза». Ул Марсель халкы тарафдарлары булган республикачыларның җиңүе хөрмәтенә шулай атала.

Икенче бөтендөнья сугышы елларында нәкъ менә Марсель эре каршылык үзәге санала. Бүген ул Франциянең чәчәк атучы шәһәре, илнең мәдәни-тарихи үзәге һәм искиткеч курорт. Яңгыр сибәләп торганга, озаклап йөрмәдек: кафега кереп, атаклы француз круассаннары белән кофе эчәргә булдык. Чыннан да, Франция круассаннары бик тәмле. Ә сырлары тагын да ныграк ошады. Кечерәк бер парфюм кибетенә сугылып чыктык, туган-тумачага француз хушбуйлары алдык. Бездәгедән 60 процентка арзанрак алар.

Рәхәт соң: отелебез үзебез белән бергә төрле илләргә күчә бара. Дөнья күреп, илләр гизеп йөрисең дә, үз номерыңа кайтып, тагын юлыңны дәвам итәсең. Ашык-пошык чемодан җыеп чапмыйсың инде.

Киңәш

■ Чит илләргә барырга җыенып та, тел белмәү каршылыгы килеп туса, бер дә аптырап калмагыз. Һәрчак кулланыла торган сәламләү, рәхмәт әйтү сүзләрен, кибеттә, урамда бирелә торган кайбер сорауларны өйрәнеп куегыз. Ышанып әйтәм, шундук үз кеше булып китәрсез.

Диңгез круизында ял иткәндә, Европаның халык аз йөри торган кечерәк шәһәрләрен күрәсең, гадәттә, күбесенчә зур шәһәрләрне, башкалаларны сайлыйлар бит. Ә болай никадәр порт шәһәрләрен күрү мөмкинлеге ачыла.

Икенче юлы мин сәяхәткә дус кызларым белән барырга булдым. Бу круизда инде бер илдән икенчесенә күчеп йөрдек. Без Тунис портына керер алдыннан гына Африкадан килгән качакларның чуалышы башланды, шуңа маршрутыбызны үзгәрттек: Мальтага тукталдык. Менә ул язмыш бүләге: Тунис белән Мальтаны чагыштырып буламы соң! Круиз кампаниясе хуҗалары пассажирлар иминлеге өчен барысын да эшләргә әзер. Корабльне бүтән якка бору берни тормады аларга.

Аһ, Мальта! Аны бер генә барып күрсәң дә күңелеңдә бәйрәм рухы гомергә саклана. Мальтаның башкаласы Валетта XVI гасырда төзелгән. Гасырларны кичкән тар урамнар һәм мәһабәт биналар рыцарьлык чорына алып кереп китә. Валеттаның иң матур архитектура корылмасы булган Изге Иоһанн соборын һич читләтеп үтеп булмый. Валетта бер күрүдә яраттыра торган шәһәр. Эш стажы булмаган өлкән яшьтәге кешеләрнең айга 500 евро алулары турында белгәч, Мальта хөкүмәтенә хөрмәтебез бермә-бер артты…

Быелгы круизга без десант булып җыендык, турның да иң зурысын сайладык: Атлантик океанның Урта диңгезе һәм Төньяк диңгезендә йөзә-йөзә, ун көн дәвамында Италия, Испания, Португалия, Франция, Дания һәм Германияләрне күрү.

Бөек диңгезчеләр иле Португалия Пиреней ярымутравына урнашкан. Аның көньяк һәм көнбатыш ярларын Атлантик океан сулары юа.

Португалия болытлы көне белән каршыласа да, ул һич тә Лиссабон белән танышуыбызга комачауламады. Лиссабон турында күпләп, озаклап язып була. Кайчандыр артта калган Европа иле кинәт туристларны җәлеп итәрлек илгә әйләнсен әле. Португалиядә ял арзан түгел. Ә анда җитештерелгән товарлар дөнья базарында дан тота. Португалия аяк киемнәре арзан һәм чыдам булуы белән аерылып тора. Табигый бөкеләрдән эшләнгән әйберләр дә бик популяр. Азыктөлеккә бәяләр кыйммәт түгел.

Лиссабон җиренә аяк басуга, экскурсия автобусларын эзләргә



■ Лиссабонда миңа барыннан да бигрәк керамик мозаика, төрле чәчәкләр, төсләр һәм рәсемнәр белән бизәлгән йорт фасадлары ошады. Кайберләренең меңәр еллык тарихы бар, майолика буяуларына бернинди катаклизмнар да зыян салмаган.

■ 9 Майда – Җиңү көнендә Берлиндагы Рейхстаг янында кулга флаглар тотып, пилоткалар киеп басып тору үзе бер вакыйга!



Фото: автор

керештек. Русча сөйләүче экскурсоводлар табу кыен булмады. Үтә күренмәле моторикшада шәһәр белән танышырга киттек. Паша үз эшен яхшы белә, әти-әнисе Украинаныкылар. Безгә атаклы замок һәм чиркәүләрне, Европадагы борынгы органны, Васко да Гама, Пантеон кебек атаклы шәхесләрнең төрбәләрен күрсәтте. Мәһабәт корылма борынгы Лиссабонның теләсә кайсы ноктасыннан да шәйләнә. Аның эче дә затлы, матур. Милләтнең бөек җәмәгать эшлеклеләрен, дәүләт эшлеклеләрен, сәнгать әһелләрен, футболистларны җирләү өчен бик лаеклы урын. Балюстрададан шәһәргә гаҗәеп күренеш ачыла.

Борынгы экскурсия трамвайлары – Лиссабонның визит карточкасы. Шәһәрнең борынгы урамнары буйлап әллә кайларга алып китә.

IX–X гасырларда исламның Португалияне яулап алуын сөйләүче мирас ул биналар. Гарәпләр португаллар мәдәниятенә күп нәрсә керткән. Майолика, шәрык архитектурасы, кофе һәм башкалар. Лиссабоннан китәсе дә килмәде. Дусларым «Миңа җитмәде» дигән канатлы сүзләремне белә инде. Монда тагын бер киләм әле.

Соңгы сәяхәт ностальгия, романтизм һәм моңсулык белән тулы иде. Ничектер шулай килеп чыкты.
Бу баруымда сугыштан инвалид булып кайткан бабам турында озак уйландым. Ул да бит Берлинга ук барып җиткән. Шуңа күрә Рейхстаг янында фотога төшәргә күптән хыяллана идем. Ата-бабаларыбызны, туганнарыбызны искә алып басып тордык без анда.

Анда-монда кәефле урам сатучылары тулгана. Кара тәнле качаклар шактый. Ярлыларга кайда да рәхәт түгел...

Берлинда мине гаҗәпләндергәне – русча сөйләшүчеләр бигрәк күп икән! Кечкенә шәһәр буйлап ял итеп йөрибез, һәр тарафтан рус сүзләре колакка керә. Хәтта кафе, даруханәләрдә дә сатучылар русча сөйләшә. Әйе, Берлин шаккаттырып та куйды безне. Чисталыгы, толерантлыгы, киемнәргә – югары, ризыкка түбән бәяләре белән. Таксистларының төрекләр булуы белән. Тәме – балачагыбызны искә төшертеп, нәкъ әбиебез мичкә салып пешергән күмәчне хәтерләткән ипие белән...

9 Май иртәсендә Рейхстаг янына килдек. Әле халык күренми. Берничә ватандашыбыз баскыч янында фотога төшә. Тирә-як әйләндереп алынган. Пропусклар һәм экскурсиягә алдан бирелгән заявкалар буенча гына эчкә уздыралар. Пилоткаларыбызны кидек тә, флагларыбызны җилфердәтеп, фотога төшә башладык. Бездән килгән егетләр бәйрәм белән котлады үзебезне. «О, кызлар әзерләнеп тә караган!» – дип, флаг, пилоткаларыбызны фотога төшәргә сорап тордылар. «Сез бит Самарадан, безнең Татарстан флагы нигә?» – дип соравыма, «Без КАМАЗ егетләре белән бергә эшлибез!» – дип дәррәү җавап бирделәр. Башкалар да яныбызга килә, бәйрәм белән котлый башлады. Пилоткаларыбызны алып торучылар да булды. Менә шулай күңелле ноталарда Җиңү көнен билгеләп үттек. Һәркайсыбыз җиңү һәм тынычлык хакына башларын салган туганнарыбызны искә алды. Җаныбызга тагын нидер җитми кебек. Бераз читкә китеп, дога кылдык. Аннары кайту ягына борылдык.

Круизларга чыгып, сез дә тормышыгызны яңа эмоцияләр белән баетыгыз. Яңа хатирәләр, яңа танышлар, дуслар белән очрашырсыз... Һичшиксез ошаячак сезгә!

16+

«УЛ МИНА ИҢ ТУРЫ КИЛГӘН ХАТЫН-КЫЗ...»



Искәндәр СИРАҖИ,
журналист, язучы;
гаилә стажы – 15 ел;
балалары – Айгөл (24 яшь),
Йолдыз (15 яшь), Рәйхан (13 яшь),
Арыслан (8 яшь), Ирхан (3 яшь).

Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя... Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик.

1 Иң элек хатын-кызның нәрсәсенә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Иреннәренә! Хатын-кызның бөтен холык-фигыле иреннәренә язылган. Өске ирен кабарынкырак икән, димәк, ул тормышта – командир, аскы ирен бүлтәебрәк алга чыгып торса – эгоистрак. Иреннең читләре төшебрәк торса, димәк, ул – пессимист... Аннары борынына күз салам. Туры, кылыч борынлылар, мәсәлән, туры сүзле булалар, әмма бернәрсәне дә уйламыйча әйтмиләр. Үзем өчен кызык һәм кирәк булган хатын-кызны башта шушы билгеләр аша өйрәнәм. Без бит аларга хәзер хатын-кыз итеп кенә карамыйбыз, ул синең бизнестагы партнерың да, кул астыңдагы хезмәткәрең дә булырга мөмкин. Ә бу дөнья манипуляциядән тора... Каршыңдагы хатын-кыз белән нинди мөгамәләдә булырга, аның белән ничек сөйләшергә икәнен син алдан ук белергә тиешсең...

2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?

– Барлык сыйфатларын да гафу итәргә була. Ул хатын-кыз булган өчен генә дә! Хатын-кыз булмаса, ир-ат бернәрсә эшләмәс иде, мөгаен. Ялкау бит без... Ир-ат нәрсәгә дә булса ирешсә: кино йолдызына өйләнсә, романнар язса, нидер төзесә, байлык тупласа, болар барысы да бары тик бер генә максат – хатын-кызны яулап алу өчен генә эшләнә. Һәм күбрәк хатын-кызны яулау өчен! Бер генә хатын-кызга карап тора торган зат түгел ул ир-ат. Турыдан-туры йөрмәсә дә, үз тирәсендә күбрәк хатын-кызны тотарга тели. Динлесе дә шулай, динсезе дә... Әгәр моңа омтылмый икән, ул инде, димәк, бик үк ир-ат түгел.

3 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм өйдә аның өчен комфорт тудыручы хуҗабикәләр. Сезгә аның кайсы якынрак?

– Әгәр өйдә берсе булса, ир-ат һәрвакыт икенчесе турында да хыялланачак. Дөньяда беркайчан да 100 процент бөтен нәрсәдән канәгать булып бетеп булмый. Кеше камил зат түгел. Ир-ат белән хатын-кыз бер-берсенең кимчелекләрен кичереп, бер-берсен тулыландырып яшәгән очракта гына янәшә кала алалар. Мәгълүм мәзәктәгечә, тормышта «бер матурга – бер ямьсез» насыйп. Безнең гаиләдә дә шулай: мин кызу менә, ә хатын – сабыр, тыныч холыклы.

4 Ир кеше өчен хатыны аңа дус та була аламы?

– Әлбәттә! Ул синең хатының да, дустың да, сөяркәң дә, хезмәтчең дә... булырга тиеш. Һәм синең кайгырту объектың да! Бер-берсе өчен дус булмаган парларны беләм – алар гомер буе талашып яши. Тәгаен әйтә алам: хатын – минем дустым.

5 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганыгызны хәтерлисезме?

– Без бергә эшләдек, әмма ул чакта арабызда әле берни юк иде. Беренче хатыным белән аерылышып йөргән вакытым... Мин бит аралашучан булсам да, сирәк кешене үземә якын җибәрәм, шуңа күрә аерылу минем өчен гел авыр бирелә торган процесс. Гаиләдән киткән чорда тирә-юнемдә хатын-кызлар бик күп булды. Әмма Пановка төрмәсенә барып утырганнан соң, янымда аларның берсе генә калды – Эльмира гына... Иреккә чыккач, дөньяда минем өчен ул гына бар иде инде... Күпләр чәчәкләр биреп, романтик уеннар уйнап тәкъдим ясый. Ә икенче елны инде аерылышалар – ятим бала кала. Беренчесе белән мин ул уеннарны уйнаган идем инде...

Ә кыз сорарга кайту булды – аны йоласына туры китердек. Буранлы көн иде. Эльмираларга – Арча районы Күлтәс авылына кайтып җиткәч тә машина белән ике тапкыр батып яттык әле. Туңып, өшеп барып кердек. Барып кердек дип... Капканы ачуга ишегалдында бозау кадәр зур эт басып тора. Ә мин зур этләрдән бик куркам... Кул астына эләккән себеркенең таягын йолкып алырга туры килде. Тик минем күрәчәкләр моның белән генә бетмәгән булып чыкты. Әтәчләре талый торган икән, ул арада өстемә анысы килеп сикерде. Саклану максатыннан инде – мин аңа тибеп җибәрдем. Әтәч болдырга – мине каршыларга чыккан әбинең алдына килеп төште... «Мин сезгә яңа әтәч сатып алырмын», – дип сөйләнә-сөйләнә өйгә уздым. Булачак кияү кайтасын беләләр, тик аның Сираҗи икәненнән хәбәрдар түгелләр.

Халык мине таный иде инде. Төрмәдә утырганымны да беләләр – коллегаларга рәхмәт: бөтен нечкәлекләре белән язып тордылар. Хатын өендә дә таныдылар... «Безнең сиңа бирерлек кызыбыз юк», – диде әби. Бабай да шул сүзне кабатлады. Эльмира: «Минем сайлаган кешем шушы, фатихагызны бирегез», – диде. Кызларының үз дигәнен итми калмаганын алар яхшы белә – ризалаштылар.

6 Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый, диләр. Шулаймы?

– Юк, дөрес түгел! Җиде айлык чагымда әни мине үзенең әбисенә калдырып киткән – әбидә үстем. Шуңа күрә әни белән аралашсак та, ике арада якынлык булды дия алмыйм. Аңа охшаган хатын-кызга өйләнмәс тә идем... Дөресен әйткәндә, әнинең нинди икәнлеген җүнләп белмим дә. Миңа 17 яшь тулганда аны инде үтереп чыктылар...

7 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар. Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?

– Барыбер ир булып калырга тиеш! Йортта хуҗа ул бит. Хатыны малны күп табу – бу әле ир кеше ир кеше булудан туктый дигән сүз түгел. Бары хатынның эше уңышлырак бара – шул гына... Безнең бөтен проблемалар ирне – ир, хатынны хатын итә белмәүдән килеп чыга. Мин күбрәк эшлим икән, димәк, мин баш, дип уйлау бар. Аллаһы Тәгалә ир кешене өстен итеп яралткан икән, чынлыкта, ул барыбер өстенрәк.

8 Гашыйк булуын хатын-кыз башлап үзе белдерүгә ничек карыйсыз?

– Әйбәт карыйм. Эльмира миңа, мәсәлән, берничә шигырь багышлады. Салып йөргән вакытымда, «Ник эчәсең, талантлы кешем?» дигән мәкалә белән мөрәҗәгать итте. Ул – «Шәһри Казан», мин «Мәдәни җомга» газетасында эшли идем ул чакта. «Бу бит синең хакта», дип килеп әйттеләр... Бу дөньяда мин күп нәрсә аша уздым. Яшь чакта хатын-кызның кадерен белмисең. Аңа күп нәрсәне кичермисең, имеш буе кыска, биле юк... Ә олыгайган саен, аны хатын-кыз булганы өчен генә дә кадерли башлыйсың... Хатынымның миңа иң туры килгән хатын-кыз икәнен беләм. Аны миңа Аллаһы Тәгалә биргән һәм башкасы булмаячак. Мәхәббәтнең гомере – өч ел, ә аннары бер-береңә кирәклегә әйләнәсең. Өйдә халык күп бит минем, «Үзем генә калып торасы иде», – дип хыялланган чаклар да була. Ә алар каядыр китсә, өйдә берүзем йоклый алмый тилмерәм. Төне буе йөреп чыгам...

9 Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә дип саныйсыз?

– Белмим... Хатын-кыз булып караган юк бит. Миңа үз гомеремдә бик күп кызларның мәхәббәт аңлатканнары булды. Үз-үземне яхшы беләм бит – мин шактый дорфа, төксе – алар урынында булсам, якын да килмәс идем. Гомумән, нәрсә өчен ир-атны яратып була икән?! Шактый килбәтсез халык бит без. Күбебез тәмәке тарта, тарткан кеше белән ничек үбешәләр? Юк, белмим, минем өчен хатын-кызның бик зур сере бу.

10 Хатын-кызларның үзегезнең кайсы якларыгызга игътибар итүне көтәсез?

– Мин инде хәзер хатын-кыздан артык игътибар көтмим. Беренчедән, ул минем өчен куркыныч – тормышым, шөкер, көйле, балаларым бар. Шүрләтә: шушы бөтенлекне җимереп куйсаң, аннары ни булыр?! Яшь чакта хис белән яшисең, ә хәзер, хисләргә караганда, акыл өстенрәк. Дөрес, күпләр мине әле дә хис белән генә эш итә дип күзаллый. Юк, Сираҗи уйламыйча берни дә эшләми ул!

11 Ир-ат белән хатын-кыз икесе ике галәмнән икәне билгеле инде. Кайчакларда аларның бер-берсен аңламаулары шуннан килеп чыга да. Хатын-кызның нигә нәкъ менә шулай эшләгәнен үзегез аңламаган берәр очракны искә төшерегез әле.

– Болай аңлашып яшибез, беркайчан тавыш күтәреп талашкан юк. Үпкәләшүләр була инде, билгеле, тик алары да минем игътибарсызлык аркасында. Туган көннәрне онытам, туй көнен (ә без аны ел саен билгеләп узабыз)... Алдыма тәлинкәне катырак этеп куйгач кына искә төшә...

Хәер, бер нәрсә бар. Хатынның кибеттән кайткач: «Фәлән әйберне алмадым әле, акча җәлләдем, әмма ул безгә кирәк», – диюен аңламыйм. «Син алырсың дип уйладым», – ди. Шул бер үк кесәдән чыга лабаса!

12 Хаклы икәнегезне яхшы беләсез, әмма хатыныгызның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный...

– Күптән бер нәрсәне аңладым – хатын-кызга һәрвакыт юл куярга кирәк. Хаклы түгел икәнен белеп тә, хатын белән килешсәң, «җиңдем» дип, ул да сөенә, «юл бирдем» дип, син дә куанасың. Һәм шуның белән бөтен проблема да хәл ителергә мөмкин. Ә гаиләдә бәхәс чыкмый калмый инде ул. Тик аны гаугага җибәрүдән ни мәгънә?! Хатын-кыз бит ул ир-атның кабыргасыннан яратылган, бераз кәкре була. Аны турайтам дип тотынырга ярамый – сынычак.

13 Шундый очракны күзаллыйк әле: сез ачыгып, арыпталып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән.

– Әйе, андый хәл дә булырга мөмкин. Тормыш бит... Мин, мөгаен, пиццага заказ бирүчеләрдәндер. Яки роллар китертәсең дә, шуны гаиләдә мәҗлескә әйләндерәсең. Хатынның да башы авыртудан туктый... Дөрес, үзем дә нидер пешерә алам. Әмма аның өчен мин язарга утырырга тиеш... Әдәби әсәрне башта бик озак күңелдә йөртәсең, ул тәмам өлгереп, ниһаять, кәгазьгә төшерерлек була. Утырасың өстәл янына. «Искәндәр Сираҗи. Хикәя» дип язып куясың. Тагын аз гына аскарак хикәянең исеме һәм беренче җөмләсе языла – алар алдан уйланган була инде. Һәм... бүтән язасы килми башлый. Өстәл яныннан китү өчен син ашарга әзерли башлыйсың...

14 Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша...


– Хатын белә: үземә кирәк нәрсәне мин үзем алырга яратам. Шуңа күрә 23 февраль бездә дә шул ук носки, шул ук одеколон бәйрәме ул.

Үзем аңа бүләк бирергә бик яратам. Алтын-көмеш бизәнү әйберләре дә шактый аның, күбесен кулланмый да, әмма матур әйбер күрсәм, барыбер аласым килә. Хәзер кызлар үсеп җитте инде – алар тага, алар кия. Ә чәчәк белән минем хатынны шаккаттырып булмый. Вазасында чәчәкләрнең беркайчан шиңгәне юк – кесә бушрак чакларда да бер чәчәклек кенә акчаны һәрвакыт таба идем...



Тулысынча сайтыбыздан укыгыз:
www.syuyumbike.ru

PRESSA



ИРТӘЛӘДЕ...

Климакс вакытында организм зур үзгәрешләр кичерә. Иртә килгәндә – бигрәк тә... Чарасын күрмәсәң, ахыры аяныч тәмамланырга мөмкин.
Баштан ук кисәтеп куйыйк: климакс яки күрем килү чорының тәмамлануы – ул хатын-кыз өчен табигый хәл. Әйе, ул организмны зур тетрәнүләр кичерергә мәҗбүр итә. Әмма аннан әле берәүнең дә котылып калганы юк.
Без табигатебез белән шундый. Күпчелек хатыннарда ул 46–52 яшьтә башлана. Инде син бала табу бәхетеннән дә мәхрүм. Синдә моңарчы булмаган чирләр баш калкыта. Һәм бу гаҗәп түгел. Без, шул рәвешле, әкренләп кенә гомер офыкларына юл алабыз. Ләкин биредә сүз иртә килгән климакс турында барыр. Монысы исә бөтенләй башка күренеш. Әйтик, әле сиңа 37 яшь тулып кына килә. Ә ул, каһәр, инде синең бусагаңда, әнә ишек шакый. Һәм «ул хатын-кызга сәламәтлеге белән бәйле исәпсез-хисапсыз проблемалар тудыра».
Казанда яшәүче Алия Галиеваның редакциягә җибәргән хаты шулай башланып китә. Хаттагы сорауларны «АВА-Казан» клиникасының генераль директоры, Татарстанның атказанган табибы Фирая САБИРОВАга юллыйбыз.

?«Күремем 37 яшьтә туктады. Балаларым булгач, башта моңа игътибар да итмәдем. Берникадәр вакыттан соң үтереп баш авырта, кул-аяклар сызлый башлады. Шунда гына аңлап алдым, климакс иртә килгәнгә... Нигә шулай булды, үзем дә аңламыйм. Нәселдән килә дияр идең, әнинең күреме 57 яшендә туктаган...»

– 40 яшьтән соң хатын-кызның күбесендә климакс билгеләре башлана. Моңа эстроген дип аталган җенес гормоннарының кимитүбәнәя башлавы сәбәпче. Әлбәттә, климакс өчен 37 яшь бик иртә әле. Әмма, әйткәнемчә, мондый күренешләр еш очрый. Климаксның башлангыч чоры ике ел дәвам итә: күпләп күрем килә, йә ул ике-өч ай бөтенләй килми тора. Организм эстроген кытлыгы кичерә. Уникешәр ай күрем килми торган чаклар да була. Инде хәзер аналык күзәнәкләренә җенес гормоннары җитми башлый. Без аны менопауза дибез. Һәм көннәрдән бер көнне аналык бизләре эшләүдән туктый.

?«Эштә үземне уңайсыз тоям. Кинәт кенә битемә кан йөгерә, кызарып китәм, тирләп чыгам...»

Кызганыч, иртә килгән климаксның галәмәтләре шундый. Кинәт кенә тәнгә кайнар су койгандай була. Бит, муен тирәләре кызарып чыга. 5-6 минут шулай дәвам итә. Соңыннан калтырата башлый. Һәм тән шабыр тиргә бата. Кәеф тәгел уйнаклап тора: әле тегеләй, әле болай. Елыйсы килә, юктан гына ачу чыга. Кинәт кенә симереп китүең дә ихтимал. Эстроген аз күләмдә генә булса да май тукымасы белән эшкәртелә. Шуңа кирәкле гормоннарны тотып калу өчен организм аны җыя башлый.
Тире начарая, чәч коелу күзәтелә. Җенес гормоннарының түбән булуы тәндә һәм биттә төкләр үсүгә китерергә дә мөмкин. Кан басымы күтәрелү, инфаркт-инсульт, сөяктәге үзгәрешләр... болар барысы да әнә шул күренеш нәтиҗәсе. Якынлык вакытында хатын-кыз авырту сизә. Өстәвенә, организмга эстрогенның җитмәве шикәр диабеты китереп чыгарырга да мөмкин. Кальций үзләштерүдә дә катнаша бит әле ул. Кул, оча сөягә сызлаулар шуның белән дә бәйле. Җыеп әйткәндә, яшәү рәвешенә, сәламәтлегебезгә җитди үзгәрешләр кертә. Һәм алар һич тә безнең файдага түгел.

?«Белгечләр күремнең иртә тукталуын «чир түгел», диләр. Нишләп чир булмасын? Нишләргә соң? Нинди дару эчәргә? Кемгә күренергә?»

Иртәләгән климаксны чир дип атамасак та, пациент вакытында табибка күренмәсә, аның, чыннан да, башы чирдән чыкмаячак.
Сүз күремнең иртә бетүе турында гына бармый. Әйе, бу күренешне без чир дип атамыйбыз. Ләкин организмның үзен башкача, үзгә тотуы әллә каян күренеп тора.
Бу чорда репродуктив цикл туктала һәм гормональ үзгәрешләр башлана. Шулай да без аны физиологик үзгәреш, дип атыйбыз. Бу вакытта әле берниндн дару да, дәвалану да кирәкми. Ә инде климакс үзен нык сиздерә, төрле җитди авыруларга этәрә торган билгеләр сала башлый икән, ул чагында гормональ препаратларның кирәклеге бәхәссез. Аның башлангыч чорында ук чарасын күрә башлыйсың икән, постменопаузаның нәтиҗәсе ул кадәр үк куркыныч булмый.

Климакс өч этапка: пременопауза, менопауза һәм, әйткәнебезчә, постменопаузага бүленә. Әгәр дә күрем туктар алдыннан башланган билгеләрне күзәтеп барсагыз, контрольдә тотсагыз, барысы да әйбәт булыр.

Хатын-кыз организмында була торган шушы өч чорның билгеләре түбәндәгечә:

Пременопауза хатын-кызда 40 яшьтән соң башлана. Ул уртача 15–18 айга кадәр сузылырга мөмкин. Мондый вакытта күкәй күзәнәкләренең эшчәнлеге кими, овуляция тәмамлана, күрем килү вакыты бозыла. Ул айдан-айга сузыла килә. Автор әйткәнчә, баш авырту башлана, биткә, муенга кан йөгерә, кәеф «уйнаклап» тора, йөрәк тибешенең ешаюы, аналык җиңсәсендә корылык күзәтелә.

Ә менә менопауза вакытында эстрогеннар эшләүдән туктый. Ул 50–53 яшьләр тирәсендә башланырга мөмкин. Шушы ук чорда остеопороз һәм йөрәк, кан тамырлары проблемасы башлана.

Постменопауза – картаю галәмәте. Бу чорда күремнең бөтен билгеләре юкка чыга. Әйе, климакс һәркемдә үзенчә бара. Аның беренче билгеләре күренүгә үк гинекологка мөрәҗәгать итәргә кирәк. Ә күремегез бик иртә туктаган очракта – гинеколог-эндокринологка... Иртә климакс белән шөгыльләнүче махсус белгечкә, дип әйтер идем. Аннары алты ай саен тикшеренеп торырга... Дөресе шулай. Кызганыч, хатын-кызның күбесе моңа җитди игътибар бирми. Элеккечә яшәвен дәвам итә. Бу үзгәрешләрне ул «арыдым»га сылтый. Тагын бер кабатлап әйтәбез: эстрогенны алмаштыра торган гормональ (ЗГТ) терапия хәлне күпкә яхшырта. Өлкән яшьтә әлеге гормоннар күләме кимеп кенә калмый, ә бәлки, бөер өсте кабыгы да юкара башлый. Хатын-кызларның күбесе гормональ терапияне зыянлы саный. Шуңа еш кына аны куллануддан баш тарта.

ЗГТның файдасы турында да берничә сүз әйтеп китүне кирәк саныйм. Белгәнебезчә, табигый булмаган химик матдәләрнең барысы да организмга зыян сала. Әмма гормоннар – табигый матдә. Алар гормоннар алмашынуны һәм гемостазны көйли. Аннан файдаланган хатын-кыз күрем бетүне җиңелрәк кичерә.

Күп кеше ЗГТ шеш үстреүгә, кан тамырларында варикозны көчәйтүгә китерә, аны иртә климакс вакытында, гомумән дә, кулланырга ярамый дигән фикердә тора. Исегезгә төшерәбез: бу – ялгыш фикер.

Тагын бер мөһим нәрсә: туклануга игътибар итегез! Рационыгызда яшелчә, кыяклы, кузаклы, соялы үсемлекләр булырга тиеш! Ногыт борчагын да онытмагыз... Брокколи, яшел чәй турында әйтеп тә тормыйм. Ә менә ит, балык, йомырка ише ризыклар, камыр ашлары, сөт продуктлары мөмкин кадәр азрак булсын. Чиргә дәваны ашаган ризыктан эзләгез. Тозлы әйберләр дә зарарлы. Әйтелгәннәрне игътибарга алсагыз, баш авыртулар да, кул сызлаулар да кимрәк булыр, бавыр-бөер проблемасы да килеп чыкмас.

Ә инде нинди дару дигәннән... Монысын бары табиб хәл итә. Шулай да иң нәтиҗәлесе – алмаштыргыч гормонотерапия (ЗГТ) препаратлары. Алар – организмга җитмәгән синтетик эстроген биреп торучылар. Әгәр дә бу препарат кемгәдер ярамый икән, ул чагында фитоэстроген кулланырга да була. Ләкин аның тәэсире күпкә кимрәк.

«Күремнең иртә бетү сәбәбе нидә? Бәлкем, мин үзем гаепледер?»

Хатын-кыз организмында бара торган кайбер үзгәрешләрне тизләтә торган нәрсәләр була. Моны тәгаен белү өчен янә эстрогенга һәм гормонга кан анализы тапшырырга кирәк. Әгәр дә беренчесе (ЛГ) – түбән, икенчесе (ФСГ) югары икән, климакс вакытыннан алда башланган дигән сүз. Ә сәбәбе? Беренчедән: нәселдән килә, әнисенә карап, дип әйтик. Икенчедән: генетик тайпылышлар гаепле. Өченчедән: аутоиммун чирләр – әгәр дә хатын-кызның калкансыман бизләре, бөер өсте бизләре авырта икән, гормональ проблема килеп туарга мөмкин. Инде килеп, стресслар, арулар, тәмәке тарту, ябыгам дип ач тору да файдага түгел. «Иртә климакс»ка юлыгучыларның 15 проценты – тәмәке тартучылар.

Шунысын да әйтмичә кала алмыйм: элегрәк баланы ярып алганнан соң аналык бизләрен алалар иде. Баласы бар, башка проблема булмасын, янәсе. Ә бу исә күрем килүне туктатуга сәбәпче. Инде бүтән чара калмаганда гына аналык бизләренә кагылырга ярый.

Мәдинә АВЗАЛОВА әзерләде.

Киңәш

- Климакс вакытында биткә, муенга кан йөгерү көндез генә түгел, төннәрен дә җәфалый. Аның беренче билгеләре күренүгә үк йокыны көйләргә (7 сәгатьтән дә ким булмаска); күбрәк һавада йөрергә; бассейнга йөрергә, йога белән шөгыльләнергә; дөрес киенергә (бик җылы да, бик салкын да булмасын) кирәк.
- Шифаханә-курортларда ешрак булыгыз! Аның да әле көньяк курортларында һәм көз көне... Минераль сулы курортлар бигрәк тә әйбәт. Бальнеотерапия (дәвалау ванналары) сәламәтлеккә аеруча файдалы. Радон ванналары, циркуляр душ, гидромассаж да бу очракта бик урынлы.
- Өй шартларында исә атнага бер-ике мәртәбә җылы ванна алыгыз. Аптекалардан файдалы үләннәр сатып алып, шуларны ваннага өстәсәң, тагын да яхшырак була. Моның өчен әрем тамыры, ромашка да әйбәт.
- Иртән контраст душ, ә кичләрен аякка салкынча ванна ясарга тәкъдим итәбез.
- Ә климакс авыр барганда шалфей, бөрлегән төнәтмәсе, валериана эчегез. Ярдәм итә. Ләкин ике айдан да артык кулланмагыз. Аннан соң башка сихәтле үләннәрне файдаланырга мөмкин.

PRESSA

ҖӘЙНЕҢ ЯМЕН БОЗМАС ӨЧЕН



Ни генә дисәң дә, безнең өчен иң рәхәт, иң матур ел фасылы – җәй. Җылы кояшы, яшелчәсе, җиләк-җимеше... Ләкин шушы рәхәтлекләре белән бергә, ашказаны-эчәк авырулары китереп чыгаручы төрле инфекцияләр дә безне, аеруча балаларны, нәкъ менә шушы чорда сагалый. Агулану очраклары да җәй көне ешрак күзәтелә. Җәйнең ямен җибәрмәс, болай да санаулы көннәрне хастаханәдә дәваланып уздырмас өчен, ризыкларның саклану вакытына һәм режимына, гигиена таләпләренә аеруча игътибарлы булырга кирәк. Республика йогышлы авырулар клиник хастаханәсенең балалар клиникасы югары категорияле табибы Нурия НУРГАЛИЕВА үзенең киңәшләрен бирә.

Саклану срогына игътибар да итмичә, төрле татлы тәм-томнар, кремлы пирожныйлар белән сыйланып, анда-монда шашлык, ысланган балык капкалап йөреп, күз кызыккан экзотик җимешләрдән авыз итеп, үз бакчабызныкы булгач, чиста инде дип, юньләп юып та тормыйча төрле җиләкләр ашап агуланулар турында һәрвакыт сөйләп, кисәтеп торсак та, «Ашыгыч ярдәм» көн саен авыр хәлдәге балаларны ташып кына тора. Бәйрәмнәр, туган көннәрдән соң берничә көн суыткычта торган майонезлы салат, торт, соклар белән сыйлануның азагы агулану белән тәмамлана.

Җәйге чорда агулану очраклары аеруча күп. Юылмаган җиләк-җимеш, яшелчәләр ашау, өлкәннәр үзләре үк сыйлаган колбаса, сосискалар, гөмбәләр, дөрес сакланмаган сөт продуктлары, кайнамаган су... Болар бар да агулануга китерә. Кечкенә балаларга, гомумән, гөмбә, кыздырган ит, тозлы кыяр ашатмаска кирәк, ул ризыклар бик авыр үзләштерелә. Тиешенчә эшкәртелмәгән, саклану сроклары чыккан ризыкларда микроблар үрчи башлый. Моны бала организмы күтәрә алмый. Җитмәсә, җәй әле кавын-карбыз, алма чоры да бит. Аларны башта чәй содасы белән юарга киңәш итәр идем.

Сальмонеллез белән авыру очраклары да күп. Ул тиешенчә пешмәгән иттән, йомыркадан килеп чыга. Йомырканы юмыйча пешерергә һич ярамый.

Ротавирус еш очрый. Инфекция селәгәй, төкерек аша да йога. Авыру бала уенчыкны тотып уйный, икенчесе шул уенчыкны авызына каба – нәтиҗәдә, чир аңа да эләгә. Еш кына инфекция су белән дә керә.

Киңәш

Агуланганнан соң туклану рационы

ЯРЫЙ: ярмалы ашлар; карабодай, дөге, солы боткалары: пешкән кишер, суган, бәрәңге; сөт продуктларыннан – кефир, бифидок, наринэ; пешкән алма, яшелчә боламыгы.

ЯРАМЫЙ: майлы ит, майлы балык, каз, бәрән ите, консервлар, сарделька-сосискалар; кәбестә, чөгендер, борыч, суган, сарымсак, фасоль, борчак, гөмбә; сөт, каймак, туңдырма, кыздырган йомырка; тары боткасы, макарон, кара ипи; газлы сулар, кока-кола; чипсы.

Елга-күлләрдә су коенганда, балаларны бассейн, аквапаркларга алып барганда бик игътибарлы һәм сак булырга, кайда да гигиена кагыйдәләрен төгәл үтәргә кирәк.

Агулануның беренче билгеләре нинди?

– Бала агуланганда, иң элек температурасы күтәрелә. Йөзе агарына. Хәлсезлек күзәтелә, ул ятып тору җаен карый. Ашау-эчүдән баш тарта. Эч авыртудан зарлана. Көненә 20 шәр тапкыр косулар, сулы (кайчак хәтта кан белән) эч китүләр башлана. Ашаган ризыгы, эчкән суы фонтан булып кире чыга.

Беренче ярдәм нинди булырга тиеш?

– Иң башта температураны төшерергә кирәк. Косканнан соң, ярты сәгать бернәрсә дә бирмиләр. Аннары организм югалткан суны кайтарырга кирәк. Балага биш минут саен ярты йә бер чәй кашыгы кайнаган су яки газы чыгарылган минераль су эчерәләр. Кул астында гына абсорбентлар булса яхшы. Ашкайнату көйсезлекләре булганда ферментлар килешә. Агуланган очракта биопрепаратлар да нәтиҗәле дәвалый. Ләкин даруларны кулланыр алдыннан инструкцияләрне игътибар белән укырга кирәк. Составында тере бактерияләр булганнарын суыткычта саклау мәҗбүри! Кайберәүләр марганцовкалы су эчертеп, ашказанын юдырып була дип уйлый. Ялгыша күрмәгез! Баланың ашказаны ялкынсынып, хәл тагын да катлауланачак.

Үз белдегең белән дәваланырга ярамый. Бала агуланганда ашыгыч рәвештә табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк. Агулану авыр форма алса, хастаханәдә дәвалыйлар. Тәүлек буе капельница астында яткан балалар да бар.

Агуланган очракта халык медицинасы ярдәмгә килә аламы?

– Халык медицинасында кулланыла торган мүк җиләге кисәле, ромашка төнәтмәсе, гөлҗимеш сиробы (аны эч киткәндә кулланырга ярамый, юкса тагын да ныграк көчәйтәчәк!), дөге суы, шомырт төнәтмәсе эчерү файдалы.

Коскач, организм бик күп микроэлементлар югалта. Шуңа күрә авыру балага йөзем белән күрәгәдән компот әзерләп эчерсәң әйбәт.

МАТУРЛЫКМЫ, ӘЛЛӘ ТӘМӘКЕМЕ?



Тәмәке тартуның зыяны турында ишетмәгән кеше юктыр. Әмма, кызганыч, аңа карап кына тартучылар нигәдер кимеми. Тәмәке организмга астыртын рәвештә, әкрен генә тәэсир итә һәм шуның белән тәмәке тартучыларның сизгерлеген киметә, алдый да. Тик бу үзгәрешләр бер, ике яки ун кап тартуга ук сизелми. Хроник бронхит, йөрәк-кан тамырлары авырулары, яман шеш... Тәмәке тарту аркасында килеп чыккан җитди авыруларның берничәсе генә әле бу. Ә хатын-кызның тышкы матурлыгына нинди зыян сала ул? Бу хакта кардиолог, терапевт, Россия кардиология җәмгыяте һәм Евразия терапевтлар ассоциациясе әгъзасы Альбина ШАҺИДУЛЛИНА сөйли.

Нинди генә матур киенгән, бизәнгән булсагыз да, тартасыз икән, сездән килгән тәмәке исе боларның барысын да «бозачак». Тәмәке исеннән җиңел генә котыла алмыйсың: ул киемеңә, чәчеңә, тәнеңә сеңә. Хушбуй исләрен дә басып китә. Әмма тартучы кеше бераздан үзе аңа иярләшә: тарту аның тәм һәм ис тоюын шактыйга киметә. Тик тирә-юньдәгеләр аңардан килгән исне сизүдән туктамый бит! Тартучы хатын-кызларның күбесе, тәмәке исе килмәсен дип, бертуктамый сагыз чәйни. Беренчедән, гел сагыз чәйнәп тору матур күренеш түгел. Икенчедән, сагыз чәйнәү аркасында ашказаны согы бүленеп чыгып тора, шуның аркасында ашкайнату системасында төрле чирләр барлыкка килә.

Тәмәке тартасыз икән, кечкенә генә бер тәҗрибә ясап карыйк әле. Өч фотосурәтегез кирәк булачак: берсе – тарта башлаганга кадәр, икенчесе – моннан өч ел элек һәм әле күптән түгел төшкәне. Ә хәзер өчесен дә алдыгызга куегыз да чагыштырыгыз. Күрәсезме аерманы? Яшь тә бара бит, анысын да онытырга ярамый, дияргә ашыкмагыз – тәмәке төтене салган зыян, яшь белән булган үзгәрешләргә караганда, барыбер зуррак ул.

Тарткан хатын-кызның йөзендә мимик җыерчыклар тартмаучыларга караганда күпкә алданрак барлыкка килә һәм, гадәттә, тирәнрәк тә була. Бу факт аларның тиреләренә даими рәвештә кислород җитмәве, аның дымланмавы, тукландыручы матдәләргә ярлылыгы турында сөйли.

Тиренең тыгызлыгын һәм сыгылмалылыгын, шулай ук йөз сызыкларының төгәллеген эластин һәм коллаген дигән гормоннар тәэмин итә. Никотин исә шуларны эшләп чыгаруны тоткарлый. Нәтиҗәдә, организмга әлеге матдәләр җитмәү аркасында тән тиресе ямьсезләнә, юкара, сәлперәя. Тәмәке төтенендәге микроскопик кисәкчекләр тәнгә сеңә һәм күзәнәкләрне бөке белән томалаган шикелле каплап куя – тәннән чыгарга тиешле табигый бүлендекләр чыга алмый башлый. Тәмәкедә булган никотин һәм сумала аркасында Е һәм С витаминнары «җимерелә», шул сәбәпле, тиредә җилсенү, ялкынсынулар башлана – тиренең тышкы кәяфәте ямьсезләнә.

Тәмәке төтененең тешләрнең эмаленә ничек начар тәэсир итүе турында да әйтми калып булмый. Никотинда булган сумала кисәкчекләре тешләрнең эмаленә «утыра», тешләр табигый төсен җуя – саргая. Тәмәке төтенендәге аммиак төкерек белән кушыла, һәм авыз эчендә селтеле мохит тудыра. Нәтиҗәсе инде күз алдында: тартучы кешенең уртлары ялкынсына, тешләре бозыла, кариес башлана.

Теләсә кайсы хатын-кызны чәч бизи, ул – аның байлыгы, горурлыгы. Тәмәке тарткан очракта баш тиресендә кан әйләнеше бозыла – аңа туклыклы матдәләр килми башлый. Янәшәгездә бертуктамый тәмәке пыскыткан хатын-кызлар бар икән, игътибар итегез: аларның баш тиресе бик коры (шуның аркасында кавык барлыкка килә дә инде), чәчләре бик сыек, сынучан, алар аның коелуыннан зарлана.

Тәмәке тарткан хатын-кызга элеккеге сәламәтлеген ничек кайтарырга, кабат битләре алсуланып, күзләре янып торган чибәр ханымга ничек әйләнергә соң? Моның юлы бер генә – тәмәке тартуны ташлау.

Бу яман гадәттән котыла алган очракта, йөрәк өянәге белән авырып китү куркынычы өч ай узуга кимиячәк, үпкәләр әйбәтрәк эшли башлаячак. Соңгы тәмәкене тартканга биш ел булгач, инсульт белән авыру ихтималы тәмәкене бер дә тартмаган кешеләрнеке белән тигезләшәчәк. Тартуны ташлаганга унбиш ел тулганда, йөрәктәге таҗ сыман артерияләр белән бәйле чирләргә дучар булу очрагы тартмаган хатын-кызларныкыннан аерылмаячак.

Ниһаять, ихтыяр көчегезне туплап, тартуны ташлый алгансыз икән, табибка барып кайтырга да вакыт табыгыз. Тәмәке тарту аркасында тешләрегезгә зыян килгән булса, һичшиксез, стоматологка күренегез: тешегездә булган ташларны алсын, дәваласын. Тартканга күрә йөрәк белән бәйле ниндидер проблемалар бар икән, һичшиксез, кардиологка язылыгыз. Отоларингологка күренү дә артык булмаячак. Организм өчен кирәк булган витаминнарны тиешле күләмдә кабул итүгә дә ныграк игътибар итегез.

Пассив тарту организм өчен шулай ук бик зыянлы: тәмәке тарткан кешеләр янында басып тормасагыз хәерлерәк булыр.

Сәламәтлегегез дә, озак яшь һәм чибәр булып калуыгыз да – үзегездән. Табигать биргән матурлыкны, тәмәке төтененә кушып, вакытыннан алда юкка чыгармагыз.

PRESSA



«Хуҗабикә» сәхифәсенең бүгенге кунаклары – Гүзәлем һәм Салават МИҢНЕХАНОВлар. Икесе дә Азнакай якларыннан. Җырчы пар татар эстрадасына «Гөрләтеп яшик әле» җыры белән дуэт буларак килеп кергән иде. Хәер, Салаватны да, Гүзәлемне дә аңынчы да белә идек үзе. Салават туганнан бирле диярлек сәхнәдә ул – якташлары аларның гаилә ансамбльләрен яхшы хәтерли әле. Инде менә Гүзәлем белән бер гаилә булып иҗат итүләренә дә биш ел икән. «Болгар радиосы»ның милли премияләре (ә ул аларның бишәү!), «ТМТВ», «Алтын Барс» премияләре тамашачы мәхәббәте турында сөйли. Сәхнәдә генә түгел, тормышта да гел бергә алар. «Без хәтта ашарга да бергә әзерлибез. Шулай тәмлерәк тә, тизрәк тә!» – диләр беравыздан. Җәй – җиңел ризыклар чоры, дип, «Сөембикә» укучыларына да тиз генә әзерләнә торган бер рецепт тәкъдим иттеләр. Дөрестән дә, тиз – плитә янында кайнашырга вакыты булмаган кеше дә әзерли алырлык ул. Өстәвенә, шундый тәмле һәм файдалы.

ҖӘЙ СЫЕ – ТУТЫРЫЛГАН ТАШКАБАК



Кирәк:

- 500 г эремчек (майлылыгы 5%);
- 4-5 яшь ташкабак (кул яссуы зурлыгындагысы әйбәт кенә);
- 100 г каты сыр;
- бер уч укроп һәм петрушка (яраткан кеше тархун да өсти ала);
- 2-3 тырнак сарымсак;
- таба майларга үсемлек мае;
- ташкабакларның өстенә сыларга 2-3 аш кашыгы майонез (мәҗбүри түгел);
- тоз-борыч.

Эш барышы:

■ ташкабакны юып, баш-башын кисеп алабыз да өске ягын 1,5 см калынлыгында итеп буйдан-буйга телеп чыгарабыз (капкач вазыйфасын үтәячәк ул). Яшь ташкабакның кабыгын әрчергә кирәкми.

■ Чәй кашыгы белән эчендәге орлыкларын алабыз. Безгә ташкабакның эче куыш булу кирәк. Ләкин бик юкартып та бетермәгез.

■ Эремчекне тирән савытка бушатып, чәнечке белән изәбез – төерләре калмасын. Шунда ук вак итеп турал-








Фото: Ксения Богданова

ган укроп белән петрушка кушабыз.
■ Сыр белән сарымсакны вак угычтан уып, аларын да эремчек янына салабыз. Түбәнчә тоз һәм борыч сибәбез, яхшылап туглыйбыз.
■ Әзер эчлекне ташкабак эченә тутырып, өстен кашык белән тигезлибез, «капкач»ын каплыйбыз.
Шуып төшмәсен өчен «капкач»ны ике читеннән агач таякчык белән ташкабакка кадап куярга да була.
■ Тутырылган ташкабакны майлы табага тезеп, 180-200 градус җылылыктагы мичкә 25-30 минутка тыгабыз. Өсте кызарып китсен өчен, бераздан, майонез ягарга мөмкин.
■ Әзер ташкабакларны табынга аш тәмләткеч үләннәр белән бизәп чыгарабыз. Янына каймак яки катык, майонез куя аласыз. Ул кайнар килеш тә, суынгач та бик тәмле. Ашларыгыз тәмле булсын!

Мастер-класс «Беседка» иҗат студиясендә уздырылды.

Мастер-классы по всем видам рукоделия
Кулинарные мастер-классы
Товары для творчества
Флористика
Беседка
студия творчества
г. Казань, ул.Муштари, 2а
(843) 264-51-15, 236-40-64
www.studiobesedka.ru
г. Казань, ул. Абсалямова, 19
(843) 221-03-73
РЕКЛАМА

Кайнатмалар чоры

Июль – бакчада җиләкләр өлгергән чор. Без сезгә берничә кызыклы һәм яңа кайнатма рецепты тәкъдим итәбез.

Дерелдәвекле чия

• 2 кг чия;
• 1,3 кг шикәр комы;
• 1,5 аш кашыгы желатин.

Чияне юып, төшен алабыз. Тирән кәстрүлдә чия белән шикәр комын кушып бутыйбыз, аннары 5-6 сәгатькә калдырабыз. Чиянең суты чыгарга тиеш.
Желатинны ярты стакан суга салып бүрттерәбез. Чама белән 20-30 минут кирәк булыр. Аннары утка утыртып, желатинлы суны кайнарлыйбыз, ләкин кайнатып ук чыгармыйбыз. Желатин суда эреп бетәргә тиеш.
Шикәрле чияне утка утыртып, кайнап чыкканнан соң 10 минут пешерәбез. Сүндерәм дигәндә генә желатин өстибез. Яхшылап болгатуга, уттан алабыз.
Кайнатманы кайнар килеш банкаларга тутырып, калай капкач белән томалыйбыз.

Кавынлы кура җиләге

• 800 г кура җиләге;
• 1,5 кг кавын (йомшагы гына);
• 2 лимон;
• 1 лайм (аны лимон белән алыштырырга була);
• 2 кг шикәр комы;
• 1 чәй кашыгы ванилинлы шикәр;
• 0,5 чәй кашыгы төелгән мөшкәт чикләвеге (мускатный орех).

Лимон белән лаймны юып, кабыгын вак угычтан уабыз, тирән эчле кәстрүлгә сутын сыгабыз. Лимон һәм лайм сутына 1 стакан шикәр комы, уылган кабыкны салып болгатабыз, 1 сәгать тотабыз. 1 стакан су һәм калган шикәрне өстәп, утка куябыз. Кайнап чыккан ширбәткә вак кисәкләргә бүленгән кавын йомшагын салып, 5 минут кайнатабыз. Аннары кура җиләген кушабыз. Тагын 5 минут кайнатып, уттан алабыз.
4-5 сәгатьтән соң, кайнатманы кабат утка утыртып, кайнап чыкканнан соң, 15 минут утта тотабыз. Иң ахырдан гына ванилин белән мөшкәт чикләвеген кушабыз.
Суынганнан соң, банкаларга тутырып, пластмасса капкачлар белән каплыйбыз, салкын урында саклыйбы



Башка үзенчәлекле рецептлар белән сайтыбызда таныша аласыз.



КАКЛАР КОЯР ЧАК

Җәй көннәрен көтеп алабыз – язның гына түгел, җәйнең дә бер көне ел туйдырырлык. Башкортстан җирендә нинди җиләк-җимеш үсә – барысыннан да компот, кайнатма ясап калырга тырышам. Безнекеләр аеруча какны ярата. Аны кунакка алып барырга да, күчтәнәч итеп биреп җибәрергә дә күңелле.
Какны кура җиләгеннән, карлыган, чия, кара бөрлегән, крыжовник, алмадан ясыйм. Алмадан кала, барысына да бал кушам. Алмадан ясарга уйласагыз, аны башта телемләп турап пешерергә, аннары вак иләк аша чыгарырга кирәк. Алма белән крыжовникка дарчин салып җибәрергә була. Ә минә кара карлыган кагы бөтнек белән бик тәмле. Какны эссе көнне тышта, кояш астында киптерәләр. Шәһәр фатирында исә электр белән эшли торган махсус киптергеч (электросушилка) кулай.













Эш барышы:

- юган кара карлыган белән бөтнек яфрагын иттарткычтан чыгарып, тәменчә бал кушабыз.
- Киптергечнең тәлинкәләрен көнбагыш мае белән аз гына майлыйбыз.
- Изелгән җиләкне юка гына итеп (5 мм) майлаган тәлинкәләргә ягабыз.
- Какларны киптергечкә куябыз.
- Бер тәүлек кипкәннән соң, тәлинкәдән кубарып, тәгәрәтеп төрәбез. (Ничә сәгать кибүе җәймәнең санына бәйле. Җәймәләр 5-6 гына булса, 10 сәгатьтән дә кибә.)
- Әгәр дә андый аппаратыгыз булмаса, какны гадәти куна тактасына җәеп, кояшта да киптерергә мөмкин. Куныны да алдан майларга кирәк, югыйсә как ябышачак. Кояшлы көннәр булмаса, какны кайнар мунчада яки майлаган калайга җәеп, сүрән мичтә (газ мичендә дә була, ләкин ишегеп ябып бетермәскә кирәк) киптерәләр. Үтәли җил йөри торган җирдә дә киптереп була.

Зәлия АХУНОВА.
Башкортстан.

Июль – җиләк-җимеш өлгергән чак. Шушы чордан файдаланып, чибәрләнеп калыйк әле. Әйе, нәкъ менә чибәрләнеп, чөнки җиләк-җимештәге табигый органик кислоталар, витаминнар, минераллар хәтта иң кыйммәтле кремнар белән дә чагыштырырлык түгел.



ИҢ ШӘП КОСМЕТОЛОГ – БАКЧАДА!

АЛМА – биттәге ялкынсынуга каршы бер дигән чара. Өстәвенә, бетчәләрне дә бетерә. Кояшта бит тиресе пешсә яки салкында өшесә дә, уылган алма ярдәмгә килә.

Ярты алманы вак угычтан уып, 1 чәй кашыгы бал, 1 йомырка сарысы, 1 чәй кашыгы алма серкәсе, 1 чәй кашыгы үсемлек мае салып болгатабыз. Бу маска бит тиресен дымландыру өчен дә әйбәт.

КУРА ҖИЛӘГЕННӘН маска бит тиресен йомшарта, кара нокталарны эретә, пигмент таплардан арындыра. Коры тире өчен тукландыргыч маска сыйфатында 2 аш кашыгы җиләккә 1-2 аш кашыгы бал салып изәргә һәм 20 минутка биткә сыларга. Юып алганнан соң, тирегә зәйтүн мае сөртергә. Ун көн дәвамында шулай эшләсәң, вак җыерчыклар күзгә күренеп бетә.
Сулган тирене яшәртеп җибәрү өчен, 2 аш кашыгы изелгән кура җиләгенә 1 аш кашыгы кибет каймагы, 1 аш кашыгы зәйтүн мае кушып туглагыз да 20 минутка биткә ягыгыз.
Майлы тирене чистарту өчен 2 аш кашыгы җиләккә 2 аш кашыгы дөге оны кушып кулланалар.

КАРА КАРЛЫГАН маскалары аеруча яшүсмерләргә файдалы. Андагы С, А, Н витаминнары тиренең ялкынсынуын дәвалый, бетчәләрне бетерә, сипкелләрне һәм тутларны агарта. Изелгән кара карлыганда арыш ипиенең йомшагын җебетеп, тирене чистарту өчен биткә ягалар. Ипи урынына кефир да кушарга була.

КЫЯР СУТЫ иң шәп лосьон. Ул чистартып кына калмый, бит тиресенең киңәйгән күзәнәкләрен тарайта, тирене агарта, арыганлык эзен бетерә.

Бит тиресе майлы һәм эре күзәнәкле булса, вак угычтан уылган кыярга күпертелгән бер йомырка агы яисә берничә тамчы лимон суты кушыгыз. Тире коры булса, уылган кыярга 2 аш кашыгы кибет каймагы өстәлә. Шушы масканы чиста биткә сылап, 10-15 минут тыныч кына ятып торыгыз. Аннары җылымса су белән юып төшерегез. Су урынына чәй яки яңа сыгылган кыяр суты да кулланырга мөмкин.

БӘРӘҢГЕ җыерчыкларны язарга булыша. Чи бәрәңге боламыгы күз төбендәге шешенкелекне ала. Ә яңа гына сыккан бәрәңге суты белән биттәге бетчәләрне дәваларга була.

Бит тиресе ялкынсынып китсә, пешкән бәрәңгене төеп, аз гына сөт белән тугларга (1 чәй кашыгы глицерин өстәргә була) һәм җылы килеш биткә ягарга. Өстеннән пергамент кәгазе ябып, 20 минут чамасы тотарга.

Киңәш

- Җиләк-җимеш маскаларын кулланыр алдыннан гына әзерлиләр. Кышкы чорда куллану өчен җиләкләрне катырып куйсаң әйбәт.
- Бит тиресе майлы булмаса, маскаларны атнага 1-2 тапкыр ясыйлар. Майлы тире өчен атнага 2-3 тапкыр ясарга кирәк.
- Маскаларны чиратлаштырырга да була.
- Майлы тире өчен иң яхшы маскалар: кызыл карлыган, мүк җиләге, нарат җиләге, кәбестәдән.
- Коры тирегә өрек, йөзем, кавын, слива, банан әйбәт.
- Карбыз, кыяр, әфлисун, җиләк исә һәртөрле тирегә дә килешә.

PRESSA



Фото: www.pixabay

СМУЗИ

НӘРСӘ УЛ СМУЗИ?

Смузи – блендерда издерелгән җиләк-җимеш, яшелчә, үләннәргә су, сөт, йогырт яки солы лавачы кушып ясалган куе эчемлек.

АНЫҢ ФАЙДАСЫ НИДӘ?

Яшелчә, җиләк-җимешләрдәге барлык витаминнар да саклангангалыктан, ул организмга көч бирә, тукландыра. Көненә берничә порция смузи эчү көнлек яшелчә һәм җиләк-җимеш нормасына тиң.

Смузи ябыгырга да ярдәм итә. Кичке ашыгызны үләннәрдән торган яшел эчемлеккә алыштырып карагыз әле, нәтиҗәсе озак көттермәс. Өстәвенә, витаминнар һәм үсемлек җепселләре ашкайнатуны көйләргә булыша. Ә менә «Детокс смузи» дигәне организмны чистарту өчен әйбәт.

СМУЗИНЫ КАЙЧАН КУЛЛАНАЛАР?

Яшелчәләрдән һәм җиләк-җимешләрдән генә әзерләнсә дә, смузины бер тәлинкә аш ашап куюга тиңләргә кирәк. Җиләк-җимештән ясалган эчемлекне – иртәнге ашка, яшелчәле-җимешлесен – көндезге аш вакытында, ә яшелчәләрдән әзерләгәнен кичке ашка куллану яхшырак. Җиләк-җимешләрдән әзерләнгән смузины көненә 200 мл, ә яшелчәләрдән ясалганын 400 мл кулланса, шул җитә.

МӨҺИМ КАГЫЙДӘЛӘР

1. Смузи өчен тыгыз нигез кирәк. Бу банан, авокадо, груша була ала.

2. Организмны чистартырга теләсәгез, эчемлеккә сөт ризыклары кушмаска кирәк. Иң яхшысы: җитен яки чиа (шундый үсемлек) орлыгы, төелгән чикләвек, имбир яки дарчин өстәү.

3. Үләннәр күбрәк булган саен, яхшырак. Шпинат, укроп, петрушка, кыяр, сельдерей, рәйхан, бөтнек – витаминнар, минераль матдәләр, клетчатка чыганагы.

4. Шикәр комы урынына – бал, тоз урынына диңгез тозы куллану отышлы.

СМУЗИ ФОРМУЛАСЫ

Бу төр эчемлек белән яңа мавыга башлаучыларга гади генә бер формула бар: 1 яки 1/2 стакан сыеклык + бер чынаяк үлән + 1 яшелчә яки 1 алма (банан, груша, киви… – ниндине телисез) яисә 1 чынаяк җиләк. Шушы ингредиентларны кушудан файдалы һәм тәмле эчемлек килеп чыга.

СМУЗИ РЕЦЕПТЛАРЫ

■ Ярты стакан солы лавачы һәм ярты стакан йогуртны блендер савытына салып, 15 минут тотабыз. Шуңа кара җиләк (башка төрле җиләк тә ярый), бераз су, 1 чәй кашыгы бал, 1/4 чәй кашыгы имбир кушып, барысын да блендерда туглыйбыз.

■ 2 киви + ярты яшел алма + ярты банан + 2 аш кашыгы лимон суты + бер уч бөтнек яфрагы + бер чеметем дарчин (корица).

■ 1 банан + 1 әфлисун + 4-5 бөртек яшел рәйхан яфрагы (базилик) + 1 киви.

■ 10 шпинат яфрагы + 1 банан + 1 авокадо + 1 груша + бер чеметем кунжут орлыгы + бераз су.

Үсемлек сөте белән ясалган смузилар:

■ 250 мл бадам (миндаль) сөте (кокос, солы сөте дә була ала) + 1 банан + 1 стакан шпинат.

■ Бадам, кокос, солы сөтләрен ничек әзерләү һәм аларның файдасы турында сайтыбыздан укый аласыз.

Детокс-смузи:

■ уртача 1 чөгендер + 2 чынаяк руккола үләне + 1 кызыл алма + 4-5 рәйхан яфрагы + 1 банан + су.

■ 1 брокколи + 1 яшел алма + 1 тәлгәш яшел виноград + 2 уч шпинат + 2 кәбестә яфрагы (теләсә нинди кәбестәнеке дә ярый).

Камилә ДИМӨХӘММӘТОВА әзерләде.



Кучкар. Очрашулар, сөйләшүләр ае булып истә калыр. Төп көчегезне эштәге мөнәсәбәтләрне җайлар өчен сарыф итәрсез. Уңышыгызның нигезендә әйләнә-тирәдәгеләр белән дустанә мөнәсәбәт ята.



Үгезбозау. Тормышыгызның уңышлы чоры. Максатыгызны дөрес билгеләсәгез, аңа ирешү юллары үзеннән-үзе табылыр. Алдыгызда яңа мөмкинлекләр ачылуын күрерсез.



Игезәкләр. Уңышлы, куанычлы ай. Соңгы айда күрсәткән тырышлыгыгызның нәтиҗәсен күрерсез. Сездәге уңай энергия, позитив фикер башкаларга да йогучан. Үзегезне игътибар үзәгендә тоярсыз.



Кысла. Ачышлар ае. Моңарчы белмәгән якларыгызны ачарсыз. Элек алынырга да курыккан эшләрне җиңел генә тормышка ашыру мөмкинлеге бар. Айның икенче яртысы ял итү, тынычлану чоры булыр.



Арыслан. Айның беренче яртысы киеренкелектә узса да, истәлекле ай булыр. Тормышның матур һәм ямьле булуын аңлатырдай мөһим вакыйга көтелә. Үзегез дә күбрәк йөрергә, аралашырга тырышыгыз.



Сөмбелә. Яңа ачышлар һәм яңа үрләр көтә. Соңгы вакытларда кими төшкән көчегез, тәвәккәллегегез кире кайтыр. Планеталарның тезелеше бик уңышлы: яңа эшләр башласагыз, ахыры яхшы тәмамланыр.



Бизмән. Үзегезне гаиләгезгә, туганнарыгызга багышлар вакыт. Алда рәхәт ял, якыннарыгыз белән күңелле сәяхәт көтә. Эш турында азрак уйларга тырышыгыз, ул яктан бар да тыныч булыр, артыгын борчылмагыз.



Чаян. Хисләр ташыган вакыт. Кайчак үзегезне кулда тотуы да кыенгарак туры килүе ихтимал. Дусларыгыз, туганнарыгыз белән мөнәсәбәтләр бозылмасын дисәгез, сабыр булыгыз. Күбрәк юл бирергә туры килер.



Укчы. Кызыклы тәкъдимнәр, яңа мөмкинлекләр чоры. Тәвәккәлләп тотынсагыз, ахыры хәерле булыр. Планеталар торышы яңача фикерләүгә этәрә торган. Стилегезне һәм имиджыгызны үзгәртү дә уңышка юл ачачак.



Кәҗәмөгез. Шәхси тормышыгызда куанычлы вакыйгалар көтелә. Бу айда төрле бюрократик киртәләр җиңел үтелә: хәл итәсе мәсьәләләр булса, хәзер тотыныгыз. Уңыш үкчәгә бастырып килә.



Сукояр. Мәшәкатьле, әмма нәтиҗәле ай. Алай да алга чәчрәп чыкмагыз, шатлыкларыгыз турында сөйләмәгез: дус булмаганнарның күзе тимәсен. Сезгә елмайган уңыш күпләрнең йөрәген яндырырлык.



Балык. Ниндидер зур вакыйга көтелә. Тормышыгызда яхшы үзгәрешләр булыр. Үзегездәге җитешсезлекләрне бетерергә, фикерләрне үзгәртергә мөмкинлек туачак. Тыйнаклыгыгыз аркасында көтелмәгән сөенеч килер.

ИЮЛЬ *дә кабынган йолдызлар*

Татарстан



Клара Хәйретдинова (27.07.1948) – **опера җырчысы, педагог, Татарстанның – халык, Россиянең атказанган артисты.**

Биектау районының Өнсә авылында туып үсә. Мәктәпне тәмамлагач, Казан дәүләт педагогика институтында укый. Студент елларында Казан вертолет заводы клубындагы үзешчәннәр түгәрәгенә йөри. 1969 елда аны Татар дәүләт филармониясенә солист итеп алалар. Шул ук елны, конкурс үтеп, ике елга Мәскәүгә – Бөтенроссия эстрада сәнгате остаханәсенә укырга китә. 1979 елда Казан дәүләт консерваториясен тәмамлап, кабат филармониягә кайта. Ләкин озакка түгел, 1980 елдан 2006 елга кадәр опера һәм балет театры сәхнәсендә җырлый. Беренче роле – «Князь Игорь» (А. Бородин) операсында Ярославна партиясе. 1997 елда аны Казан дәүләт консерваторясенә вокал укытырга чакыралар. 2006 елдан опера сәхнәсен калдырып, үзен тулысы белән педагогикага багышлый.

Россия



Лия Ахеджакова (9.07.1938) – **Россиянең халык артисты.**

Украинаның Днепропетровск шәһәрендә туа. Әнисе һәм үги әтисе дә сәхнә кешеләре. «Старые клячи» фильмында алар әтиле-кызлы уйный. Ә бит кайчандыр үги әтисе аның актриса булу теләген хупламый, һәм ул ел ярым Мәскәүнең төсле металл институтында укый. Соңрак барыбер ГИТИСны тәмамлый (1962 ел). 1977 елдан – «Современник» театрында. Беренче ролен 1973 елда – «Ищу человека» фильмында уйный. Танылу аңа Эльдар Рязановның «Небеса обетованные» фильмындагы Фима роленнән соң килә. Икенче пландагы рольләрне генә уйнаса да, Рязановның «Гараж», «Служебный роман», «Ирония судьбы или с легким паром» фильмнарын аннан башка күз алдына китерүе кыен.

Чит илләр



Мишель Родригес (12.07.1978) – **актриса.**

Аны Россия тамашачысына «Форсаж», «Мачете», «Аватар», «Обитель зла» фильмнары танытты.

Үзе ул Американың Техас штатында, Сан-Антонио шәһәрендә туа. Үзсүзле, буйсынмас кыз булып үсә. 17 яшендә мәктәпне ташлап, шоу-бизнес белән шөгыльләнеп карый, төрле фильмнарның күмәк күренешләрендә катнаша, кастингларга йөри. 2000 елда аңа «Женский бой» фильмында уйнарга тәкъдим итәләр. Һәм ул аның актерлык карьерасын үзгәртә дә инде: актрисаны «Форсаж» фильмында уйнарга чакыралар. 2009 елда Джеймс Кэмеронның «Аватар» фильмында уйный.

Фото: https://www.vokrug.tv/







ЧӘЧӘК ҖИЛЕ

Рәссам тудырган образлардан без, гадәттә, авторның үз чалымнарын да эзли башлыйбыз. Менә, Лилия Сираҗетдинова картиналарындагы чәчәкләр дә аның үзенә охшаган кебек. Нәфис, серле, горур, нәзакәтле... Кызыл мәкләр, ак ромашкалар, сары көнбагышлар арасында зәңгәрләре – кыңгыраулар, күкчәчәкләр үзенә бер нур белән балкый. Нәкъ Лилиянең күзләре инде! Ул тирә-юньдәге матурлыктан, табигать могҗизасыннан биһуш. Картиналарында да чәчәк җиле уйный. Җәй уртасы. Димәк, Лилия тагын Идел буендагы бакчасында чәчәкләре белән сөйләшә. Купшы лилияләр, мөгаен, кунак көткән хуҗабикәләре кебек, талгын гына бакча түрендә сихри ямьгә чумып утырадыр. Нәзберек ирислар – иң яратканнары.
Ул аларны камиллек символы дип атый.

Ничек рәхәт биредә! Кайчандыр Кама Тамагы якларыннан күчеп килгән Гариф бабасы, Әминә әбисе бакчасы бит ул! Аларның эзләре, аларның кул җылысы, алар утырткан агачлар сакланган кадерле җир. Бабасы Шәрипов Гариф Фәссах улы бик гыйлемле, зыялы кеше булган. Шәһәребезне, аның борынгы урам-тыкрыкларын яратырга, берсен-берсе кабатламаган биналарына сокланырга, милли мәдәниятка табынырга кызны Гариф бабасы өйрәтте түгелме соң инде? Хәзер ул мәхәббәтне Лилия ханым укучыларында тәрбияли. Талантлы шәкертләре күп аның! Милли мәдәниятка мәхәббәтне әкиятләр, риваятьләр аша, тормышның үз кагыйдәләренә төреп бирүен укучылары ничек ошата! Кайчандыр, ерак балачакта башлангыч күнекмәләрне 1 нче балалар сәнгать мәктәбендә алган иде, хәзер инде менә 30 елдан артык үзе шунда укыта, Лилия Юрьевна – югары категорияле педагог. Н. И. Фешин исемендәге Казан художество училищесында белем ала. Яшь рәссамның һөнәри осталыгы югары реализм традицияләрендә үсә. Рәсем, сынлы сәнгать, декоратив-гамәли композицияләр укытучысы дипломы алып чыга. Ә 2010 елда Социаль мәгариф академиясенең культурология бүлеген тәмамлый. Россия һәм Татарстан Рәссамнар берлеге әгъзасы. Татарстанның атказанган мәдәният эшлеклесе.

Ире Рафаэль Сираҗетдинов та – рәссам. Уллары Эмиль исә әти-әнисеннән күчкән шул сәләтне тагын да үстереп, архитектура өлкәсен сайлаган. Швейцариядә архитектура академиясендә уку елларында байтак Европа шәһәрләре архитектурасын өйрәнеп йөргән. Түбән Каманы танымаслык булып үзгәрде диләр икән, баш архитектор Эмиль Сираҗетдиновның турыдан-туры катнашы бар монда... Буыннар чылбыры шулдыр инде...

Рәссам шәһәр, республика, төбәк, Россия күргәзмәләрендә актив катнаша. Татарстан Рәссамнар берлегенең 70 еллыгына багышлап иҗат иткән «Композиция» картинасы үзе генә дә ни тора! Картиналарының күбесен фәлсәфи натюрморт жанры берләштерә. Аларга тирән мәгънә салынган. «Чагылыш», «Ностальгия», «Вакыт сулышы» картиналары күз алдыннан үтә. «Иҗатыма бер караш бу. Шәһәребез, вакыт, чәчәкләр, төрле әйберләр турында үзенә күрә бер хикәя, – ди рәссам. – Мәсәлән, Казанда инде юкка чыккан йортлар истәлегенә ачкыч-йозаклар, борынгы предметлар сурәтләнгән. Өйләрен инде сүткәннәр, ә хуҗалары әле һаман иске ачкычларын саклый... Гадәти булмаган композиция югалган шәһәрне, балачакны, яшьлекне, җаныбызның кире кайтарып булмый торган бер халәтен юксындыра... Ә чәчәкләр аша кәефне сиздереп була».

Эльмира ЗАКИРОВА









ЛИЛИЯ СИРАҖЕТДИНОВА





«Почта России»ның «Подписные издания»
(ПАП) рәсми каталогы буенча
ЖУРНАЛЫБЫЗНЫҢ ИНДЕКСЫ П2204

Татарстаннан читтә яшәүчеләр
әлегә «Роспечать» каталогындагы
элеккеге индекс буенча языла алалар 73002

яртыеллыкка язылырга өлгерми калучылар
һәр айның 15 нә кадәр язылып,
журналны киләсе айдан алдыра ала



Сайтта: www.syuyumbike.ru
ВКонтактеда: vk.com/suumbike
Фейсбукта: www.facebook.com/syuyumbike
Инстаграмда: www.instagram.com/suyumbike_journal

Журналыбызга онлайн режимда :
http://podpiska.pochta.ru сайтында (регистрация узып)
язылырга мөмкин



Электрон версиягә язылган очракта, яңа санны компьютерда, планшетларда, барлык мобиль җайланмаларда PDF форматта укырга була.
iPad һәм **iPhone** кулланучылар «Сөембикә» журналының электрон версиясен App Storeдагы «Pressa.ru» киоскына кереп, хатын-кызлар өчен журналлар арасыннан таба ала.
Электрон версиягә язылу турында тулырак мәгълүматны «Сөембикә» журналының сайтында «Язылу» бүлегендә табып була.

16+